# ТАТАР ТЕЛЕ
# ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ

**ТӨП ДӘҮЛӘТ ИМТИХАНЫНА**

**ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР**

КАЗАН

2020

**Т ө з ү ч е - а в т о р л а р :**
***Г.Р. Галиуллина, Э.Н.Денмөхәммәтова , Н.М. Йосыпова, Г.Р.Мөгътәсимова, К.С. Фәтхуллова***

Җыентык 2020 нче елда татар теле һәм татар әдәбиятыннан төп дәүләт имтиханына әзерлек өчен төзелгән һәм контроль бәяләү материалларының үрнәк вариантларына таянып башкарылган өстәмә материалларны үз эченә ала. Ул төп гомуми белем бирү программасын үзләштергән IX сыйныф укучыларына имтиханга мөстәкыйль рәвештә әзерләнү өчен, шулай ук укытучыларга һәм методистларга өстәмә методик ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

**ТАТАР ТЕЛЕ**
**81 нче код биремнәре**

## Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына аңлатма

Дәүләт йомгаклау аттестациясе эше сочинение элементлары белән киңәйтелгән иҗади биремле изложение формасында тәкъдим ителә. Изложение имтихан бирүчеләрнең тыңланган текстка нигезләнеп, мөстәкыйль рәвештә мәгънәви бөтен, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерланган иҗади бирем башкаруына йөз тота. Киңәйтелгән изложение укучыларның лингвистик компетенциясе (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясе (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), коммуникатив (аралашу) компетенциясе (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерелә.

Күрсәтмә материаллар катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенең төзелеше, биремнең үзенчәлеге, аның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу варианттагы биремне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Күрсәтмә материаллар чыгарылыш сыйныф дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенә әзерлек осталыгын булдырачак.

## Эшне үтәү өчен күрсәтмә

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларга татар теленнән дәүләт йомгаклау аттестациясе эшен язу өчен 3 сәгать 55 минут вакыт бирелә. Бирем 1 өлештән тора. Укучылар текстны 2 тапкыр тыңлыйлар. Беренче тапкыр тыңлаганнан соң, уйлану өчен һәм караламада эшләү өчен вакыт бирелә (5 минут). Текстны икенче тапкыр тыңлаганнан соң, изложение язу эше башлана. Изложение биремдә күрсәтелгән проблемага бәйле сочинение элементлары белән киңәйтелә. Укучылар әлеге проблемага бәйле иҗади фикер йөртергә һәм үз фикерләрен дөрес, логик эзлеклелектә формалаштырырга тиеш.

Язма эшне башкару барышында орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт бирелә.

Караламадагы язулар тикшерелми!

Язма эш махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Язма эшне хаталарсыз башкарып, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

**1нче вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме <u>200 сүздән ким</u> булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Кышлак читендә ялгыз бер өй булган. Биредә Хәлимә исемле кечкенә кызы белән Мәрьям апа яшәгән. Ишегалларында гөлчәчәк куаклары үскән. Ана белән кыз әлеге куакларны бик кадерләгәннәр. Көз килсә, аларны камышлар белән төреп, салкын кыштан яшереп куя торган булганнар. Көннәрдән бер көнне ана белән кыз яңа йортка күчәргә җыенганнар.

– Әнкәй! Безнең гөлчәчәкләребез каламыни? – дип, әнкәсеннән сорап куйган Хәлимә.

– Без күчәсе йортның алдында гөлчәчәкләр күп булса да, боларны да ятим итеп монда калдырмабыз, үзебез белән күчерербез.

Алар ваграк куакларны тамырлары белән казып күчерә алсалар да, иң зур куакка көчләре җитмәгән.

– Кызым, монысы калсын инде. Казый торгач, тамырларын харап итеп ташлавыбыз бар, – дигән әнкәсе.

Кыз, карт куакның үзен генә калдырырга кызганса да, көче җитмәгәч, нишләсен? Шулай итеп алар, иске өйләре алдында карт гөлчәчәк куагын ялгыз калдырып, китеп тә барганнар.

Көз үзе белән салкын җил, кыш рәхимсез суык бураннар алып килгән. Көзге җил дулаган, сызгырган, ыжгырган, әллә кайлардан куе болыт көтүләрен куып китергән дә ялгыз куак өстенә эре-эре тамчыларын сибәргә тотынган. Ә төн җиткәч, кинәт каты суык китереп бәргән. Иртәгесен күкне калын болытлар каплап алган, күбәләк-күбәләк кар яварга тотынган. Мескен карт куак, күз ачып йомганчы, ап-ак кар белән күмелеп калган.

Көн артыннан көн үткән, кояшлы, көләч яз килгән. Үләннәр яшәреп киткәннәр, агачлар чәчәкләргә күмелгәннәр. Бары куак кына язны котлап елмая алмаган. Ул, кышкы суыктан чирләгәнгә, кара янып, тереклектән мәхрүм булып боегып утырган да утырган. Тик кайдадыр, бик тирәндә, тамырларының ерак очларында зәгыйфь кенә тормыш җылысы саклый икән ул.

Ничектер бер көнне Мәрьям апа кызы Хәлимә белән куак яныннан үтеп бара икән. Хәлимәнең күзләре әлеге зур куакка төшкән дә, ул аны кызгануыннан чак кына елап җибәрмәгән.

– Әнкәй! Безнең ялгыз куагыбыз корыган бит, – дип, әнкәсенә сарылган.

– Ай, харап булган шул! – дигән әнкәсе. – Янында агып тора торган арыгы да кибеп беткән икән, ичмасам. Аны тазартып, су җибәрергә кирәк. Бәлкем, шуннан соң яшәреп китәр...

Ана белән кыз арыкны тазартканнар, буасын ачып, аңа саф су агызып кикәннәр.

Чынлап та, кинәт зур куакның тамырларына дым йөгергәне сизелгән. Кечкенә Хәлимә арыкны тикмәгә генә ачмаган бит! Ботакларда беренче бөреләр күренә башлаган, алар күбәйгәннәр, тулыланганнар, ә үзләре барысы да яшәү бөреләре булганнар.

Менә берзаман зур куак янына әнкәсе белән Хәлимә килеп туктаган.

– Әнкәй! Кара әле, куагыбыз чәчәк аткан бит безнең! – дип, кул чабып кычкырып җибәргән Хәлимә. – Арыкка су җибәрүебез бик яхшы булды, әнкәй. Чәчәкләре элеккегә караганда да матуррак!

– Әйе шул! Яхшы эш, хезмәт беркайчан да әрәм булмый ул, – дигән әнкәсе һәм чәчәкләр арасыннан берсен, иң матурын өзеп алган да кызының чәченә кадап куйган. *(Д.Аппакова)* (398 сүз)

**“Яхшы эш, хезмәт беркайчан да әрәм булмый ул, – дигән әнкәсе һәм чәчәкләр арасыннан берсен, иң матурын өзеп алган да кызының чәченә кадап куйган”,** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Ялгыз өй янында гөлчәчәк куагы үскән. |
| 2 | Ана белән кыз яңа йортка күчкән. |
| 3 | Гөлчәчәк куагы кышны ялгыз үткәргән. |
| 4 | Язын куак бөреләнмәгән. |
| 5 | Мәрьям апа белән Хәлимә куакка су агызганнар. |
| 6 | Гөлчәчәк куагы чәчәк аткан. |

## 2нче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм таныrлык итеп языгыз.***

Кларaның бабасы, мәрхүм, аңа еш кына: «Клара, бәбкәм, безнең Каракошны бер кайтып күрер идең, ата-бабаңның туфрагы бит ул!» – дип әйтә торган иде. Бабасының бу сүзләренә каршы Клара, ни әйтергә белмичә, уңайсызланып кала торган иде. Әллә кайдагы ул «туган туфрак» дигән нәрсә аңа билгесез, ят иде, шуңа күрә бабасының сүзләре аңарда бернинди теләк тә, кызыксыну да уятмый иде.

Ә бабасы Каракошын, шунда үткәргән гомерен еш кына сагынып исенә төшерә торган иде. Бала чагын, егет вакытларын, каз өмәләрен – барысын да кызык итеп, көрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде. Клара, карт кешенең хәтере өчен генә аны тыңлаштырса да, барыбер үзенчә уйлый иде. «Хәзерге авылның коты юк, ә иске авыл нинди булгандыр инде ул?..» Аның укып белүе буенча, иске авылның бер яме дә, бер кызыгы да булмаган. Дөрес, аның бабасы таза гына тормышлы булган, аты, сыеры булган, иген иккән. Әмма шулай да хәзерге вакытта иске авылны сагынып утыру һич килешә торган эш түгел инде. Кайчакта Клара, артык түзә алмыйча, бабасының сүзен бүлә иде: «Куй инде, бабакай, мактама инде син иске авылны. Йә, сезнең ул Каракошыгызда элек мәктәп булганмы, клуб, радио, электр булганмы?»

Әмма шуңа да карамастан, бабасы үзенең Каракошын һаман сагына иде. Әледән-әле Кларага әйтә торган иде: «Кайтып күр, кызым, гомер иткән нигезебез шунда, ерак бабаларыңның кабере шунда, сиңа якын түгелмени алар?», – ди иде.

Инде менә үткән көз Кларaның бабасы каты авырудан соң үлеп китте. Сиксән елдан артык дәвам иткән гомер өзелде. Барысын да – сагыну-юксынуларын да, җыр-әкиятләрен дә бабай үзе белән бергә кабергә алып китте.

Хәзер инде гаиләдә Каракошны телгә алучы да юк, «туган туфрак» дигән сүз үзе үк бөтенләй онытылырга тиеш иде. Ләкин, ни гаҗәптер, Клара, бабасы үлгәннән соң, аның әйткән сүзләрен исенә төшергәли башлады. Каракош та әледән-әле күңеленә килгәли торды. «Бабакаемның гомер иткән җире, безнең «туган туфрагыбыз», миңа ул кайтып күрергә кушып калдырды бит», – дип уйлана торган булды.

Ахырда, эчке бер кызыксыну белән уйланып йөри торгач, Кларада бабасының туган авылын кайтып күрү теләге туды. Ничектер менә, бабасы алдында бурычлы кебек ул, әгәр аның васыятен үтәмәсә, җаны бервакытта да тынычланмас шикелле... Мөмкинчелеге бар, әтисенең хәле иркен, аның теләгенә каршы төшмиләр – шулай булгач, эш нидә? Бер елдан ул институтны бетерергә тиеш, аннары инде үзең теләгән җиргә барып йөрүләр авыр булачак.

Клара әнә шулай уйлады һәм, җәйге каникул вакытында тиз генә җыенып, ерак Каракошка китеп тә барды. (*Ә.Еники*) (374 сүз)

**«Кайтып күр, кызым, гомер иткән нигезебез шунда, ерак бабаларыңның кабере шунда, сиңа якын түгелмени алар?», – ди иде.** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

| Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Декларага «туган туфрак» төшенчәсе билгесез. |
| 2 | Бабасы иске авылда үткәргән гомерен сагынып искә ала. |
| 3 | Бабасы Кларага авылны кайтып күрергә куша. |
| 4 | Кларaның бабасы каты авырудан соң үлеп китте. |
| 5 | Клара бабасының сүзләрен еш искә ала башлады. |
| 6 | Бабасы алдындагы бурычны үтәргә кирәк. |

**Знче вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме <u>200 сүздән ким</u> булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм таныр лык итеп языгыз.***

**Яшел каләм**

Капка төбенә әллә никадәр кеше җыелган! Елаганнары да, елмайганнары да бар. Соңгы вакытта шулай җыелганнарда елмайганнары күбрәк була башлады. Фронтовиклар кайта! Сукыр-чукракмы анда, аксак-туксакмы – кайта бит әле. Менә Әһлинең әтисе кайта алмас инде, сугышта үлгән ул. Наилнекен көтәләр. Ул Германиянең үзенә үк барып җиткән.

Ләрияне иң элек Разифа әби күреп алды:

- И, тизрәк булсана, бәбекәем. Бар, бар, тизрәк кер, атаң кайтты анда!

Ләриянең тыны-сулышы өтелеп, тамагына әллә нинди төер килеп тыгылды. Чын микән? Әти кайткан? Ләриянең көн саен диярлек төшенә керә торган солдат әтисе, бик сагындырган, бик көттергән әтисе кайткан! Тамактагы төер кайнарланып эчкә йотылды.

- Әти! Мин сине көттем, әти! Яшел каләм алып кайттыңмы, әти?!

Өстәл артында утырган солдат абыйларның погонлысы әти булырга тиеш! Теге икесе, солдат күлмәгеннән булса да, погонсыз иде: берсе – агач аяклы Фаяз абый – әллә кайчан кайтты, икенчесе – Сабантуй Салих – сугышка нәкъ сабан туе көнне киткән сигез егетнең исән калганы – быел сугыштан нәкъ сабан туе көнне кайтты. Бусагадан ук “әти!” дип мүкәләп кергән Ләрияне погонлы солдат күтәреп алырга өлгермәде, әллә кайдан гына килеп чыккан Зәрия апасы аны әтисе кулыннан тартып төшерде.

- Бар икәнсең инде! Шыксыз! Башта битеңне, кулыңны юып, бу сәләмә күлмәгеңне алыштырып кил.

Әтисенең терсәгенә чытырдап ябышкан чәчнәби башта үзен йолкып азапланган апасына тибеп-тибеп алырга уйлаган иде дә, әти алдында анысы ук ярамас дип, сыдырылып идәнгә төште дә, теге ал күлмәге саклана торган фанер әрҗәсен алып, өс алышырга кереп китте.

Зәрия әтисенең электән калган уку-язу әсбапларын барлап азаплана. Күпме барласаң да – юк шул инде алар. Әтисенең үз фәне – математика буенча зәңгәрсу шәмәхә сызыклы яки шакмаклы дәфтәрләргә пөхтәләп язган дәрес эшкәртмәләрен Зәрия үзе тотып бетерде, кайберләре Ләриягә дә эләкте. Укырга

йөри башлагач дәфтәре дә кирәк бит! Бүтән каян аласың? Башкалар төрле гәзит читләренә, теләсә нинди кәгазьгә язганда алар шундый затлы дәфтәрләр белән йөриләр иде әле. Хәдичә апа үзен ничектер гаепле кебек хис итә, иренең кыйммәтле хезмәтләрен саклый алмавына борчыла, Миргарифан абый аны юатырга тырыша:

- Борчылма, әнисе. Син балаларның барысын да исән алып чыккансың. Уку әсбаплары табылыр ул, сатылган портфельләр дә, йорт әйберләре дә табылыр. Иң мөһиме – исән булу! Илнең җиңеп чыгуы, сугышның бетүе.

Әтисе Ләриянең болай да тузган чәчен тузгытып җибәрде дә:

- Әнисе! Теге капчыкның эчке кесәсенә тагын бер кереп чык әле син, анда бу чәчнәби өчен тагын бер нәрсә бар, – диде. Хәдичә апа иренә ялтырап торган яшел төстәге җиз башлы карандаш сузды. 9 май көнне куак төбенә утырып йоклаганда төшендә күргән яшел башлы карандашы иде бу Ләриянең.

- Шул үзе инде, әнисе, шул үзе! Ләриягә ул! Шигырьләр, җырлар язам, ди бит, язсын әйдә! *(К. Булатова)* (413 сүз).

**«Иң мөһиме – исән булу! Илнең җиңеп чыгуы, сугышның бетүе.** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезнераслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Фронтовиклар сугыштан кайта. |
| 2 | Ләриянең әтисе кайткан. |
| 3 | Апасы Ләриягә матур күлмәген кияргә кушты. |
| 4 | Әтисеннән калган дәфтәрләр тотылып беткән иде. |
| 5 | Әйбер табылыр, иң мөһиме – әтисе исән кайткан. |
| 6 | Әтисе Ләрия төшендә күргән яшел каләмне алып кайткан. |

## 4нче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме <u>200 сүздән ким</u> булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

### Дөньяда иң тәмле ризык нәрсә?

Әгәр бу хакта Галәү бабайдан сорасагыз, ул ике дә уйламыйча:

– Көлгә күмеп пешергән бәрәңге, – дияр.

Тик бүген Инсафның тамагыннан аш үтми. Башында һаман бер уй, бер кайгы: аның өч ел буе назлап-иркәләп үстергән тае, ак бәкәлле елгыр кара айгыры югалды. Тартай болынында башка атлар белән утлап йөргән җиреннән, шүрәле урлагандай юкка чыкты. Шул кыбырсыкны эзләп, атна-ун көн эчендә айкамаган урман-кыры, әйләнмәгән болын-тугае калмады малайның. Инде тәмам төшләренә керә башлады. Имештер, аның айгыры канатлы акбүз атлар өеренә баш булып алган да, шулар белән бергәләп, өем-өем ак болытлар арасында зәп-зәңгәр печән утлап йөри. Менә бер заман ул Инсафны күреп ала да көмеш кыңгырау чыңлагандай яңгыравык аваз белән кешнәп җибәрә. Аннары, кара ефәктәй бөдрә ялларын җилдә тузгытып, озын-озын, салмак-салмак ыргылып, түбән төшә башлый. Ләкин төшеп җитүгә, ап-ак ефәк оекбаш төсле ак бәкәлләрен, ялтыр кара тоякларын күз иярмәс тизлек белән уйнатып, өермәдәй чабып китә. Бөдрә яллары Инсафның йөзенә сирпелеп кенә кала. Артыннан куа-куа малай хәлдән тая, шабыр тиргә батып уяна…

Галәү бабай Инсафның хәлен яхшы аңлый.

– Кайгырма, улым, хафаланма ул тикле, – дип, үзенчә тынычландырырга тырыша ул аны. – Кайта, беркая да китми синең таең. Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы…

Бераздан Галәү бабай малайлар белән бергәләп, Идел ярындагы карама төбенә йокларга ятты. Болын җиле тәмле печән исе, җиләкле аланнар исе алып килде. Караманың яфраклары, ашыга-ашыга, нәрсәдер пышылдашып алдылар. Моңсу гына тулы ай күтәрелде. Ул, ботакларны аралап, кешеләргә күз төшереп алды.

Әйе, барысы да йокыда. Оеп, изрәп йоклыйлар. Тик Инсаф кына йокы аралаш елмая, куанып көлә… Җиләс җилләр канатында ерак-еракლардан аңа бик таныш, бик тансык авазлар агылып килә. Көмеш кыңгыраулар авазы!

Һәм колак төбендә һаман бер үк сүзләр яңгырый:

— Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы. *(Габделхәй Сабитов)* (290 сүз)

**“– Кайта, беркая да  китми синең таең. Кадерле ул туган як. Кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы.” –** җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм таныклык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

| Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Дөньяда иң тәмле ризык – көлгә күмеп пешергән бәрәңге. |
| 2 | Инсафның кара айгыры югалды. |
| 3 | Галәү бабай Инсафны юата. |
| 4 | Галәү бабай һәм малайлар йокларга ятты. |
| 5 | Инсаф төшендә көмеш кыңгырау авазы ишетә. |

**5нче вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение элементлары белән киңәйтү изложение текстыннан соң, күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме <u>200 сүздән ким</u> булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Галиянең әтисе фронтта. Ул әтисе белән гел хат алышып тора. Аның хатларында сүзләр дә, хәрефләр дә булмый. Ак кәгазь өстендә бары тик Галия үзе генә аңлый торган кәкре-бөкре сызыклар, төрле фигуралар гына. Абыйсы Касыйм аның хатларына карап көлә генә. Әйдә, көлә бирсен. Ул үзе дә бит әле, инде мәктәптә укып йөрүенә карамастан, әллә ни кыра алганы юк. Дәфтәрләрендә хәтта Галия дә аңламаслык сызыклар гына тулып ята.

Ә менә Галиянең хатларын әтисе укый. Укый да җавап хаты яза. Галия дә әтисенең хатын укый белә. Менә ул, фашистларны кырып бетерәбез инде, дигән, аэропланга атланып, фашистларның окопларына барып кердем, танкка утырып, фашистларның корабларын бастырдым, дигән.

– Әни, Касыйм абый көлмәсен лә, фашистларны әти шулай кыра бит менә, – ди ул яңа гына бүлмәгә килеп кергән әнкәсенә.

– Шулай, шулай, кызым, – ди аңа әнкәсе. – Әтиең бик батыр синең.

– Аэропланга атланып йөриләрмени? Аның белән окопка кереп буламыни? Танк белән диңгезгә кереп корабларны батырып буламыни? – дип, абыйсы аны үртәп ала.

Галиянең моңа да исе китми. Батыр кеше барысын да булдыра, моны Галия белә, ә менә Касыйм, зур булса да, белми икән...

Ул әтисенең хатларын кулына каләм алып укый. Төртеп-төртеп укый.

– Әни, әни! Менә монда әти, тиздән өйгә кайтам, дигән! – дип, кулларын болгап, сикереп үк куйган иде – кара савыты авып китте дә бөтен өстәлне, эскәтерне буяды. Менә харап эш!

Аның янына абыйсы йөгереп килде.

– Менә бу Кара диңгез булды хәзер, әнә шунда кораблар йөздер дә танклар белән аларны кыра башла, батыр кыз!.. Әни кергәч тә, сине тиргәп ташлар бу эшең өчен! – дип ачулана башлады ул.

– Әнигә әйтмик инде, абый җаным, кара үзе түгелде бит, мин тимәдем бит аңа, – дип, Галия акланырга маташтьы.

– Әһә, әнигә әйтмик дисеңме? Син түкмәгәч, мин түккән булып чыгам алайса! Юк, монысы булмас! – дип, Касыйм Галиягә кизәнә дә башлаган иде – тукталып калды, чөнки Галия мышнап еларга да тотынды.

Кич иде инде. Галиягә йокларга вакыт җиткән иде. Ул моннан файдаланырга ашыкты: тизрәк караватына үрмәләде. Әнисе дә:

– Ах, кызым, моның өчен каеш та аз сиңа, эскәтерне бөтенләй харап иткәнсең бит! Җитмәсә, тагын абыеңнан да акыллырак булып кыланган буласың. Бәхетең – йокларга вакыт. Ярый, иртәгә моны исеңә төшерермен әле, үкенеп бетә алмассың! – дип ачулану белән генә чикләнде.

Ай, күңелсез булды Галиягә! Иртәгә әнисе нәрсә эшләтер икән инде аны? Бәлки, онытыр? Ә ничек икән ул «үкенеп бетә алмау»? *(Г. Иделле)* (366 сүз)

**“Ай, күңелсез булды Галиягә! Иртәгә әнисе нәрсә эшләтер икән инде аны? Бәлки, онытыр? Ә ничек икән ул «үкенеп бетә алмау»?”**, – җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтелмәгән өчен 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Галия әтисенә фронтка хатлар яза. |
| 2 | Абыйсы Галиядән көлә. |
| 3 | Галиянең моңа исе китми. |
| 4 | Галия эскәтерне буяды. |
| 5 | Әнисе Галияне ачуланды. |

**6нчы вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение элементлары белән киңәйтү изложение текстыннан соң, күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме <u>200 сүздән ким</u> булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Моннан өч ел элек, сентябрь башында ук, әллә нишләп кинәт кенә катырып җибәрде. Гомер булмаган хәл. Әле кичтән генә җып-җылы иде, югыйсә. Иртән торып тышка чыксам, исем китте: җир шытырдап каткан, баскыч култыксалары җем-җем килә. Арка үзәгем дерелдәп куйгач кына исемә килдем. Инде кереп китим дисәм, әллә каян таш йөрәкләрне тетрәндерерлек тавыш ишетелде. Ачыргаланыплар кычкырды Торна күле ягында бер кошкай. Бер генә кычкырды да тынды бу... Йөрәгем өзелеп төште, дип торам. Хәерле нәрсә түгел бу, дим үземә-үзем. Тиз генә өйгә кереп өскә кидем дә, күл буена киттем.

Калкулыкка килеп бассам, шаккаттым. Кул буендагы иңкүлек мыжгып тора иде. Җыелган торна, өелгән торна. Үзләре дер-дер калтырыйлар. Читтәгеләр уртага керергә, уртадагылары тапталмаска тырыша. Әле берсе, ике икенчесе өскә сузылып бәгырьләрне телеп, үлем авазы сала...

— Әти! Синен арттан мин да йөгердем. Аннары, кешеләр чакырдым.

— Әйе шул. Минем арттан ук Арыслан улым да килеп җиткән. Аны шундук кире йөгерттем. Җыелган халык мондагы торналар саныннан бер дә ким булмагандыр. Кайсы брезент, кайсы колга, кайсы нәрсә ташый. Кемнең башы җитеп киңәш биргәндер, кошкайларның өстенә чатыр корып куйдык. Әле алай гына җылынамы соң алар! Совхозның җылыткычын көйләп җибәрдек...

Өч көн, өч төн карадык торналарны. Дүртәр-бишәр кеше алмашлап тәрбияләдек. Коткардык бахырларны. Берсе генә дә үлмәде.

— Акмуенны әйт әле син, карткаем, — дип Әминә апа да сүзгә кушылды. — Канатлары салынып төшкән, аягында да басып тора алмый иде бит ул...

— Акмуенны әти өйгә алып кайтып җылытты шул, шуңа тиз терелде ул, — дип аңлатты мина Арыслан.

— Акмуенның беренче генә яше иде бугай әле ул елны. Алай да башкалардан калышмады, аякка басты...

Шулай итеп, өч көн катырып торды да, дүртенче көнне җылытты. Төш вакытында торналарыбыз берәм-берәм чатырдан чыгып, канатларын яза башладылар. И сөенүләре, и куанулары! Әйтеп бетергесез инде, малай... Ә киткәндә... — Фаяз абый күзләрен йомгалап, имән бармагы белән күз төбен сөртеп алды. — И әйләнеп тә куйдылар соң баш өстендә. Бер төркеме очып китә дә, иптәшләре тавыш биреп озатып кала... Ә Акмуен, бичаракай, безнең

ишегалдында арлы-бирле йөгеренә. Очып киткән һәр төркемгә ияргә омтыла. Аннан тагын йөгереп килеп күкрәгемә башын куя. Хушлашуыдыр үзенчә... Иң азаккы төркем кузгалгач кына күтәрелде Акмуен.

Фаяз абый, баш бармагына ияге белән таянып, каядыр еракка текәлгән килеш тынып калды. Хәер, ул гына түгел, без барыбыз да уйга чумдык. Кешеләрнең бу яхшылыгы турында сөйләшмичә генә уйланып утыру һәммәбезгә дә бик рәхәт иде. *(Әхмәт Дусайлы)* (369 сүз)

**“Хәер, ул гына түгел, без барыбыз да уйга чумдык. Кешеләрнең бу яхшылыгы турында сөйләшмичә генә уйланып утыру һәммәбезгә дә бик рәхәт иде”,** – җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтелмәгән өчен 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Торна күле ягыннан бер кош кычкырды. |
| 2 | Күл буена торналар җыелган. |
| 3 | Арыслан кешеләрне алып килде. |
| 4 | Кошларны коткардык. |
| 5 | Акмуен иң соңгы булып кузгалды. |
| 6 | Кешеләрнең яхшылыгы күңелгә рәхәтлек бирә. |

**7нче вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение элементлары белән киңәйтү изложение текстыннан соң, күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Караклыкның башы энә урлаудан башлана, диләр. Ялкаулыкның да башы менә шулай кеше хезмәтеннән файдаланудандыр, мөгаен. Шөһрәт баштарак вакыты җитмәгәндә яки үзе аңламаганда гына Гадиләдән күчергәләсә, тора-бара бу аның гадәтенә кереп китте. Кыз да кат-кат каршылык күрсәтмәде, чөнки тагын бер кат: "Үзеңнең миңа бурычлы икәнеңне онытма, мин сине суга батканда коткарган кеше бит", - дигән сүзләрне ишетүдән курыкты.

Укытучы күрмәсә дә, классташлары һәммәсен белеп тордылар. Алар Шөһрәтне үрти үк башладылар. Бигрәк тә ерык авыз Кәшиф җанына тиде.

– Синең эшләр хутта, малай, ә? – диде ул. – Өйгә бирелгән мәсьәләләрне чишеп, баш ватасың юк. Гадиләдән күчердең дә куйдың. Берәр бишлегә укучы кыз бәкегә дә төшми, ичмасам, тартып чыгарыр идем дә үземнең бөтен эшемне шуңардан эшләтер идем.

– Кызыгасыңмыни? – диде Шөһрәт мактанулы тавыш белән.

– Кызыгам!

-Беләсегез килсә, Гадилә минем өчен утка да, суга да керәчәк.

– Суга төшкәнен беләбез инде. Утына да керер – анысына да ышанабыз, әмма кәләш булмас, – диде тыйнак табигатьле Тәлгат.

– Телисезме, бөтен класс алдында Гадиләдән мин синең кәләшең дип әйттертәм?

– Булмый!

– Менә күрерсез.

Класска башка укучылар да җыела башлады. Тәлгат Шөһрәтнең янына ук килеп:

– Әз генә акылың булса, син мондый түбәнлекне эшләмәячәксең, – диде.

– Кем өчен түбәнлек бит, – дип авыз ерды Шөһрәт.

Гадилә класс бусагасын атлауга ук, Шөһрәт аның каршысына килеп басты.

– Гадилә, – диде Шөһрәт кискен генә, – бөтен класска ишетелерлек итеп «мин синең кәләшең» дип әйт әле.

Гадилә үзе белән шаяралар дип уйлап, урынына барып утырмакчы булды, ләкин Шөһрәт аның юлына аркылы төште:

– Әйт. Син бит миңа гомереңбелән бурычлы...

Кыз кинәт агарынып китте. Елмаерга торган иреннәре усал кысылды. Ул Шөһрәтнең мыскыллаудан чалшаебрак торган йөзенә чалтыратып чабып җибәрде.

Класста, әйтерсең бомба шартлаттылар, гөрс итте дә тынды. Гадилә сумкасын да алмыйча, урамга чыгып йөгерде. Шуннан соң гына укучылар шаулашырга, кычкырышырга тотындылар.

Берничә көн Гадилә дә, Шөһрәт тә мәктәпкә килмәделәр. Бераздан классташ дуслары Гадиләнең район мәктәбендә укый башлавын ишеттеләр. Ә Шөһрәт, ярты ел каңгырып йөргәннән соң, шәһәргә һөнәр училищесына китеп барды. *(Ф. Яруллин)* (303 сүз)

**“Кыз да кат-кат каршылык күрсәтмәде, чөнки тагын бер кат: “Үзеңнең миңа бурычлы икәнеңне онытма, мин сине суга батканда коткарган кеше бит”, - дигән сүзләрне ишетүдән курыкты.”,** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм таныրлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтелмәгән өчен 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Шөһрәт Гадиләне үзенә бурычлы дип саный. |
| 2 | Классташлары һәммәсен белеп тордылар |
| 3 | Шөһрәт масая башлады. |
| 4 | Шөһрәт Гадиләне бөтен класс алдында кимсетте. |
| 5 | Аларның юллары аерылды. |

**8нче вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение элементлары белән киңәйтү изложение текстыннан соң, күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме <u>200 сүздән ким</u> булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Ничек кенә авыр булмасын, сугыш вакытында мәктәптә дәресләр тукталмады. Уку көннәре кыскарды, әмма мәктәп ябылмады. Суык та, ачлык та үзәкләрне өзә, әмма авыл малайлары киләчәктә укуның никадәр кирәклеген аңлыйлар иде.

Безнең мәктәптә дә әйбәт укучылар, шулай ук начар укучылар, тәртипле балалар, шулай ук тәртип бозучылар бар иде. Бигрәк тә Зөфәр исемле малай нык җәфалады укытучыларны. Тәртипсез булса да, гадел малай ул. Уйнаганда да, эштә дә хәрәмләшми. Дус та була белә. Ә менә мәктәпне атлап керүгә "җене кузгала", билләһи!

Бер вакыйгадан соң мәктәптә аңа мөнәсәбәт үзгәрде. Хәтта ул үзе дә үзгәрде. Шул хакта бөртекләп сөйләмәкче булам.

Ботаника дәресе иде. Зәмзәмия апа керә. Беркөнне Зәмзәмия апа Зөфәрне "тотты". Иң арткы партада астан гына нидер эшләп утыра иде ул.

Укытучы аның иелгән башын күреп калды да:

— Сәфәргалиев! — диде.

Зөфәр шундук башын күтәрде, сикереп торып, үрә катты. Ул арада идәнгә нәрсәдер шапылдап төшеп китте.

Зөфәр төшкән әйберен иелеп алмакчы булган иде, Зәмзәмия апаның тавышы аны кабат үрә бастырды:

— Сәфәргалиев! Такта янына чык!

Зөфәр болай да артык озын, алга сузылып йөрүче гәүдәсен тагын да бөкрәйтебрәк такта янына узды, класс ягына борылып, теләсәгез нишләтегез дигән кебек, башын иде.

Зәмзәмия апа, дәрес хакында тәмам онытып, Зөфәрне тиргәргә кереште.

Ул арада класс ишегендә мәктәп директоры Нәзиров агай күренде. Коридорда барганда ишетеп калган, күрәсең…

— Нинди тавыш монда? Нәрсә булды?

— Нәрсә булсын, әнә, һаман шул Сәфәргалиев инде…

— Тагын нәрсә?

— Дәрес вакытында астан гына кирәкмәгән эшләр эшләп утыра…

Нәзиров агай Зөфәргә табан борылды.

— Нинди эш ул?

Зөфәр дәшмәде.

— Нинди эш дим?

Зөфәр һаман дәшмәде.

Бу юлы Нәзиров агай үзе барып тикшерергә булды. Зөфәрнең партасы астыннан калын гына китап тартып чыгарды.

Озак кына ул китапның тышына карап торды, актаргалап чыкты, аннары, такта ягына борылып:

— Зөфәр бит әле? — дип сорады.

— Әйе… — Бу юлы Зөфәргә җан керде.

— Менә шул, Зөфәр туган, сиңа бик мөһим эш бирелә. Тиз арада шушы китабыңны укып чык та класс белән әңгәмә үткәр, аңладыңмы?

Нәзиров агай, Зөфәрнең җавабын да көтеп тормыйча, кызу-кызу атлап чыгып китте, ә без, дәррәү килеп, теге серле китап өстенә ябырылдык. Зөфәрнең биш чатлы йолдыз тырналган партасында "Дошманны ничек җиңәргә?" дигән китап ята иде. *(Г. Гыйльманов)* (337сүз)

**"Зөфәрнең биш чатлы йолдыз тырналган партасында "Дошманны ничек җиңәргә?" дигән китап ята иде.",** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтелмәгән өчен 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Сугыш вакытында укулар тукталмады. |
| 2 | Зөфәр, тәртипсез булса да, гадел малай. |
| 3 | Ботаника дәресендә укытучы Зөфәрне ачуланды. |
| 4 | Класска директор керде. |
| 5 | Директор Зөфәрнең партасы астыннан китап тартып чыгарды. |
| 6 | Без барыбыз да китапка ябырылдык. |

## 9нчы вариант

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение элементлары белән киңәйтү изложение текстыннан соң, күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

Беркөнне Мәрьям белән Рөстәм өйдә икәү генә калдылар. Әбиләре ерактагы апаларына кунакка киткән иде. Ә әниләре: «Мин кибеткә генә кереп чыгам, хәзер кайтам, карагыз аны, шаярмый гына торыгыз, өйне туздырмагыз», – дип чыгып китте. Мәрьямгә: «Син, Мәрьям кызым, апа кеше, акыллы гына бул, Рөстәмне кара. Ул кечкенә, акылсыз әле, кирәкмәгән әйберләргә тотынмасын!» – дип әйтеп калдырды.

Мәрьям белән Рөстәм, икәү генә калгач, акыллы гына итеп уйный башлаганнар иде дә, уйный торгач, әниләре әйткәнне онытып җибәрделәр.

Мәрьям шкафны ачты да, утыргычка менеп, сурәтле китап эзләргә тотынды. Ә Рөстәм, Мәрьям апасы китап эзләгән арада, «Акбикә» исемле курчагының бер күзен чокыды. Ботинкасын ишек төбеннән алып, кровать өстенә китереп куйды. Идәнгә тоз түкте. Аннан соң, утыргыч куеп, өстәлгә менде дә, одеколон шешәсен алып, көзгегә суга башлады. Рәстәм одеколон шешәсен өстәлдә калдырган булган икән, идәнгә төшерде дә җибәрде. Идәнгә одеколон түгелде. Мәрьям тиз генә пыяла ватыкларын җыйды да, одеколонны сөртеп алырга дип, чүпрәк эзләргә китте. Ул арада Рөстәм утыргычтан төшкән дә, идәнгә түгелгән одеколон өстенә утырган. Одеколон бит әле ул әчеттерә. Менә Рөстәм елый башлады. Мәрьям нишләргә дә белми. Аның үзенең дә елыйсы килә. Елар иде, өйдә Мәрьямнән зуррак кеше юк. Энекәшен юатырга тотынды. Рөстәм һаман елый. Мәрьям, апа кеше булгач, ачулана башлады.

– Елама, тискәре малай. Менә хәзер әни кайтып керсә, нишләрбез? Менә тагы, әти кайткач, әтигә дә әйтер әле.

Шулай дигәч, Рөстәм елаудан туктады. Алар шулай сөйләшеп торганда, өйгә бер зур кеше килде дә керде. Өстенә гимнастерка кигән, башында фуражка, кулына чемодан тоткан.

– Әниегез кайда? – ди.

– Кибеттә, хәзер кайта.

– Әбиегез кайда?

– Ерак апаларда кунакта... әтиебез сугышта.

Теге кеше көлеп куйды.

– Ә синең исемең ничек?

– Мәрьям.

Кеше тагын да ныграк көлеп, Рөстәмгә иелде.

– Ә синең исемең ничек?

Теге кеше әйтте:

– Мине таныйсызмы?

– Юк.

– Ә мин сезнең әтиегез. Мин сугыштан кайттым инде.

Мәрьям ул кешегә ышанырга да, ышанмаска да белми. Ә Рөстәм «әттә, әттә» дип, әтисенең алдына менеп тә утырды.

– Фу, фу, – диде әтисе, – сез әллә мин кайтуга бизәнеп тордыгызмы? Одеколонга манчылгансыз.

Мәрьям дә, әтисе дә көлеп җибәрделәр. Әтиләре икесен дә үбеп алды. Ул арада әниләре дә кайтып керде. Әй шатландылар бары да, әй шатландылар! Әниләре Мәрьям белән Рөстәмне ачуланырга да онытты. Әтиләренә дә әйтмәде. Болай булгач, әтиләре хәзер аларга чемоданындагы бүләкләрен, күчтәнәчләрен дә чыгарып бирә инде. Мәрьям белән Рөстәм үзләре дә моннан соң болай шаярмаслар. Әниләре әйткәнне дә, әтиләре әйткәнне дә, әбиләре әйткәнне дә тыңлап кына торырлар. (*Мирсәй Әмир*) (380 сүз)

**“Мәрьям белән Рөстәм үзләре дә моннан соң болай шаярмаслар. Әниләре әйткәнне дә, әтиләре әйткәнне дә, әбиләре әйткәнне дә тыңлап кына торырлар..”,** – җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтелмәгән өчен 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Мәрьям белән Рөстәм өйдә икәү генә калдылар. |
| 2 | Алар өйне туздырдылар. |
| 3 | Өйгә гимнастерка кигән бер зур кеше килеп керде. |
| 4 | Ул балалардан әниләре, үзләре турында сорашты. |
| 5 | Зур кеше үзенең әтиләре булуын әйтте. |
| 6 | Әниләре кайтып керде, барысы да шатланды. |

## 10 нчы вариант

***Текстны тыңлагыз һәм киңәйтелгән изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Сочинение элементлары белән киңәйтү изложение текстыннан соң, күтәрелгән проблемага туры китереп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм таныргылык итеп языгыз.***

1942 елның башлары иде. Мин өченче сыйныфта укып йөрим. Бер көнне, дәрес вакытында, кемдер сыйныф ишеген шакыды. Укытучы апабыз ашыгып ишеккә юнәлде... Бераздан ул безгә:

– Балалар, Ахун абый килгән, аның сезгә әйтер сүзе бар. Басып каршы алыгыз, – диде.

Ахун абый:

– Утырыгыз, балалар... Бер гозеремне тыңласагыз иде. Атлар абзарында яңарак кына туган бик матур колыныбыз үлем хәлендә ята. Кайсыгыз да булса шул колынны өенә алып кайтып исән калдыра алса, үзегезнеке булачак. Сүз бирәм! Уйлап карагыз әле, йә, кайсыгыз тәвәккәлләр икән?!.

Тынлык... Башлар иелгән... Сугыш бит ул үзе белән бергә ачлыгын да алып килә. Бу балаларның байтагы үзләренең туйганчы ашаган чакларын инде хәтерләми дә бугай.

– Абый, мин алып карыйм әле... – дип әйткәнемне сизми дә калдым.

– Бәрәкалла! Ялгышмасам, син Кәшифәттәй малае бит әле, әйеме? Сөт эчерә алсагыз, колын исән калачак!

Өйгә кайтып керү белән, әнигә барысын да сөйләп бирдем.

– И-и, бала, ат җене кагылган шул сиңа, ат җене... Бигрәкләр дә мал җанлы бала шул син, улым... Йә, бар инде, чананы лапастан ал да йөгер!

Абзарга килеп керсәм, ябык, чем-кара бер колын сузылып ята. Күзләре йомык. Эчем жу-у итеп китте, тыным кысылды. Елап җибәрдем.

Үлгән колынны жәлләп җылавымны ишеткәнме, әллә каян гына ат карауачы Саттар абый килеп чыкты.

– Саттар абый, үлгән бит бу колын,– дим, ә үзем һаман елавымнан туктый алмыйм.

– Юк, олан, исән әле, исән ул! – ди Саттар абый. – Җә инде, егет кешегә яшь агызып тору бер дә килешми. Менә, егет булгач, колын да үлемгә бирешмәскә тырыша. Әйдә, балакай, чанаңны мондарак китер, икәү күтәреп салмый булмас: яңа туган булса да, авырлыгы җитәрлек моның, ат токымы бит... Һай, әгәр дә исән-имин үстерә алсаңмы?! Нәселле айгыр булачак бу!

Шулай икәүләшеп чана тарта-тарта өйгә җиткәнебезне сизми дә калганмын. Колынны идәнгә кертеп салдык. Әни җылымса гына итеп сөт әзерләп куйган. Сөтне кашык белән колынның авызына сала башладык, әмма колын аны йотмады, сөт агып төшә торды. «Булмас, ахры, бу» дигән шомлы

уйдан өметем киселеп барганда, колыным беренче йотымын йотмасынмы! Озак та үтмәде, күңелләребезгә шатлык өстәп, күзләрен дә ачып җибәрде бу! Менә сөенеч кайда икән ул!

Колыныбызга Барса дип исем куштык. Атна-ун көн эчендә Барсабыз тәмам ныгыды, тернәкләнде бит, әй! Шаянлыгына, кыланмышларына түзәр хәл калмагач, тоттык та җылы абзарга чыгардык үзен. Мин Барсаны әкренләп өйрәтә башладым.

Шулай бер-бер артлы атналар, айлар үтте. Торган саен зирәкләнә баруы белән колыным күрше-күләнне дә гаҗәпкә калдыра башлады. Ул үзенең шатлыгын да, үпкәсен дә, «рәхмәт»ен дә матур итеп аңлата, кешеләрнең тел белән әйтүенә караганда да үтемлерәк итеп аңлата белә иде. *(Г.Галиева)* (396 сүз)

**"«Булмас, ахры, бу» дигән шомлы уйдан өметем киселеп барганда, колыным беренче йотымын йотмасынмы! Озак та үтмәде, күңелләребезгә шатлык өстәп, күзләрен дә ачып җибәрде бу! Менә сөенеч кайда икән ул!** – җөмләләрендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме **200 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

| **Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| 1 | Ахун абый үзенең гозерен әйтте. |
| 2 | Мин колынны алырга теләк белдердем, әнием каршы килмәде. |
| 3 | Абзарда хәлсез колын ята. |
| 4 | Колынны өйгә алып кайттык. |
| 5 | Атна-ун көн эчендә колыныбыз тернәкләнде. |
| 6 | Барса бик зирәк булып үсте. |

## Язма эшне бәяләү критерийлары

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган. | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма** бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән). | 0 |
| **ИК2** | **Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән. | 2 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма** бер логик хата бар<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар. | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** бердән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән. | 0 |
| **ИК3** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **ИК4** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (**матур әдәбиятка караган 2 дәлил-мисал** китергән). | 4 |
| | Укучы **2 дәлил-мисал** китергән, шуларның **берсе матур әдәбиятка** карый. | 3 |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2 дән ким булмаган дәлил китергән) | 2 |
| | Укучы **1 дәлил-мисал** китергән. | 1 |
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | китермәгән, **яки** укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | |
| **ИК1-ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | **10** |

**Игътибар!**

Әгәр изложениедә сочинение элементлары булмыйча, текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча (ИК1-ИК4) 0 балл белән бәяләнә.

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм анық фактик төгәллеге** аерым бәяләнә (2 нче таблицаны кара).

*2 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк. | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар. | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар. | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, **изложениенең күләмен** исәпкә алырга кирәк. Язма эшнең гомуми күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш.

2 нче таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 200 дән артык сүз булган изложениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр **изложениенең** гомуми күләме 150-199 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК – 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК – 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр **изложениенең** гомуми күләме 100 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **20.**

## Татар әдәбияты
## 71нче код биремнәре

### Аңлатма язуы

Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек өчен материаллар 9 нчы сыйныфта имтиханга әзерләнүчеләргә йөз тотып төзелде. Аның төп максаты – укучыларга сайлап алу имтиханына мөстәкыйль әзерләнергә юнәлеш бирү.

Әлеге материаллар укучыларда контроль бәяләү материалларының структурасы, биремнәрнең күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм гомумән киң җәмәгатьчелектә бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый.

Әлеге мәгълүматлар барысы да укучыларга татар әдәбиятыннан сайлап алу имтиханына әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итәр.

### Биремнәрне башкару өчен күрсәтмә

Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эше 2 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлек тәкъдим ителгән әдәби текстларга эчтәлек һәм форма ягыннан бәя бирүне күздә тота. Текстларны башта игътибар белән уку, бары шуннан соң гына әсәргә яки тәкъдим ителгән өзеккә карата куелган сорауларга җавап бирә башлау мөһим. Беренче бүлектә ике вариант тәкъдим ителә. Укучы үз теләге белән шуларның БЕРСЕН генә сайлап алып эшләргә тиеш. Эпик яки драма әсәренә анализны эченә алган беренче вариантта киңәйтелгән җавап таләп иткән 3 сорау тәкъдим ителә.

Лирик әсәргә анализны эченә алган икенче вариантта киңәйтелгән җавап таләп иткән 3 сорау бирелә.

Беренче бүлектәге беренче һәм икенче вариантлардагы 1.1.1., 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәренә җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә, 3-5 җөмлә күләмендә формалаштыру мөһим. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Өченче бирем исә (1.1.3. һәм 1.2.3.) чагыштырма планда җавап язуны таләп итә һәм аны 5-8 җөмлә күләмендә формалаштыру сорала.

Өченче бүлек дүрт сочинение темасын үз эченә ала. Алар аерым әсәрләргә мөнәсәбәтле кечкенә күләмле сочинение язуны күздә тота. Җавап бирү барышында шуның БЕРСЕНӘ генә сочинение форматында 150 сүздән дә ким булмаган сочинение язу сорала, 100 сүздән дә ким булган язмалар 0 балл белән бәяләнә.

Биремнәрне башкару өчен 210 минут вакыт каралган. Эшнең беренче бүлеген башкару өчен – 2 сәгать, өченче бүлекне үтәүгә калган вакыт күздә тотыла.

## 1нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Көн әле кич булмаса да, Гарифка төн кебек тоела иде. Ул чикмәнгә бик нык төренгәнгә күрә, тәрәзәдә улаган җил һәм дулкын гөрләүләре аермачык ишетелми. Тик әллә кайсы почмакта, гүя әллә кем акрын тавыш белән, ярсуланып-ярсуланып, бертуктамый елый иде... Аһ, мескен, кем соң син?.. Гарифның әнкәсе генә шулай елый иде... Әнә аның әткәсе кара күзле, таза гәүдәле, исерткечкә дучар булучы мулла... Ул балаларын, якыннарын бик сөя, ләкин аны сөюче юк... Менә ул базар авылыннан пар ат яллап кычкыра, җикерә, җырлап кайта... Әнкәсе тавыш чыгармый, бер җирдә качып, әкрен генә елый... Әнә ул хәстә, балаларын чакырып-чакырып берәмләп үбә, салкын куллары белән башларыннан сыйпый... Менә аның урынын тартып алган «сары җиләнле мулла» инде аның җеназасы өстенә иелеп, бөгелеп, әрле-бирле йөгерә... Бу чагында инде әнкәсе тавышсыз түгел, өзелеп-өзелеп тавышлап ярсый...

Гариф шушы күңелсез хатирәләргә бирелеп торган чагында, кинәт ишек ачылып аны сискәндерде. Чикмәнне азрак ачып карагач, бераз аптырап китте: Газизә кергән иде.

– Гариф абый, йокламыйсың икән... Юеш әйберләреңне әнкәй сораган иде, кухняга илтеп җәясе үзләрен... – диде.

Гарифның бер читкә ташлаган фуражкасы белән күлмәкләрен Газизә җыештырып алып чыкканда, Гариф утырган җиреннән: «Мәшәкать булыр, борчыласыз, Газизә... » – дип сөйләнеп калды.

Газизә чыгып киткәч, ул беркадәр аптыранган рәвештә ишеккә карап торды-торды да, тагын бөркәнеп ятты. Кайсыдыр бер почмакта әллә нинди моңлылык эчендә һаман бернәрсә елый иде. Ләкин бу юлы аның елавы Гарифның күңелендә тупас өметсезлекләр, ачы кайгылар салмый, бәлки аның күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык катыш эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде. Аз гына элек Гарифны кара хатирәләр, тупас өметсезлекләр белән газаплаган шушы билгесез моңлылык гүя аны юата, иркәли, шатланырга, шатланып, үзе белән бергә еларга куша...

Киң күкрәкле, юлбарыстай көчле һәм матур егет иске чикмән астында әкрен генә елый иде.

*Ш.Камал «Акчарлаклар»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: «*Кайсыдыр бер почмакта әллә нинди моңлылык эчендә һаман бернәрсә елый иде. Ләкин бу юлы аның елавы Гарифның күңелендә тупас өметсезлекләр, ачы кайгылар салмый, бәлки аның күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык катыш эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде*». Гариф күңелендә барган мондый үзгәреш нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Гариф холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ш.Камалның «Акчарлаклар» повестенда Гариф һәм Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә Айдарның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның Газизәгә һәм Вәсиләгә мөнәсәбәтендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Атын күргәнмен, арбасын күргәнмен, алмасын күргәнмен, ә менә алма әрҗәләре арасында кысылып утырган кечкенә генә кызны, түгәрәк ак беләкле, кап-кара күзле, башына салам эшләпә кигән кызны моңа чаклы күрмичә торганмын. Алма сатучының үз кызыдыр инде ул, шөпшә төслерәк икән. Алай дисәң, шөпшәнең күзләре кара булмый бугай. Нинди була соң әле шөпшәнең күзләре? Аты әйбәт, арбасы әйбәт, алмасы әйбәт, ә кызы барыннан да әйбәтрәк. Шөпшә төсле дип юри генә әйттем мин, бөтенләй шөпшә төсле түгел.

Бүтәннәр алма карыйлар, мин кыз карыйм. Кыланчык нәрсә икән, эшләпәсенә ал лента бәйләгән булган. Безнең авылныкы булса, мин аның эшләпәсен чәнчә бармак белән эләктереп алыр ием дә, өй түбәсенә атып бәрер ием. «Алып бир дә, алып бир», – дип, соңыннан минем тирәмдә тик бөтерелеп йөрсен. Безнең авылныкы түгел шул. Әллә, алма караган булып, якынрак килеп караргамы? Әтисе күрер каһәрнең. Алма чәлдерергә йөрисең, дип борынга чиртер. Шулай да арбага якынрак елышам, арт карамага тотынам. Бушаган әрҗәләргә поса төшеп, кызга якыннанрак карап торам. Шактый ук озак карап торам, ә ул күрми дә күрми. Ә күрсен иде, каһәр. Бер дә булмаса, әтисе күрсен иде. Ә болай берсе дә күрми. Әллә арба тәгәрмәченә басып караргамы? Бастым. Кинәт үсеп киттем. Кызны хәзер колак йомшакларына чаклы күрә башладым. Әллә агач ботагында алма белән бергә үстеме икән ул? Битләре нәкъ алма

төсле. Чәчен зәңгәр лента белән кушып үргән, маңгае ап-ак, күзләре түгелергә торган төсле. Ә үзе шул кечкенә генә куллары белән үлчәү тәлинкәсе тирәсендә маташкан була. Герләр алып сала, алма тутырыша, мине ичмасам бар дип тә белми. Ачуымны китерсә, чәч үргеченнән тартырмын әле. Уйлавым булды, тартуым булды. Карамас җиреннән карады кызың. Карады, аннары көлеп җибәрде. Тешләре уенчык төсле ап-ак. Алма ашап шулай агарып беткәндер инде ул, дим эчемнән генә. Ә үзем, күземне терәп, карап тик торам. Кыз үлчәү тәлинкәсе тирәсендә бераз маташты да тагын борылды, тагын миңа карады. Бу юлы инде мин аның бит очындагы кечкенә миңенә чаклы күреп калдым. Әйбәт кыз, әйбәт. Безнең авылныкы булса, мин аның хәйләсен табар идем, колак йомшагыннан гына тешләп алыр идем, безнең авылныкы түгел шул.

Дөресен генә әйткәндә, әллә ни эшләдем мин. Алманың исен сизми башладым, үземнең Кәҗә Шаяхмәт малае гына икәнлегемне оныттым, ә Госманнар әнә һаман шул тирәдә чуалалар. Берсе, берәүгә дә сиздермичә, эләктерде дә бугай, ахры. Алма сатучы килер дә китәр, иптәш малайлардан аерылырга ярамый. Ачык авыз, дип соңыннан үртәп йөдәтүләре бар үземне.

Мин арбадан бер читкә китәм, берсенә дә карамаган бер төс белән басып торам. Кыз күтәрелә дә карый, тешләрен күрсәтә. Үзем дә сизми калганмын, минем дә тешләр күренеп киткән тегеңә. Шуның артыннан озак та тормады, ул кыз бик зур, бик матур бер алманы сайлап алып, этисе күрмәгәндә генә, миңа атып бәрде.

Мин инде бик әйбәтләп кенә тотып алдым. Аннары нәрсә булган, – берсен дә белмим. Ник дисәң, кинәт башым әйләнеп китте минем, өйгә йөгердем. Малайларның әйтүенә караганда, аннары ул алма сатучы, атын җай гына атлатып безнең авылдан чыгып киткән. Кая киткән? Берәү дә белми. Авылдан чыккан чакта аның кызы бушаган әрҗәләр өстенә утырып, арбадагы бөтен әйберләрдән, этисенең үзеннән дә, атның дугасыннан да биегрәк булып, озакка, бик озакка чаклы күренеп барган. Аның зәңгәр ленталары белән җил уйнаган, ә ул үзе басу капкасын чыкканнан соң да каерылып-каерылып безнең авыл ягына таба карап барган.

Ә Госман, курнос борын, мине мыскыл итмәкче була.

– Алма сатучының кызы алманы сиңа дип атмады, үлчәү тәлинкәсенә салам дигәндә кулыннан ялгыш төшеп китте, – ди.

Мәтәштерми генә тор. Ялгыш кына төшеп киткәч, нигә соң ул минем кулга килеп эләккән, нигә Госман кулына эләкмәгән?

Дусын дус та син, Госман, шулай да әллә нәрсә генә бар синдә. Нигә инде кешене алай үртәргә. Бүген алма сатучы узган, иртәгә кыяр сатучы узар. Безнең Янбулат урамы киң ич ул. Шулай да, күп бәхәсләшеп тормыйча, әйдә су кереп кайтыйк әле. Әллә нәрсә, бик эсселәп торам мин бүген.

Күз ачып йомганчы без, Госман белән икәү, тегермән буасына су керергә йөгерәбез. Ә теге алма һаман кулымда…

*Ф. Хөсни «Йөзек кашы»*

## Вариант 2

Сөйләр сүзләр бик күп алар,
Иренмичә сөйләсәң;
Озын сүзнең кыскасы шул,
Күп яшәргә теләсәң:
Үлем турында уйлама,
Илең турында уйла,
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

*Ф.Кәрим «...Сөйләр сүзләр бик күп алар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** «*Илең турында уйласаң, / Гомерең озын була*» юллары белән Ф.Кәрим нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик төргә хас нинди үзенчәлекләрне билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Ф.Кәримнең «...Сөйләр сүзләр бик күп алар» һәм М.Җәлилнең «Соңгы җыр» шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Җир йөзе шундый киң,
Күңелле һәм якты!
Тик төрмәм караңгы,
Ишеге йозаклы!

Күктә бер кош оча,
Югары, югары!
Мин ауныйм идәндә,
Кулларым богаулы.

Тышта бер гөл үсә
Яңгырга коенып;

Мин кибәм, мин сулам
Төрмәдә боегып.

Мин беләм: бик татлы
Да яшәү тойгысы!
Тик инде мин үләм,
Бу җырым – соңгысы!..

*М.Җәлил «Соңгы җыр»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында автор идеалы.

**2.2.** Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә мәгърифәтчелек идеяләре.

**2.3**. М.Колый хикмәтләрендә суфичылык мотивлары.

**2.4**. К.Насыйри иҗатында әхлаклылык проблемасы.

## 2нче ВАРИАНТ
## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

*Хәлил (моңаеп кына җырлап килә).*

Аклы ситсы күлмәгемне
Саламын да киямен;
Ярым ятлар белән уртак,
Янамын да көямен.

*Галиябану (урталыкта суын җиргә куеп).* Җаным, мин ул Исмәгыйль эшне чуалтыр дип куркам.

*Хәлил (юатып).* Бернәрсә дә эшли алмас, бер әти-әниеңнең дә күнүе белән булган эшне ун Исмәгыйль дә боза алмас. Бөтен авыл безнең якта. Ялгыз Исмәгыйль әллә кая бара алмас.

*Галиябану (бик борчулы).* Белмим шул. Ул әллә нинди яла ябудан да тартынмас. Бигрәк яман күңелле кеше икән инде. Миңа эт кебек ябышты бит... Әллә ни, әтиләрне айнытмагае дип куркам.

*Хәлил.* Әтиләрең айныганнан аңа ни файда да, безгә ни зыян? Азрак безнең эш мәшәкатьлерәк чыгар, бары шул.

*Галиябану.* Безнең әти бик аумалы кеше ул. Шунлыктан күңелем бик шикләнә башлады. Исмәгыйль, мөгаен, әтиләрне айнытыр.

*Хәлил.* Әйтәм бит, җаным. Алар айныганнан безгә ни зыян?

*Галиябану.* Ни зыян дисеңме? Элек Гыйльметдиннәр Фатыйманы бикләп куйган кебек, мине бикләп куярлар. Аннан Исмәгыйльгә никах укытырлар да, төяп җибәрерләр.

*Хәлил.* Син әтиләреңне шуны эшләрләр дип уйлыйсыңмы?

*Галиябану.* Әти дә, әни дә Исмәгыйльгә сатылмагайлары дип куркам.

*Хәлил (уйга кала; бераздан).* Соң нишлик дисең, Галиябану?

*Галиябану.* Зинһар, бер юлын тап! Минем акылым ирешми.

*Хәлил.* Алайса, менә нәрсә, Галиябану. Без хәзер сабыр итеп торыйк. Әтиең каладан кайтсын. Әгәр Исмәгыйль чынлап эшне болгатып, әтиләрең айнысалар һәм ызалый торган булсалар, шул ук төнне Көмшәр авылына качарбыз да, никах укытырбыз.

*Галиябану.* Алар бит мине бикләп куярлар.

*Хәлил.* Син аларның айныганын сизгәч тә, алар яклы бул, мин Хәлилне ташладым, диерсең. Шуннан сине бикләмәсләр. Авыл тынгач, мин синең тәрәзәңә барырмын да, Көмшәргә сызарбыз.

*Галиябану.* Ярый ла син килсәң. Бер-бер сәбәп белән килә алмасаң?.. Мин аннан соң харап булам бит.

*Хәлил.* Юлыма таш яуса да, бармый калмам, вәгъдә бирешкән чактагы, «сөйгәне өчен корбан булудан яшь егет баш тартырмы», дигән сүзне мин уйнап кына әйтмәдем. Тик үзең, теге хәйләне онытма!

*Галиябану.* Ярый, мин күнәм. Синеке булып калыр өчен тау тишеп чыгарга да ризамын. Кинәт кенә бәхетле булдым дип куанган идем. Никадәр кыеннар, никадәр сүзләр ишетәсем бар икән әле.

*М.Фәйзи «Галиябану»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Синеке булып калыр өчен тау тишеп чыгарга да ризамын. Кинәт кенә бәхетле булдым дип куанган идем. Никадәр кыеннар, никадәр сүзләр ишетәсем бар икән әле».* Галиябану күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Галиябану холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында Хәлил һәм М.Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә Хисаметдин менланың кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның характер сыйфатларында нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

...Кышкы вакытларда хикәябездә язылган затларның тормышлары гадәтенчә кичеп, дикъкатькә лаек бер нәрсә дә юк иде. Белешләребез Гали бай вә Сибгатулла әфәнде сәүдә эшләре белән мәшгуль улып, бу көн – Мәскәүдә, иртәгесен – үз шәһәрләрендә вә берсекөнне бер сәүдә үзәгендә вакыт уздыралар иде. Белешебез Бикбулат мулла үз вазифасын үтәү белән мәшгуль улып, муллаларга садака бирергә кирәклекне мәхәлләсенә киңәш итеп вә кисәтеп-искәртеп, аучы куян вә үрдәкне өмет итеп саклаганы кебек, бу да никахлар өмет итеп сакламакта иде.

Белешебез Хәнифә туташ тегү тегеп, китап укып вакыт уздырмакта иде. Белешебез Хисаметдин менла, сабыйларны укытудан башка, арыш вә солыларын суктырып вә сатып кәсеп итеп, эшсез һич ятмас иде. Чөнки бу кеше укымыш улып, белер иде ки, кәсеп вә эш шәригать буенча намаз вә руза тоту

кеби фарыз вә гыйбадәттер. Әмма кыш кичеп, яз башлары җитү белән, Хисаметдин менланың тормыш рәвеше бераз алмашынды. Кыш вакытына караганда хәзерге заманда шәһәргә күбрәк барырга гадәтләнде. Моның асыл сәбәбе бу ки, язганыбыз Хәнифә белән очрашуы менлага бик көчле тәэсир итте, шәһәргә барган вакыт Габбас агайга төшәр иде вә йортта, капка алдында яисә урамда Хәнифәне очратырга тырышыр иде. Вә күп тапкыр морадына ирешер иде. Ахрысы, Хәнифә туташка да менла белән очрашкалау хуш иде, чөнки туры килгән вакытларда кыз белән егет бер-берсенә карашып уза башладылар.

Менланың шәһәргә еш килгәләп йөрүе дикъкатьсез калмыйча, беркөн Габбас ага да, аңа эндәшеп: «Менла, син шәһәрне ярата башладың, элекке вакытларга караганда хәзер күбрәк киләсең», – диде.

– Әйе, Габбас ага, һәрвакыт эшләр белән киләмен; аны-моны алырга кирәк була, үзем килмәсәм, минем эшемне кем эшләсен? Мин ялгыз бит, – дип җавап бирде Хисаметдин менла.

Әмма бу килешендә Хисаметдин бик уңышлы вә бәхетле булды. Гүзәл Хәнифәнең чистарынып-таранып, киенеп-ясанып базарга чыгып китүен менлабыз тәрәзәдән күрде. Бераздан, халыкка белдермичә, гүя үз эшенә киткән кебек, мөсафирханәдән чыкты вә, бер-ике йортны узгач, Хәнифә туташны куып җитте. Вә узып киткән чагында яшь егет әйләнеп караганда, кыз шәкәр иреннәрен вә энҗе тешләрен күрсәтеп көлеп алды. Менла да, чын күңелдән шатланып, кызга гыйшыклык көлкесе илә җавапланды. Ике яшь, бер-берсенә багышып, бәхетле булдылар. Халыкның дикъкате тупланмасын дип, менла, бераз калып, кызның артыннан китте. Хөрмәтле укучыларым, хәзер, әлбәттә, аңладыгыз ки, бу ике яшь бер-беренә гашыйк улмышлар.

Бара торгач, яшь кыз бер кибеткә керде. Шәһәр тротуарларында йөрегән адәмнәр һәрвакыт күп булганлыгы мәгълүмдер; кем кемгә кирәк, һәркем үз эшендәдер. Менлабыз, кибеттән ерак китмичә, йөренеп калды. Гаҗәптер ки, әүвәл вакытларда менлабыз кызны узып киткәндә күрсә дә бик шат була иде, ә инде хәзер бер күрү белән генә канәгатьләнмичә, морады янә артты. Вә хис итте ки, йөрәге кыз белән еш хәбәрләшмәкне, күрешмәк вә күзгә-күз сөйләшмәкне тели. Гыйшыклык шулай ул. Ахыр чиктә, кыз кибеттән чыккан вакыт, Хисаметдин менла тугры аңа каршы барып узганда, әкертен генә бу сүзләрне әйтеп алды: «Хәнифә ханым, иртән таң илә бакчада сарайдан егерме бишенче казык төбендә, таш астында бер гаҗәеп нәрсә табарсыз. Алла өчен, алып карагыз, үтенәмен!» – вә сүзләрен бетереп узып китте. Хәнифә туташ исә, бер җавап та бирмичә, туры өенә китте.

*М. Акъегет «Хисаметдин менла»*

**Вариант 2**

Тагын узды кыңгыраулы язлар,
Чылдырдатып чәчкә чукларын.
Беләсеңме, кәккүк, бу юлларның
Кая җитеп, кая туктарын?

Юк, әйтми тор әле, чү, әйтми тор,
Гомер елын бик аз санама.
Сабый чактан көткән ал җилкәндәй
Җәйге таңнар һаман аллана.
Килә дә ул, китә. Ә мин һаман
Зәңгәр ярга барып җитмәгән.
Күңелемдә йөрткән сүзләремне
Кулъяулыкка әле чикмәгән...

*С.Сөләйманова «Тагын узды кыңгыраулы язлар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Килә дә ул, китә. Ә мин һаман / **Зәңгәр ярга барып җитмәгән»*** юллары белән С.Сөләйманова нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** С.Сөләйманованың «Тагын узды кыңгыраулы язлар» һәм Ф.Кәримнең «Бездә яздыр» шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы, төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз
Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман, кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман

Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән таланган.

Фашист тырнагына капкан кеше
Сыкрамыйча монда тын алмый,
Янган авылларның төтеннәре
Язгы таңның нурын томалый.

Фашист илгә үлем генә китерә,
Фашизмның таңы, язы юк.
Яшен уты белән күккә язып әйтәм:
Язы юкның яшәү хакы юк!

*Ф.Кәрим «Бездә яздыр»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә романтик геройлар.

**2.2.** Заһир Бигиевның «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә күтәрелгән проблемалар.

**2.3**. Каюм Насыйриның «Әбугалисина» кыйссасында автор югары күтәргән сыйфатлар.

**2.4**. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә Йосыф һәм Зөләйха образлары.

**Зnче ВАРИАНТ**
**1 БҮЛЕК**

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

**Вариант 1**

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр. Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәр»не җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнгәме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә яки тиктомалга яндыра да башлый. Менә бүген дә гел туңып тора, аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк», – ди ул, үз-үзенә иренеп кенә һәм авылга таба борыла.

Бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән?

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Аның хәзер бер генә эше бар – ул ялан таптарга ярата. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да төгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр.

Карт әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач, дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

– Нихәл, арумы, Миңлебай агай? – диде.

– Каян кайтып киләсең болай? – диде карт.

– Менә кизәк җыярга чыккан идем.

– Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

– Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора, – диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

– Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, – диде карт. – Ярый, кортка, юлыңда бул! Һәм карт озын аякларын сыга биреп китеп барды.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗалы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде.

*Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы».* Миңлебай карт мондый җавабы белән нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Акъәбинең тормышындагы һәм холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Әсәрләрнең сюжетына нигезләнеп, Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә Акъәби һәм Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында Әлмәндәр образларын чагыштырып карагыз. Аларның дөньяга карашында, башка кешеләргә мөнәсәбәтендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

*Әҗәл*. Мин үлемсез. Үлемсез булу начар, Әлмәндәр. Үлү зур бәхет ул. Сез кешеләр шуңа бәхетлеләр. Минем миллиард ел яшәвем сезнең бер ел гомерегезгә тормый. Сез төзисез, сез өмет белән яшисез. Минем өмет юк, мин җимерүче.

*Әлмәндәр.*Җимермә, кем куша җимерергә.

*Әҗәл*. Дөнья шулай корылган, Әлмәндәр.

*Әлмәндәр*. Әйдә ярар, кадакла.

*Әҗәл*. Ял итик бераз.

*Әлмәндәр*. Алып китәм, дисең инде, ә?

*Әҗәл*. Шулай итәргә туры килә, Әлмәндәр.

*Әлмәндәр*. Хәзер үк дисең инде, ә?..

*Әҗәл*. Шаярма, Әлмәндәр...

*Әлмәндәр*. Хет ун ел.

*Әҗәл*. Булмый.

*Әлмәндәр*. Бер ел.

*Әҗәл*. Әйтәм бит, Әлмәндәр, булмый. Ярамый.

*Әлмәндәр*. Бер ай, бер атна...

*Әҗәл*. ...Әмма дә ләкин сабыр гына уйлап кара әле, Әлмәндәр. Тагын, әйтик, утыз ел яшәдең ди. Ул яшәүнең ни кызыгы? Кемгә кирәк син?

*Әлмәндәр*. Шаярма, Әҗәлетдин. Үзең ишеттең, присидәтел, лифкавай машинасы белән бакча янына туктап, нәрсә диде? Печән өябез, нигә эскерт башында торырга чыкмадың, Әлмәндәр бабай, дидеме?

*Әҗәл*. Ул бит аны көлеп әйтте. Күреп тордың, елмайды.

*Әлмәндәр*. Тагын эләктең, Әҗәлетдин. Кеше мине күреп елмая икән, мин кирәк дигән була. Минем яннан елмаеп киткәч, бүтәннәр янында да елмая ул. Аның елмайганын күреп бүтәннәр елмая. Минем аркада ничаклы кеше елмая. Шуннан соң кирәк булмыйммы инде мин?

*Т.Миңнуллин «Әлдермештән Әлмәндәр»*

**Вариант 2**

Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин,
Күңелемә шулай тоела:
Пар кулыңа пар чиләгең асып,
Син чыгасың, әнкәй, коега.

Су алганчы юлга бер карыйсың,
Чиләкләрең тулгач, тагын бер.
«Бала күңеле далада», – дип, бәлки,
Үпкәләп тә йөргән чагыңдыр.

Изге теләк теләп үстердең син,
Бассыннар дип тизрәк аякка.
Шул сүзләрең синең искә төшә,
Юнәлсәм дә менә кай якка.

Кое янында син ишетерсең
Миннән сиңа хәбәр килгәнен,
Син һәркемгә очрыйсыңдыр, әнкәй,
Мөлдерәмә килеш чиләгең.

*С.Хәким «Әнкәй»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Син һәркемгә очрыйсыңдыр, әнкәй, / Мөлдерәмә килеш чиләгең»* юллары белән С.Хәким нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** С.Хәкимнең «Әнкәй» һәм Г.Тукайның «Ана догасы» шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сахралар тора балкып.

Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
Халык йоклый – каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.

Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
Авыл кырыенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.

Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

*Г.Тукай «Ана догасы»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар**

**бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә автор идеясе.

**2.2.** Заһир Бигиевның «Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә мәгърифәтчелек карашлары.

**2.3**. Каюм Насыйриның «Әбугалисина» кыйссасында Әбүгалисина һәм Әбелхарис образлары.

**2.4**. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә автор югары күтәргән сыйфатлар.

## 4нче ВАРИАНТ
## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

...Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез!

Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең, мәхшәр көне!

Старостаның бер кулында зур сөлге – бусы икенче килгәнгә билгеләнгән.

Тузан, шау-шу эчендә староста, ялгышыпмы, ничектер, чапанны Күк биягә сузды, минем Алмачуарның муенына сөлге ташлады:

– Син икенче килдең бугай, – ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем. Камчы тигәндерме, юкмы – белмәдем...

–Аны карап торырга вакыт та юк: чабып килгән атны туктатырга ярамавы һәркемгә билгеле бит!

Ул арада Сафа бабай, әткәй, күршеләр килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар. Һәммәсе мактый, һәммәсе рәхмәт укый. Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап:

– Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең, – ди.

Әткәй Алмачуарны җитәкләп йөртә башлады. Мин яулыкны ташлап, кәләпүш кидем дә кайнашып торган халык туфанына барып кердем.

Малайлар мине куркыта башладылар:

–Камчы белән сугып, старостаның битен яргансың. Ну, бирер үзеңә дә кирәгеңне! – диештеләр.

Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе чыннан да ярылган булса кирәк: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләнгән.

Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым. Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

–Мин бала чакта үзем дә атка менеп күп чапкан кеше... Алдан килеп тә, икенченең бүләген бирсәләр, җан түзәлми аңа... мин сиңа ачуланмыйм, арыгансың, бар кайт инде, – дип миңа егерме тиенлек көмеш бирде.

–Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.

*Г.Ибраһимов «Алмачуар»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем»*. Закир күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Закир холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә Закирга һәм М.Әмирнең «Агыйдел» повестенда Ильяска хас сыйфатларны чагыштырып карагыз. Нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Мин, пәрдә алдына чыгып, спектакльнең биш минуттан башланачагы, Галиябану ролендә яңа артистка уйнаячагы турында хәбәр бирдем. Көчле алкышлар мәктәпне күтәрә яздылар...

Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты.

Андый көчле җырны, андый йөрәк җырын гомеремдә беренче тапкыр ишеткәнмендер. Шул кадәр дәртләнеп, шул кадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, әйтерсең лә ул чын-чынлап Галиябану кичергәннәрне үз йөрәгендә кичерә. Аның вакытлыча гына Галиябану роленә кергән һәвәскәр артистка икәнлеген онытасың. Йөрәгең үзеңә дә сиздермәстән, аның йөрәге белән кушыла. Ул куанганда куанасы, ул көлгәндә көләсе килә. Ул боекканда боегасы, ул елаганда аның белән бергә елыйсы килә. Бер күтәрелеп, бер төшеп сулый торган калку күкрәгеннән агып чыккан үтә саф тавышның кеше тавышы булуына ышанасы килми. Анда гади кешегә аңлашылмый торган нindидер сер яшерелгәндер сыман тоела...

Бүгенге кичәнең җитәкчесе – үзенә күрә режиссеры булуым мине беразга айнытты. Бу сихерле музыка әсирлегеннән йөрәгемне тартып алып, үзен үзе оныткан залга карадым. Залдагылар, чын-чынлап, үзләре үзләрен онытканнар иде. Бик күпләрнең кыяфәтләре миңа көлке тоелды. Кем нинди хәлдә булса, гипноз белән йоклатылган шикелле, шул хәлендә катып калган.

Күпләрнең аскы иякләрен дә ябып тотарлык ихтыяры калмыйча, авызлары ачылган, күпләр муеннарын тота алмыйча, көлке кыяфәтләргә кереп, башларын

кыегайтканнар, һәрберсе үзенә бер төргә ия булган күзләр, барлык көчләренә киерелеп ачылып, сәхнәгә текәлгәннәр... Бөтен зал шулай катып калган.

Бу тиңе булмаган йөрәк көче алдында үзен үзе югалтмаган бер генә кеше күрдем мин – ул Низамый иде. Аның аптыраашта калган ачулы күзләре ниндидер авыр сорауга җавап эзлиләр. Ләкин мондый минутта кем аңа җавап бирсен. Аның барлыгын белүче дә юк... Ул, залда урнашкан йөрәк тынлыгын җимерергә теләмәгән сыман, әкрен генә урыныннан кузгалды. Кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады. Аның чыгып китүен миннән башка беркем күрмәде дә, сизмәде дә. Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым. Йөрәгем яңадан Артыкбикә йөрәге белән тоташты.

*М.Әмир «Агыйдел»*

**Вариант 2**

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка киләә уйлар төрле-төрле,-
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән:
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу нинди көй?”
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!”

*Г.Тукай «Милли моңнар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен**

**ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Әлеге шигыре белән Г.Тукай нинди фикерләр җиткерә дип уйлыйсыз? Моң образына ул нинди мәгънәләр сала?

**1.2.2.** Шигырьдә хис-кичереш үзгәрәме? Әгәр «әйе» икән, нинди күренешләргә бәйле үзгәрә дип уйлыйсыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Г.Тукайның «Милли моңнар» һәм Х.Туфанның «Кемнәр сез?» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Һәр елда
Бөек Тукайның
Бәйрәме таңы туса
Эндәшә сезгә, яшьләргә,
Һәйкәлдән Җәлил Муса:

«Кемнәр сез?
Безнең дәваммы?
Һәм безнең нәселме сез?
Тукайлар изге йоласын
Үтәргә әзерме сез?

Якладым соңга кадәр мин
Туган ил гадәтләрен,
Кулымны бәйләсәләр дә
Телемне бәйләтмәдем!

Сез балык баласы түгел,
Сез халык баласы бит.
Киләчәк көнгә Тукайны
Сез алып барасы бит!

Киселде башлар... тиделәр...
Тик телгә тидертмәдек;
Агабыз Тукай йөзенә
Каралык китертмәдек!» –

Һәр елда бөек Тукайның
Бәйрәме таңы туса
Эндәшә сезгә һәйкәлдән –
Эндәшә шулай Муса.

*Х.Туфан «Кемнәр сез?»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Г.Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.
**2.2.** Ф.Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда Фәнияр образы.
**2.3**. И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә мәхәббәт темасы.
**2.4**. Г.Кутуйның «Сагыну» нәсерендә автор идеясе.

## 5нче ВАРИАНТ
## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Көннәрдән беркөнне боларның игезәк ир балалары булды. Ата белән ана бик шатландылар. Балаларның берсенә Әбүгалисина, икенчесенә Әбелхарис дип исем бирделәр.

Көннәр, атналар үтте, айлар, еллар да үтеп киттеләр, балалар дүрт яшькә җиттеләр. Аларны мәктәпкә укырга бирделәр.

- Укысыннар, белем алсыннар, кеше булсыннар, – диделәр.

Әбүгалисина үзенең үткенлеге, зирәклеге белән башка балалардан аерылып тора иде. Әбелхарис, Әбүгалисина белән игезәк булса да, бер ата, бер анадан туса да, зирәклек һәм булдыклылык ягыннан туганы шикелле үк түгел иде.

Әбүгалисина бик яхшы укый, укытучы ни генә әйтсә дә, ул бик тиз төшенеп ала, белгәнен бер дә онытмый иде. Шулай ук ул, укытучы сөйләгәннәр белән генә канәгатьләнеп калмыйча, яшьтән үк китаплар укуга бирелде. Шуңа күрә бик күп нәрсәләр белде. Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка ячучы» бер бала иде.

Аның зирәклеге, сизгерлеге турында бик кызык сүзләр сөйлиләр. Ул вакытларда мәктәпләрдә, асларына киез салып, идәнгә тезләнеп укыйлар – парталар булмый. Әбүгалисинаның иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куялар, ә үзләре, Әбүгалисина нишләр икән дип, кызыксынып карап торалар.

Әбүгалисина мәктәпкә килә, урынына килеп утыра, аннары бер югары, бер түбән карап тора. Аңа сорау бирәләр:

- Нишләп алай карангалыйсың? – диләр.

Әбүгалисина:

- Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да бар, элеккечә түгел, – ди.

Шулай ул киез астына салынган бер бит кәгазьнең калынлыгын да сизгән, имеш, дип сөйлиләр.

Унике яшенә җиткәндә, Әбүгалисина инде бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитешә, төрле фәннәрдән үзе дә башкаларга сабак укыта башлый. Үзеннән күп зур балалар килеп, аннан дәрес алалар.

Ул төшкә кадәр балаларга сабак укыта, төштән соң урамга чыгып, алар белән рәхәтләнеп уйнап йөри. Аның бу гадәте кайбер кешеләргә бер дә ошамый. Аңа:

- Син шундый галим, шундый акыл иясе кешесең, никадәр балаларга сабак өйрәтәсең, белем бирәсең. Ә үзең надан балалар белән уйнап йөрисең, – диләр.

Әбүгалисинаның моңа бер дә исе китми. Ул:

- Кешенең һәр яшендә үзенә күрә бер матурлыгы була, сабыйлыкның матурлыгы уен белән, – дип җавап бирә.

Тагын берничә ел үтеп китә. Әбүгалисина зур галим булып җитә. Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз көрәштерерлек кеше калмый. Ләкин ул үзе моңа гына риза булмый, тагын да тирәнрәк белем алырга тели...

*К.Насыйри «Әбүгалисина»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Халык сүзе белән әйткәндә, ул «кылны кырыкка яручы» бер бала иде».* Әбүгалисинага карата әйтелгән бу гыйбарә аша аның холкындагы нинди сыйфатлар ачыла? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әбүгалисинаның туганы Әбелхарис образы аша язучы нинди проблемалар күтәрә?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** К.Насыйриның «Әбүгалисина» повестенда Әбүгалисина һәм М.Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында Хисаметдин менла образларын чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

... Күп халык карт мулланың сүзенә шәригать сүзе кебек инаныр иде. Әмма Хисаметдин мәктәбендә укытмыш вә тәҗрибә итмеш кешеләр, карт мулланың буш сүзләренә ышанмыйча, Хисаметдин менлага камил теләктәшлек итәрләр иде. Хисаметдин менла исә морфология һәм синтаксис белеменнән генә түгел, хәтта мөселман хокук белеменнән, хәтта философия фәненнән Истанбулда шәкертлектә тәмам хәбәрдар булган иде. Татар муллаларының кайберләре, үзләре аз белдекләреннән, күп белүче башкаларга көнчелек итеп сөймәдекләре мәгълүмдер.

Хисаметдин менла хәрәкәт вә кәсеп сөюче кеше иде: ун дисәтинә үзенең җире бар иде. Гәрчә бер хезмәтче тотса да вә күп чакта яз вакыты иген эшендә башка хезмәтчеләр ялласа да, күп вакыт үзе дә кара иген эшене эшләр иде. Моның аркасында Хисаметдин менла рәхәт вә башкаларга ихтыяҗсыз тормыш итәр иде.

Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә гаҗәпләнерсең. Йөзе гүзәл ачык. Яңарак чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары, вә кыска чәче коңгырт төстә булып, матур йөзенең гүзәллеген тагын да арттырадыр. Нурлы вә күк күзләре китап битенең юлыннан юлына йөгереп үтәрләр. Башында бәрхет такыясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар иде.

*М. Акъегет «Хисаметдин менла»*

**2 ВАРИАНТ**

Яңгырларда-явымнарда,
Давылларда-җилләрдә
Киек казлар кайгылдыша
Мин белмәгән телләрдә.

Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит дип
Елашалар микәнни?

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.

Киек казлар кыйгылдаша,
Сау бул, якташ, диләрдер;
Әллә кайтыр, әллә кайтмас
Безнең башлар, диләрдер.

Казлар кебек очасылар,
Китәселәр юк инде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дияселәр юк инде.

Кыйгылдашып болытларда
Мин белмәгән телләрдә,
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә.

*Хәсән Туфан «Киек казлар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Киек казлар образы аша Х.Туфан нинди фикерләр җиткерә дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә кулланылган нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Х.Туфанның «Киек казлар» һәм М.Җәлилнең «Ана бәйрәме» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

– Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Әйтсәгезче, зинһар, үз итеп,
Сагыш белән кипкән анага:
Кайда йөри минем улларым?
Ана күңеле тели белергә:
Кая илтә язмыш юлларын,
Җиңүгәме әллә үлемгә?
Көньягыннан очып күгәрчен
Кайтып керде ана йортына.
– Син, күгәрчен, беләм, күргәнсең,
Салма мине сагыш утына.
Сөйлә дөресен, кая зур улым?
Дөньядамы бәгърем, күз нурым?
– Кайгы сиңа, ана, Кырымда
Улың үлде сугыш кырында.

Катып калды ана, дәшмәде,
Ярсып чыкты кайнар яшьләре.
Кайгысыннан өлкән улының
Көмеш төсле булды чәчләре.

–  Өч улымны, очар кош итеп,
Мин очырдым ерак далага.
Әйтсәгезче, якын дус итеп,
Кайгы белән сулган анага.

Кайталмады өйгә зур улым,
Сугышып үлде бәгърем, күз нурым.
Уртанчысы, бәлки, исәндер,
Җил аңардан миңа исәдер?

Җил, уйнаклап, тәрәз төбендә
Нидер әйткән төсле кылынды.
– Әйтче, җилкәй, йөргән җиреңдә
Күрмәдеңме минем улымны?

– Кайгы сиңа, ана, уртанчы
Улың үлде сугыш кырында.
Соңгы йөрәк тибеше тынганчы
Алмаз кылычы булды кулында.

Ауды ана, таеп һушыннан,
Парчаланган йөрәк түзмәде.
Елый-елый улы сагышыннан
Сукырайды аның күзләре.

– Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым шомлы далага,
Әйтегезче, зинһар, үз итеп,
Хәсрәтеннән көйгән анага.

Ике улым үлде сугышта,
Бер өмитем калды тормышта:
Күрмәсәм дә бергә өчесен,
Мин күрермен, бәлки, кечесен?

Никтер очмый күктә күгәрчен,
Җил дә тынган, йоклый, күрәсең.
Тик яңратып урман буйларын,
Ишетелә быргы уйнавы.

Таң алдыннан ана уянды –
Җир тетрәткән тояк тавышына.
Тәрәзәгә килеп таянды,
Чик-чама юк аның сагышына.

Шыңгырдатып тавышын даганың
Бер ат килә, ярсый йөрәге.
Ат өстендә улы ананың,
Иң кечесе, өзелеп сөйгәне.

Күкрәгендә медаль алтынлы,
Кулларында җиңү байрагы.
Каршы ала котлап батырны
Таң нурлары, кошлар сайравы.

Күрмәсә дә, ана улкаен
Күңеле белән сизеп таныды.
– Балам! – диеп, елап, ул аның
Күкрәгенә килеп сарылды. –

Кайттыңмы, улым, алтыным!
Куанычым минем, актыгым!
Карт ананың көмеш чәченә
Алтын яше тама батырның.

– Я, тынычлан, анам, борчылма,
Сиңа улың – синең актыгың
Алып кайтты алмаз кылычында
Ил саулыгын, җиңү шатлыгын.

Абыйларым канлы сугышта
Җиңү юлын сызып үлделәр.
Гомерләрен соңгы сулышта
Мәңге үлмәс данга төрделәр.

Калдырсам да күмеп еракта
Абыйларның батыр гәүдәсен,
Алып кайттым данлы байракта
Каннарының алсу шәүләсен...

Ана алды алсу байракны,
Күзен сөртте – күзе ачылды:
Каршысында тора гайрәтле,
Киң күкрәкле батыр лачыны.

– Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Сез килегез, якын дус итеп,

Күп кайгылар кичкән анага.

Күкрәк сөтем имезеп, тирбәтеп,
Мин өч лачын илгә үстердем.
Батыр көрәш җырын өйрәтеп,
Кошларымны кырга очырдым.

Ике улым кире кайтмады,
Кешнәп йөри кырда атлары,
Мин аларга бирдем канымны,
Алар аны ерак калдырды.

Изге Ватан өчен агызып,
Җиңү таңын җиргә кабызып,
Алып кайтты илгә ул таңны,
Кече улым, батыр лачыным.

Ал медале аның путаллы,
Куандырды анай карчыгын.
Һич үлмәгән төсле улларым,
Өем тулы кызлар, егетләр,
Туя алмыйм тыңлап җырларын,
Минем балаларым кебекләр.

Бер кайгырсам, ике шатланам.
һәр тамчысы хәләл сөтемнең;
Илдә мәңге үлмәс ат белән
Үлә белгән уллар үстердем.

Сез килегез бу шат анага,
Аның бүген туган бәйрәме.
Агыла аңа картлар, балалар,
Өе тулы чәчәк бәйләме.

Ил шатлыгы белән төзәлде
Йөрәгенең авыр ярасы.
Ил түрендә, гөлләр эчендә
Өч батырның туган анасы.

*М.Җәлил «Ана бәйрәме»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә автор югары күтәргән сыйфатлар.

**2.2.** Габдерәхим Утыз Имәнинең «Гыйлемнең өстенлеге турындагы төркичә бәетләр» әсәрендә мәгърифәтчелек идеяләре.

**2.3**. Ризаэтдин Фәхретдиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романында автор күтәргән проблемалар.

**2.4**. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасында Сөһәйл һәм Гөлдерсен образлары.

## 6нчы ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Алар конторадан чыкканда томан сыекланган һәм дә диңгез ягыннан аксыл томан аркылы тонык кына нур чәчеп торган кояш шактый югары күтәрелгән иде. Һава кичәгегә караганда шәп иде. Җил юк, йомшак кына саф һәм ләззәтле бер салкынлык сулыш белән эчкә керә дә, бөтен тамырларга җәелеп, җанны рәхәтләндерә иде. Сыек кына томан белән өртүле диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларның гыйгылдап көлгән шикелле үткен һәм күңелне кытыкландыра торган тавышлары диңгез өстендә асылынып торган әллә нинди тылсымлы сарайлардан ишетелгән шатлык шаркылдауларына охшый иделәр.

Бу өч иптәшнең рухлары шактый күтәренке иде. Солдат, кулы белән селтәп торып:

– Кара мартышкаларны, көлеп эчләре ката бит! Значет, балык аз булмас! – диде.

Гариф, Солдатның иңбашына кулын салып:

– Әй, картка нишлибез, керәбезме? Чәйгә чакырган иде ич, – диде.

Солдатның авызы ерылды, күзләре көлә иде.

– Сезне алып керергәме икән? – диде дә, күзләрен майландырып, Гариф белән Мусага алмаш-тилмәш карады. Тегеләр гүя бернәрсә дә аңламый иделәр. Ул Гарифны иңбашыннан этеп җибәрде дә:

– Газизәгә күзең төшмәсен дим, жулик! – диде.

Гариф хәзер генә исенә төшкән шикелле:

– И, кызы бар дигән идең, чын да, менә юләр; әйтәм нәрсә сөйли бу! – диде.

Солдат, Мусага күз кысып:

– Бу нәгъләткә ышанырга ярамый, иптәш, исеңдәдер теге Марфа Петровна ничек кабартмалар белән сыйлый иде үзен, – диде...

Солдат бу сүзләрне әйткәндә, күзләрен почмакландырып, күбрәк мәгънә аңлатырга тырыша һәм тегеләргә алмаш-тилмәш карый, көлә иде.

– Үзе чакыргач, ник утырмаска соң, юләр! – диде Гариф.

– Әйтерсең лә мулла остабикәсе белән рәхәтләнә; без мескеннәр каткан күмәч ашап җаныбыз чыга, ә алар майлы кабартмалар сыталар! Ха-ха.

Муса да Солдатка кушылып көлеп җибәрде.

Гариф аз гына көлемсерәп:

– Майлыларны диген, ә, юләр син, Солдат! Дөрес сүз икән ул, солдат кешедә төшкә кадәр бер акыл булмый имеш, тышта әле завтрак кына шул, – диде.

Кечкенә казарма алдында Шәрәфи карт үзе юк иде; кискәгә чабып куйган балтасы гына читтән караганда әллә нинди нечкә гәүдәле ерткыч кошка охшап күренә, тирә-ягында ап-ак йомычка кисәкләре чәчелеп ята иде.

Болар казарма ишек алдында тукталдылар.

– Шәрәфи абзый өйдәме? – дип Солдат кычкырган иде, озакламый ул ишек ачылып, ишек арасында мөлаем генә бер кыз күренде:

– Ул хәзер лабазга дип чыккан иде, – диде.

Шулай дигәч, болар бер-берсенә карадылар.

Теге тагын ялгады:

– Әйдә керегез, Хөснетдин абый... Ул, хәзер кайтам, дип әйткән иде... Сезгә керергә кушты.

Бу сүзләрне әйткәндә ул инде ишек алдына чыкты. Күзләрен кояштан ышыклар өчен, бер кулын кашлары өстенә куеп, лабаз ягына карана иде. Гариф күңеленнән: «Шул була инде күрәсең Газизә...» дип уйлап алды. Үзенчә исе китмәгән гади һәм гөнаһсыз рәвештә тегеңәр күз төшергәли иде. Ул төс-баш күренеше белән шәһәрләрдәге урта катлаудан түбәнрәк татар гаиләләрендәге бер кыз иде; өстендә тубыктан югарырак торган иске генә аксыл ситсы күлмәк, аягында да каюлы һәм искерәк кенә кызыл читек белән ялтыравы беткән сары резинка галошлар иде. Аның аз гына кызгылт ак йөзе, кош борынына охшаулырак килешле борыны, уйчан кара күзләре дә бер караштa гади генә күренәләр. Гариф, аның күзенә туры карарга яхшысынмаганлыктан, авызына күз төшергәләде. Гөл чәчәге кебек иреннәре гадәттән тыш матур иде. Ияк астына китереп бәйләгән простой күк сарфинка яулык та ярыйсы гына килешә иде. «Калфак кисә, тагын да шәп буласы икән...» дип Гарифның күңеленә килде.

*Ш.Камал «Акчарлаклар»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** *«Гариф күңеленнән: «Шул була инде күрәсең Газизә...» дип уйлап алды. Үзенчә исе китмәгән гади һәм гөнаһсыз рәвештә тегеңәр күз төшергәли иде... Гариф, аның күзенә туры карарга яхшысынмаганлыктан, авызына күз төшергәләде».* Әлеге өзектә Гариф холкына хас нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.2.** «Канатсыз акчарлаклар» символына язучы нинди мәгънәләр сала? Кемнәр турында сүз алып бара? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр**

**текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ш.Камалның «Акчарлаклар» повестенда Гариф һәм Г.Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә Солтан образларын чагыштырып карагыз. Аларның якын кешеләренә мөнәсәбәтендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Моннан биш-алты ел элек сугышка киткәндә, Гайния мине:

– Көтәрмен... айлар, еллар көтәрмен... Аяксыз, кулсыз булып кайтсаң да, син минеке! Башкаларга күзем дә, күңелем дә төшми! – дип елап озаткан иде.

Мин булмаган чакларда, бигрәк тә минем хакымда «атылган икән, асылган икән» дип төрле хәбәрләр таралган вакытларда, ул сылу тәнле, уңган куллы асыл кызны төрле җирләрдән яхшы-яхшы урыннарга сорап башкодалар күп йөргәннәр.

Ләкин ул һәммәсен:

– Сүз биргән егетем бар... аны көтәм... – дип, кире кайтара торган...

Авылга соңгы мәртәбә кайтып төшкәч, элекке кебек качмады. Тартынмады. Кеше алдында минем белән сөйләшә бирде.

Әни бик картайды инде. Вак-төяк эшләр дә аны бик арыталар. Гайния, килгән саен, безнең әллә ничаклы эшләрне башкара, өйне җыештыра, самавырны агарта, карчыкның гөлләренә; җимешләренә сулар сибә иде.

Кайтып төшкән көннәрдә ячейка белән, яшьләр белән кайнашып, ничектер иркен бер вакыт таба алмадым – Гайния белән озаклап сөйләшә алмадым. Ләкин болай сөйләшүнең кирәге дә булмады. Безнең тормышлар ничектер үзеннән-үзе кушылып киттеләр...

Беркөнне шулай Гайния җиләктән кайтышлый:

– Әбкәем, бик харап сусадым. Бозлы әйрәнең юкмы? Синдә була торган иде, - дип янып-пешеп, кызарып, безгә керде.

Минем карчык үзенең хәлсез куллары белән кер юып азаплана иде. Кыз түзмәде:

– Их, әбкәем, бер дә рәтең калмаган синең хәзер. Бар, өеңә кер. Мин үзем бу нәрсәләреңне башкарырмын, – диде.

Мин агач төбендә, аңа сокланып, колхоз турында бер китапны укыштырыбрак ятам. Гайния зәңгәр яулыгын артка кайтарып салды, ак алъяпкыч белән билне кысып, күкрәкне калкытып бәйләде, ак шалкан кебек тулы матур беләкләрне сызганды да, бер самавыр кайнап чыгарлык вакыт үтмәгәндер, бөтен чүп-чарны юып бетерде. Аннан соң, ике чиләккә тутырып, көянтә белән бөгелә-сыгыла Агыйделгә төшеп, керләрен чайкап та менде.

Ул арада әнкәйнең самавыры да кайнап чыккан иде. Гайния җыеп кайткан җиләкләр белән тәмләп чәй эчтек.

Өстәлне җыештыргач, ындырдан бер чиләк эре бәрәңге алып кайтты, кое төбендә кырып юды да пешереп безне сыйлады. Кояш баткан иде инде. Бәрәңге ашагач, без икәүләп өй буена бакчага чыгып утырдык.

Гайния күп көлде... Авылның әллә нинди гайбәтләрен сөйләп бетерде... Аннан соң ничектер үткән көннәргә кереп киттек...

Авыр вакытлар булган. Агасы Гыйлаҗи белән атасы Зариф карт үтерелгәч, күп җирләрдән башкодалар килеп, бик аптыратканнар... Әнкәсе дә көчләп караган...

Утыра торгач, вакытның үтүе сизелмәгән дә икән. Бакчадагы үләннәрдән, чәчәкләрдән төнге тәмле, ләкин юеш хуш ис күтәрелә башлады. Бер почмакта көндез күренми торган ахшам чәчәкләре ап-ак булып атып чыктылар.

Агыйдел аръягындагы Урал тармаклары артыннан кызарып ай калыкты. Дөнья йөзе матур, йомшак нурга чумды.

– Абау!.. Без таңны аттыра язганбыз икән, – диде дә Гайния урыныннан кузгалды.

*Г.Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр»*

## Вариант 2

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
Юл бара ят ил карап...
Чыкты җилләр,
Купты тулкын –
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

*Дәрдемәнд «Кораб»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Чыкты җилләр, Купты тулкын – Ил корабын җил сөрә!..»* юллары белән Дәрдемәнд нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик төргә хас нинди үзенчәлекләр чагылыш таба?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр**

**текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Дәрдемәнднең «Кораб» һәм Г.Тукайның «Өзелгән өмид» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомерем яртысы.

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урнында – анда тулган айның яктысы.

Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.

И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барсы корган – бер генә юк җанлысы, яфраклысы.

Булмадың, алтын ярым, салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, -
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

*Г.Тукай «Өзелгән өмид»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән**

**темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** «Идегәй» дастанында автор югары күтәргән сыйфатлар.

**2.2.** Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» романында автор идеясе.

**2.3**. Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» повестенда күтәрелгән проблемалар.

**2.4**. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә әхлакый-тәрбияви фикерләр.

## 7нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Үзара сөйләшкәннәр дә, өченчегә Алмачуарны җигәргә булганнар. Моны ишеткәч, мин, еларга җитешеп, эткәйгә бардым.

– Ни бар? Кем тиде? – ди.

– Берәү дә тимәде! Ник минем Алмачуарны сабанга җигәсез? – дидем дә түзә алмый елап ук җибәрдем.

Минем тавышка әнкәй дә килеп керә.

Алмачуарны миннән көнләшә булса кирәк. Кайчан гына шул турыда сүз чыкмасын, мине тиргәргә, каһәрләргә тотына. Әле дә эткәй ни барын сөйләп бетмәде, әнкәй, миңа каршы кызып, ачуланып китте:

– Фу, илаһым, – ди, – нинди бәла-каза килгән, дип торам... Бер тай өчен адәм шул чаклы акырыр икән, ди. Әллә аны гомер буена җикми асрар идеңме? Менә тилергән нәрсә!.. – ди.

Әткәй ачуланмый, кызмый, мине юатырга тырыша:

– Чү, Закир, алай юк өчен елап барма, – ди. – Бернәрсә дә булмас, без аны буразна яклап очка гына җигәрбез... Үзең ат куарсың.... Карап кына йөртерсең, – ди.

Мин аның саен ярсыдым, аның саен елый бирдем.

Ашарга чакырдылар – кермәдем. Самовар кайнаган, диделәр, – аңа да карамадым. Туктаусыз еладым да еладым; шулай елый-елый барып, эштән чыгып, бакча буендагы такта өстендә йоклап та калганмын.

Уянып китсәм, ишек алдында түшәктә ятам.

Төш ауган. Кояш түбәнәеп бара. Дөнья бик рәхәт кенә, талгын гына тора, йортта бер кеше дә күренми. Сабаннар, арбалар да юк, капка тулы ачык тора.

Сикереп тордым да абзарга йөгердем.

Барсам, ни күрим!? Минем Алмачуар, озын тезген белән бәйләнгән хәлдә, улакның бер башыннан икенче башына йөреп тора.

Ахрысы, сагынгандыр, мине күрүгә кешнәп үк җибәрде.

Телләребез сөйләмәсә дә, без бер-беребезне бик тирән аңлыйбыз. Мин килеп күренүгә, ул шатланып ук китте, өстен, ял, койрыгын тазартканда, йөзеннән сыйпаганда, айгырым бертуктаусыз иһи... иһи... дип, йомшак кына кешнәп, иркәләнеп тора, улагын төзәттем, коега илтеп, су эчердем дә өйгә кердем.

Әткәй ярым шелтә, ярым елмаю белән каршы алды:

– Елак малай! Җиңдең бит, ахрысы!.. Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә янәшә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булдылар... – ди.

Шатлыгым йөрәгемнән тулып таша. Җире, күге, бөтен дөньясы минем шатлыгымнан һәммәсе бииләр кебек тоела.

Бүген әни яныннан китмәдем. Ни кушса, барын-барын тыңладым.

Утын керт, диде, – аны керттем. Каз бәбкәләрен Өзән елгага илтеп кайт, диде – аларны илттем. Тавыклар йомырка салгандыр, ояларны кара, диде, – аңа йөгердем.

Әткәйләр киткәндә, катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән; шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән, аларга ашарга илтергә кирәк булды.

– Бар, Мохтарга әйт, – диде, – аркылы агач белән тотарсыз да яланга икмәк белән катык илтеп кайтырсыз, – диде әнкәй.

Бер сүзенә карышмадым, тик:

– Мин үзем генә дә илтә алам, әнкәй, – дидем.

– Булдыра алмассың, катыкны түгеп, әрәм итәрсең, икәү барыгыз, – дигәч, аңа да күндем.

Яланга баргач, безнекеләр янында сабан сөрә торган Апуш мине көлеп каршы алды:

– Ну, малай, эт икәнсең, җиңдең бит, Алмачуарны җиктермәдең бит, – ди. – Әйдә, бирешмә, Закир, чабышкы буласы асыл сөякне сабанга җигепәрәм иттермә, – ди.

Бу юлга җиңүен җиңдем...

Әмма бу җиңүләр миңа бик кыйбат төшкән чаклар да булды.

*Г.Ибраһимов «Алмачуар»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Ну, малай, эт икәнсең, җиңдең бит, Алмачуарны җиктермәдең бит».* Закирга карата әйтелгән бу гыйбарә аша аның холкындагы нинди сыйфатлар ачыла? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Закирның Алмачуарга мөнәсәбәте аркылы әсәр сюжетында язучы нинди проблемалар күтәрә?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә һәм Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек» әсәрендә төп геройларның күңел халәтен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

... «Минем читегем юк, минем кәҗүл читегем юк», – дип, әллә кем минем эчемдә сыкранып кычкырына башлады.

Мин тавышланып еларга тотындым. Саплы калачны алмадым. Чәйне эчмәдем. Акырып барып мендәргә яттым; мине әти дә яратмый, миннән мулла абый да көлә; мине әни дә, әби дә сөйми... Читегем юк... Рәбиганың читеге бар, минем читегем юк.

Әни торды.

– Ни булды сиңа, угылым. Синең, бит, читегең бар, тик кәҗә Вәлинең килененең баласы кызамыктан авырганга нәни генә өлгермәгән.

Әби:

– Менә мин сине акыллы дип чапан тектем. Син зур башың белән елап утырасың.

Әти дә:

– Елама, елама! Алай булса, мулла абыеңны кызганмасаң, киеп бар.

Минем күз алдыма тагы шул мәхәббәтсез читек килде. Мин тагы кычкырып еладым.

Әни:

– Тукта инде, акыллы бул. Мә, алай булса, үз читегемне бирәм.

Әни каймалы зәңгәр җирлекле читек күтәреп килде.

– Мә, ки, үзеңә булсын.

Рәбига, почмакта читеген кочаклап:

– Мин бирмим, мин бирмим, – дип акырырга тотынды.

Тиле, мин катымша мыни хатыннар читеген кияргә!

Мулла абый:

– Мин сине зур булды, мәдрәсәгә алып барырмын дип тора идем. Син анда да шулай елап йөдәтсәң, алмыйм инде, – диде.

Әби:

– Мин сиңа үзем кәҗүл читек тегәм, үзем тегәм. Менә күр дә тор, үзем тегәм. Иртәгә чапаныңны киярсең. Читегеңне киярсең. Мәхдүм булып гаеткә барырсың.

Мин күземне ачтым. Рәбига, тиле, авызын ыржайтып елап утыра. Тиле! Гарәфә көнендә еларга ярыймыни? Тиле! Фәрештәләр тәсбих әйткәндә еларга ярыймыни? Әти авырса нишләрсең?

Мине җилтерәтеп самовар янына алып киттеләр. Әни чәй ясады. Әти бал кашыгым белән бал алып бирде. Әби чапанымны, яшел чапанымны кигезеп карады.

– Бар дә тәмам. Өр-яңа чапан, төймәсен генә тагасы бар. Иртәгә менә читек тә өлгертәм.

– Нәни читекме, әби?

– Нәни читек, угылым.

– Кәҗүл читекме, әби?

– Кәҗүл читек.

Мин саплы калач белән малайларны кызыктырырга, ындырлар артына сыерлар ашатырга чыктым. Иртәгә минем кәҗүл, нәни читегем була.

Караңгы төшеп өйгә кайтканда әби түр башында утырган да, колак артларына җеп белән эләктергән күзлеген кигән дә, чынаяк астлыгында ак май белән корымны бергә изеп маташа.

Аның янында әнинең иске читеге, Сәрби әбинең үлек өстеннән бирелгән каймасыз кызыл читеге.

– Әби, нишлисең?

– Бар, ят, угылым, бар. Әнә Рәбига акыллы кыз, күптән йоклый. Иртәгә гает бит. Гаеткә тора алмассың. Бар, ят!

– Әби, читегем өлгердеме?

– Юк әле, юк. Мин аны намазымны укыгач кына тегәм. Бар, ят.

Әбинең миңа читек тегүен, кәҗүл читек тегүен күрәсем килсә дә, гаеткә тора алмам дип яттым.

Юрганның кырыеннан гына әбинең нишләгәнен карап яттым. Әби, аркасы белән утырганга, нишләгәне күренмәде.

Бүлмә тактасының шәүләсендә генә аның калын бармаклары әллә нәрсә өстеннән бик кызулап йөргәне, аның әллә ни ышкыганы шәйләнде.

Минем күз алдыма нәни генә читек, кәҗүл читек килеп басты. Ул минеке.

Кил, кил, кәҗүл читек. Иртәгә гает, кәҗүл читек, иртәгә гает!

*Г. Исхакый «Кәҗүл читек»*

**Вариант 2**

Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин
Күңелемә шулай тоела:
Пар кулыңа пар чиләгең асып,
Син чыгасың, әнкәй, коега.

Су алганчы юлга бер карыйсың,
Чиләкләрең тулгач, тагын бер.
Бала күңеле – далада, дип, бәлки,
Үпкәләп тә йөргән чагыңдыр.

Изге теләк теләп үстердең син,
Бассыннар дип, тизрәк аякка.
Шул теләгең хәзер искә төшә,
Юнәлсәм дә менә кай якка.

*С. Хәким «Әнкәй»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Пар кулыңа пар чиләгең асып, / Син чыгасың, әнкәй, коега»* юллары белән С.Хәким нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә кулланылган нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** С.Хәкимнең «Әнкәй» һәм М.Җәлилнең «Ана бәйрәме» шигырьләрендә лирик геройның Анага мөнәсәбәтен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

– Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Әйтсәгезче, зинһар, үз итеп,
Сагыш белән кипкән анага:
Кайда йөри минем улларым?
Ана күңеле тели белергә:
Кая илтә язмыш юлларын,
Җиңүгәме әллә үлемгә?
Көньягыннан очып күгәрчен
Кайтып керде ана йортына.
– Син, күгәрчен, беләм, күргәнсең,
Салма мине сагыш утына.
Сөйлә дөресен, кая зур улым?
Дөньядамы бәгърем, күз нурым?
– Кайгы сиңа, ана, Кырымда
Улың үлде сугыш кырында.

Катып калды ана, дәшмәде,
Ярсып чыкты кайнар яшьләре.
Кайгысыннан өлкән улының
Көмеш төсле булды чәчләре.

– Өч улымны, очар кош итеп,

Мин очырдым ерак далага.
Әйтсәгезче, якын дус итеп,
Кайгы белән сулган анага.

Кайталмады өйгә зур улым,
Сугышып үлде бәгърем, күз нурым.
Уртанчысы, бәлки, исәндер,
Җил аңардан миңа исәдер?

Җил, уйнаклап, тәрәз төбендә
Нидер әйткән төсле кылынды.
– Әйтче, җилкәй, йөргән җиреңдә
Күрмәдеңме минем улымны?

– Кайгы сиңа, ана, уртанчы
Улың үлде сугыш кырында.
Соңгы йөрәк тибеше тынганчы
Алмаз кылычы булды кулында.

Ауды ана, таеп һушыннан,
Парчаланган йөрәк түзмәде.
Елый-елый улы сагышыннан
Сукырайды аның күзләре.

– Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым шомлы далага,
Әйтегезче, зинһар, үз итеп,
Хәсрәтеннән көйгән анага.

Ике улым үлде сугышта,
Бер өмитем калды тормышта:
Күрмәсәм дә бергә өчесен,
Мин күрермен, бәлки, кечесен?

Никтер очмый күктә күгәрчен,
Җил дә тынган, йоклый, күрәсең.
Тик яңратып урман буйларын,
Ишетелә быргы уйнавы.

Таң алдыннан ана уянды –
Җир тетрәткән тояк тавышына.
Тәрәзәгә килеп таянды,
Чик-чама юк аның сагышына.

Шыңгырдатып тавышын даганың
Бер ат килә, ярсый йөрәге.
Ат өстендә улы ананың,
Иң кечесе, өзелеп сөйгәне.

Күкрәгендә медаль алтынлы,
Кулларында җиңү байрагы.
Каршы ала котлап батырны
Таң нурлары, кошлар сайравы.

Күрмәсә дә, ана улкаен
Күңеле белән сизеп таныды.
– Балам! – диеп, елап, ул аның
Күкрәгенә килеп сарылды. –

Кайттыңмы, улым, алтыным!
Куанычым минем, актыгым!
Карт ананың көмеш чәченә
Алтын яше тама батырның.

– Я, тынычлан, анам, борчылма,
Сиңа улың – синең актыгың
Алып кайтты алмаз кылычында
Ил саулыгын, җиңү шатлыгын.

Абыйларым канлы сугышта
Җиңү юлын сызып үлделәр.
Гомерләрен соңгы сулышта
Мәңге үлмәс данга төрделәр.

Калдырсам да күмеп еракта
Абыйларның батыр гәүдәсен,
Алып кайттым данлы байракта
Каннарының алсу шәүләсен...

Ана алды алсу байракны,
Күзен сөртте – күзе ачылды:
Каршысында тора гайрәтле,
Киң күкрәкле батыр лачыны.

– Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Сез килегез, якын дус итеп,
Күп кайгылар кичкән анага.

Күкрәк сөтем имезеп, тирбәтеп,
Мин өч лачын илгә үстердем.
Батыр көрәш җырын өйрәтеп,
Кошларымны кырга очырдым.

Ике улым кире кайтмады,
Кешнәп йөри кырда атлары,
Мин аларга бирдем канымны,
Алар аны ерак калдырды.

Изге Ватан өчен агызып,
Җиңү таңын җиргә кабызып,
Алып кайтты илгә ул таңны,
Кече улым, батыр лачыным.

Ал медале аның путаллы,
Куандырды анай карчыгын.
Һич үлмәгән төсле улларым,
Өем тулы кызлар, егетләр,
Туя алмыйм тыңлап җырларын,
Минем балаларым кебекләр.

Бер кайгырсам, ике шатланам.
һәр тамчысы хәләл сөтемнең;
Илдә мәңге үлмәс ат белән
Үлә белгән уллар үстердем.

Сез килегез бу шат анага,
Аның бүген туган бәйрәме.
Агыла аңа картлар, балалар,
Өе тулы чәчәк бәйләме.

Ил шатлыгы белән төзәлде
Йөрәгенең авыр ярасы.
Ил түрендә, гөлләр эчендә
Өч батырның туган анасы.

*М.Җәлил «Ана бәйрәме»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә мәхәббәт темасы.

**2.2.** Габделҗәббар Кандалыйның «Сәхибҗәмал» поэмасында мәгърифәтчелек идеяләре.

**2.3**. М.Фәйзинең «Галиябану» драмасында автор күтәргән проблемалар.

**2.4**. Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә Ана һәм бала мөнәсәбәте.

## 8нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Колын! Шуны гына ишетүем булды, ялт итеп сикереп торуым булды. Шулай булмыйча соң! Авыл малаеның иң мавыктыргыч, иң матур хыялларыннан берсе шул колын лабаса инде!

Ишегалдына йөгереп чыксам, шатлыгымнан телдән кала яздым. Әнә ул, әнә мин көткән колын! Үзе җирән, аркасыннан бармак иңлеге коңгырт тасма сузылып киткән, алгы аякларының балтырына тикле ак оек кигән. Маңгаенда йолдызы да бар. Таяк шикелле нечкә һәм озын, әмма хәлсез аякларын бик сәер итеп дүрт якка тырпайткан да имгән булып маташа.

Минем янда гына, кулын артка куеп, колыннан күзен алмыйча, әти елмаеп тора. Ул да бик куанган.

– Безнең бия, бер бик матур колын алып кайтасы килеп, күптән үк эзләнеп йөри башлаган иде инде, – ди.

– Ник элегрәк алып кайтмаган соң?

– Һе, ансат кына сиңа! Мондый матуры еш очрыймыни аның? Менә кичә болынга кунарга төшкәч, шушы ак оеклысын туры китергән дә ияртеп үк кайтасы иткән...

Биягә минем шундук күңелем йомшап, карашым яхшырып китте. Болай югыйсә ул мине бик үк санламый да, янына җибәрмәгән чаклары да булгалый. Җитмәсә, бер күзенә ак төшкәнлектән, күрше малайлары үртәп җен ачуымны чыгаралар.

– Сезнең атыгызның бер күзе өшегән! – диләр. Менә хәзер мин аларның авызларын ачарга да ирек бирмим инде! Өшегәнме? Өшегән булса да, колынның әнә ниндиен алып кайткан!

Тик кара бия минем шикелле йомшак күңелле булып чыкмады. Мин, колынны аркасыннан сыйпамакчы булып, «бәһ-бәһ» дип, янына бара гына башлаган идем, бия, яман да ачуланып, колакларын шомрайтты, дәү сары тешләрен ыржайтып, ашардай булып, башын миңа таба айкады.

Әти мине тиз генә үз янына тартып алды:

– Чү! Якын барасы булма! Ачуын китерәсең, – диде.

*Г.Бәширов «Туган ягым – яшел бишек»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән**

**күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: «*Биягә минем шундук күңелем йомшап, карашым яхшырып китте. Болай югыйсә ул мине бик үк санламый да, янына җибәрмәгән чаклары да булгалый. Җитмәсә, бер күзенә ак төшкәнлектән, күрше малайлары үртәп җен ачуымны чыгаралар*» Закир күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге әсәрдә язучы нинди проблемалар күтәрә?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестендәге Гомәр һәм Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендәге Закирның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Тик өйгә алып кайтып, бияне кое баганасына бәйләп куйгач кына, мин үз-үземә исәп бирә алырлык булдым.

Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде: аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган ефәк бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара ефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка - бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз дип күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе, әйтерсең, ходайның үз кулы белән, фирештә-ләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый... сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар.

Төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел - ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора.

Бер самовар кайнарлык вакыт үтмәгәндер, йортка бала чага җыела башлады. Бары да, авызларын ачып, хәйран булып, бу асыл сөяк колынга карап каталар.

Кайдандыр ишетеп, безнең Сафа бабай да ак сакалын җилбердәтеп килеп керде. Ул бөтен тирә-якка ат тану белән дан тоткан кеше.

«Я ходай! Ни әйтер?» – дип, мин аңа карап каттым. Колынны күрүгә бабайның йөзе ачылды:

– Сөбханалла... Сөбханалла... Күз тимәсен... Бу колын да үзенең элекке ике агасына охшаган икән, - диде.

Дәшми-тынмый тагы бик озак карап торды да:

– Шулай, шулай! Яңлышмыйм. Бу да нәкъ агалары кебек... – диде.

Әти, миңа белдермичә генә, әллә кайчаннан кечкенә генә көмеш кыңгырау алып куйган икән. Әни кызыл тасма бирде.

Карт акрын гына, оста гына килеп, колынны кинәт кенә кочаклап алды да:

– Бисмилла... Сөбханалла... Яман күздән, эт-бүредән ходай сакласын, – дип, догалар укый-укый, минем айгырымның муенына шул кызыл тасма белән кыңгырауны такты.

Тагы бераз читкәрәк китеп карады да әткәйгә:

– Беләсеңме, Хафиз, бу нәкъ агалары кебек булыр, төсе дә тиз арада алмачуарга әйләнер... Хәерле булсын, хәсрәтең зур иде, ике өлкән балаң хафасы сине бик картайткан иде, бурлы бия бу йортка җиңел аяк белән килде, бәрәкәт китерде, – диде.

Ике өлкән баласын хәтергә төшерү һәрвакыт безнең әткәйнең йөрәгенә авыр була, мондый чакта, ничектер, аның тавышы үзгәрә, сүзләре башкачарак чыга. Мин, аптырап, күзләрендә яшь юкмы дип, ана карыйм.

Юк, ул еламаган. Шулай да әсәрләнгән. Әллә нинди эчке тавыш белән:

– Сөйләмә инде, Сафа абзый, ул ике балам адәм түгел, лачыннар, арысланнар иде. Үзләре дә бәхетсез булды, минем дә вакытсыз чәчләремне агарттылар... – диде. Бераз туктап торып: – Язганы шулдыр инде... Менә бар өмет бу кечкенәсендә, – дип кушты.

Сафа бабай тагы, теләкләр теләп, колынны мактады да минем колагымнан шаярып тартты:

– Закир, бәхетең зур икән: башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды, сиңа алмачуар колын де, бу колын ике агасы кебек асыл сөякләрдән... Күз тимәсен, бу да чабышкы булыр... – дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.

Мин кая басканымны белмим. Бер көндә әллә ничаклы үскән кебек булдым: уенмыни?! Минем колыным бар. Ул айгыр! Төсе алмачуарга әйләнәчәк! Тирә-якта дан тоткан ике агасы кебек чабышкы булачак!

Әнә күрегез: ул ничек көмеш тавыш белән яңгыратып кешни! Ничек асыл сөякле гәүдәсе белән матурлап сикереп уйный.

*Г.Ибраһимов «Алмачуар»*

**Вариант 2**

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да

Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

*Ф.Кәрим «Ватаным өчен»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Чәчәкләргә төренеп эзем кала, Җырым кала үткән юлымда»* юллары белән Ф. Кәрим нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик төргә хас нинди үзенчәлекләрне билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Фатих Кәримнең «Ватаным өчен» һәм Муса Җәлилнең «Соңгы җыр» шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Җир йөзе шундый киң,
Күңелле һәм якты!
Тик төрмәм караңгы,
Ишеге йозаклы!

Күктә бер кош оча

Югары, югары!
Мин ауныйм идәндә,
Кулларым богаулы.

Тышта бер гөл үсә
Яңгырга коенып;
Мин кибәм, мин сулам
Төрмәдә боегып.

Мин беләм: бик татлы
Да яшәү тойгысы!
Тик инде мин үләм,
Бу җырым — соңгысы!...

*М.Җәлил «Соңгы җыр»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** М.Акъегетнең «Хисаметдин менла» повестенда тема бирелеше.

**2.2.** Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә төш образы.

**2.3**. Каюм Насыйриның «Әбугалисина» әсәрендә мәгърифәтчелек идеяләре.

**2.4**. Заһир Бигиевның «Өлүф яки гизәл кыз Хәдичә» романында күтәрелгән проблемалар.

## 9нчы ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күңелендәгеен шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул... Ничек кенә дип әйтергә аңа? Бераз икеләнеп ятканнан соң, баланың аркасыннан сыйпап, гүя болай гына әйтеп куйган була:

– Бәләкәчем, мин тиздән китәрмен инде...

– Китәсең... Кая китәсең? – ди бала, зур күзләре белән әбисенә тутырып карап. (Ә берни сизә, берни төшенә белмәгән, бары тик ышана яки курка гына белгән сабый күзләреннән дә бәгырьне телгәләрлек нәрсә бар?!)

– Ни инде... үзебезнең Юлкотлыга, – ди карчык, көчкә генә телен әйләндереп.

– Юк, китмисең, китмисең!.. – ди бала, шунда ук үпкәли дә башлап.

Акъәби үксеп җибәрмәс өчен иреннәрен кыса һәм озак кына дәшә алмыйча ята. Бары бугазына килгән төер кире киткәч кенә, тагын әйтеп куя:

– Мин сиңа, кошчыгым, аннан бүләк җибәрермен.

– Бүләк? Нинди бүләк, әбекәем?

– Сиңа билгеләп куйган бик матур чулпыларым бар, шуларны җибәрермен.

– Ә нәрсә ул чулпы? Нигә син аны алып килмәдең?

– Онытканмын.

Бала, ышаныргамы, юкмы дигәндәй, әбисенә карап тора-тора да, нидер сизенгәндәй, башын селкеп куя.

– Син алдыйсың, – ди ул, сузып кына. – Бездән китәр өчен генә әйтәсең...

Акъәби йөзен тизрәк читкә бора. Юк, булмый, сөйләү мөмкин түгел... Сабыйның күңеленә кагылырга ярамый, ярамый, аярга кирәк аны, аярга!.. Кем белә, бәлки, соңыннан бу әйткәннәрне исенә төшереп, әнисеннән: «Әбекәем кая китте, нигә миңа чулпы җибәрми?» – дип сорап йөдәтер. Һәм карчык сабыйны тынычландырыр өчен, аның күңелендә бернинди шик-шомлану калдырмас өчен, көлгән булып, баланы юатырга ашыга:

– Юри генә әйттем, бәбкәчем, юри генә! Сине калдырып китәмме соң?.. Юк, юк, беркая да китмим, күз нурым!..

...Гаҗәп хәл! Бала белән шушы гөнаһсыз гына сөйләшүдән соң Акъәби гомумән васыятьләрен кемгә дә булса әйтергә тырышудан шактый вакыт

тыелып торды. Әллә ничек шунда һичнәрсәгә исе китмәстәй, һичнәрсә турында уйлыйсы килмәстәй булып калды. Тик өзлексез җанын борчыган бер генә нәрсә аны һаман уйландыра иде.

*Ә. Еники «Әйтелмәгән васыять»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күңелендәге шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул...».* Акъәби күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Акъәби образы аша язучы нинди фикерләр җиткерә?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә Акъәби һәм Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» повестенда Сөннәтче бабай кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның милли, дини традицияләргә мөнәсәбәтендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Ул, өйлә намазыннан соң тәһарәте кыстар төсле кеби тоелганга, өйгә кайтып тәһарәтләнеп барырга уйлап, өйгә таба борылды. Күрше йортка көзге ат көтүе бирергә җыелган җыен янына килеп, сәлам биреп, мәсҗед картлары берлән сөйләшеп, акыртын гына өенә юнәлде. Ишекне ачты. Түр башында карчыгының бәрәңге арчып утырганыны күрде. Күзе карчыкның кулындагы былчыранып беткән пәкегә төште. Аның кулында сөннәт пәкесе икәнне күреп, элгәре катып калды, ахырдан ул җенләнгән кеби булды; кычкырырга, бакырырга тотынды, кулы берлән бәреп җибәреп, пәкене алды, үзе кычкырып егъларга тотынды. Аңар әллә кайдан көч керде. Кычкырып-кычкырып тиргәргә, кулы берлән бутанырга башлады:

–Чык өемнән, бәдбәхет, чык өемнән! Сәлман Фарси пәкесе, Сәлман Фарси пәкесе! Ни диярмен?! Кыямәт көнне ни дип җавап бирермен?! – дип егъларга, карчыкның кулына очраган сандыгыны, комганыны, ястыгыны йортка ыргытырга тотынды, тагы кычкырды, тагы бакырды, тагы егълады. Елан

чаккан кеше кеби кая барырга белмәде, егълап урамга чыкты. Күршедәге халыкка: “Җәмәгать, җәмәгать!” – дип, бик каты иттереп кычкыра башлады. Бөтен җыен, ут-фәлән бар дип, бабайга таба ашыкты...

Ул, шул сүзне әйткәндә өенә төртеп күрсәтте:

– Шул пәке берлән, хәзрәти Сәлман Фарси пәкесе берлән бәрәңге арчый!... – диде дә тагы егъларга тотынды.

Халык бабайны төрлечә бастырырга теләсә дә, бабай һаман кызганнан-кызды. Ул бөтенләй тилергән кеби булды. Ул, өенә таба барып, йорттагы карчыгыны күреп:

– Кит, шайтан!... Гөнаһ шомлыгы, Иблис сидеге, пәри ташландыгы, күземә күренмә!.. Талак син, талак син!.. – дип кычкырды... Карчык урамга чыгып качты. Бабай аның артыннан ястыгыны, сандыгыны, комганыны, туп уйнаган малай кеби, берсе артыннан берсене ыргыта башлады. Ул тагы егълады, тагы:

– Сәлман Фарси, шәфәгать кыл! Карчыгым бәддогасы, карчыгым бәддогасы!.. – дип, халыкка кайгысыны аңлатырга тотынды.

Ләкин теге карчык тагы йортка керергә өлгерә алмады, ул тагы сикереп торып казыкны күтәрде. Бу юлы сугарга да өлгерде, ләкин карчык качып өлгерде. Ул тагы кызды, тагы кычкыра башлады. Кулындагы пәкесене кысып, тагы әллә ниләр сөйләргә тотынды. Картлар аны бастырыр өчен төрле сүзләр сөйләргә тотындылар. Ул берсене дә ишетмәде.

Менә бердән аның кып-кызыл бите агарды. Ул калтырана башлады. Ап-ак булып авызыннан күбеге агып, һушсыз булып егылды. Хәзрәт килеп Коръән укыганнан соң аның һушы килсә дә, теле ачылмады. Пәкене никадәр алырга теләсәләр дә, кулыннан ычкындырмады. Хәзрәт килгәч, ул күзе берлән әллә нәрсә эзләнә башлады, кунакларга әллә нәрсә әйтергә теләде, ләкин әйтә алмады.

Өченче көнне хәзрәт, Коръән укып бетереп, янында утырып торганда: «Әти, кунаклар килде!» дип, этисене чакырып мәхдүм килеп керде. Бабайның күзләре нурланды; ул көлгән кеби булды; әллә нәрсә әйтергә теләгәне беленде, күзе берлән мәхдүмне чакырган кеби булды. Мәхдүм акыртын гына этисе янына килде. Бабай тагы, күзене әллә нинди мәгънәләр чыгарып, кулыны селкетә башлады. Мең бәла берлән кулыны күтәреп, мәхдүмгә таба төртте. Һәммә кешегә мәхдүмгә пәкесене, үзенчә, иң кыйммәтле мирасыннан – Сәлман Фарси пәкесене бирергә teләвене аңлатты. Мәхдүм аптырап калды. Хәзрәт алырга кушты. Алды. Бабайның йөзенә көләчлек чыкты. Ул әллә нигә шатланган кеби булды. Тагы бик авыраеп: «Алла...» – диде дә үлде.

Үзе казыган кабергә иртәгесен бөтен авыл җыелып күмде. Күрше карты аның өстенә дә каен илтеп утыртты. Ике каен бер-берсе берлән бәрелә-бәрелә, сөйләшә-сөйләшә үсә башладылар.

Көзге ягъмурлы җилдә өйнең сылаганы изрәп, ул да җимерелде. Усал сыерлар, канауны җимереп, бакчага кереп йөргәнгә, түтәлләр, бакчалар да кешелектән чыкты. Кызыл миләшләрне җыяр өчен бөтен урам малайлары миләшнең ботакларыны сындырып бетергәнгә, ул да икенче елны яфрак ярмады. Корыды.

Бер ике-өч елдан Сөннәтче бабайның йорты урынында тормыш галәмәтеннән бер нәрсә дә калмады. Ләкин зираттагы ике картайган, черегән, беткән картларның өстенә ап-ак тузлы, ямь-яшел яфраклы яшь ике каен үсте. Алар зурайды, биекләнде, түгәрәкләнде; тавышлы-тынлы, кешеләр аңламый торган тормыш берлән яши башладылар.

Бер тормыш бетте, бер тормыш башланды...

*Г.Исхакый «Сөннәтче бабай»*

**Вариант 2**

Җырларым, сез, шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю –
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш языма.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны торткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,

Үлемем дә яңрар җыр булып.

*М. Җәлил «Җырларым»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Гомрем минем моңлы бер җыр иде, / Үлемем дә яңгырар җыр булып»* юллары белән М.Җәлил нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә җыр образына нинди мәгънәләр салынган?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** М. Җәлилнең «Җырларым» һәм Ф. Кәримнең «Ант» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларда нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Юлбасарлар таптый җиребезне,
Ватан сугышына мин китәм.
Менә – балам. Син әнкәсе аның,
Балабызны тотып ант итәм.

Синең өчен, шушы балам өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән
Бер адым да артка чигенмәм...

Бәлки, соңгы тапкыр – күрештек,
Кочаклаштык, озак үбештек.

Сизә бала, карый күзләремә:
«Сакла безне!» – ди ул күңеленнән,
Ана күкрәгеннән суырып алган
Сөт тамчысы алсу иренендә.

Шушы балам өчен, синең өчен,
Нәселем өчен, Туган ил өчен,
Мылтык тотып баскан җиремнән

Бер адым да артка чигенмәм.

*Ф.Кәрим «Ант»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Каюм Насыйриның «Әбугалисина» кыйссасында капма-каршы куелган сыйфатлар.

**2.2.** М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» әсәрендә Хәнифә образы.

**2.3**. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә күтәрелгән проблемалар .

**2.4**. «Идегәй» дастанында идея бирелеше.

## 10нчы ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук алъяпкыч буган оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самовар артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та, минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга тора кебек иде. Әйтерсең, бу һич йомылмас моңсу күз аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән? Без гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек, Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да бик тирән яшерә беләме?...

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне капладык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

– Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле, – диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык...

– Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар, – диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

– Кайдан бу синдә?

– Үзем мәтәштергән булдым инде, – диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тонык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чиртկәләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

– Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең? – дидек без. – Мәдрәсәдә Сәгыйт скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

– Оста барда кулың тый! – диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шулчак мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы, – гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караш та, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем...

Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез, нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң – мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә, – моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

*Ә.Еники «Матурлык»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Без гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек, Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да бик тирән яшерә беләме?... Шулчак мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз*

*алдыгызга китерә аласызмы, – гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караштa, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы!*». Хикәяләүче бу юллар аша нинди фикер җиткерә дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына һәм аның исеменә бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әсәрдән өзектә Бәдретдин холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ә.Еникинең «Матурлык» хикәясендә Бәдретдиннең һәм Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрендә Айдарның характер сыйфатларын чагыштырып карагыз. Аларга хас сыйфатларда охшаш һәм аермалы яклар бармы?

...Барып җиттек. Тезелдек. Чыктык. Башта, бер-ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек дип әйтерлек. Бу араны атлар җиргә түгел, хәйләгә басып килделәр. Бер-беребезнең чамасын тарттык, йомшак якларны капшадык. Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады, ара-тирә йөрәксеп кычкырып та җибәрә, тик шулай да ул берәүне дә куркытмый. Аның түшәмен без шунда ук күрдек. Моннан соң ул, ничаклы тырышса да, артык сикерә алмаячак. Ул бездән, бер җир буе дип әйтерлек, алда бара, тик шулай да мине ул түгел, арттан уйнаклап килүче теге кашка байтал шикләндерә. Үз атымның чамасы үземдә, камчы тидерергә ашыкмыйм, – бар нәрсәнең дә вакыты була бит.

Ниндидер юл аермасын үттек, берәү шунда кинәт кенә:

– Һа! – дип кычкырып җибәрде, колагыма җил бәрелде, тояклар ярсу белән тупырдадылар. Күземне ачып-йомарга өлгермәдем – кашка байтал минем алга сикереп чыкты. Аның арт тоякларыннан балчык атылып минем битемә бәрелде, бераз вакыт күземне ача алмыйча бардым, ә күзне ачарга вакыт бик җиткән иде.

Алда, берничә чакрым ераклыкта, колга башындагы сөлгеләр чагылып киттеләр. Күренделәр, анңары тагын югалдылар. Хәйлә бетте, безнең аяк астында хәзер җир, Җитмәсә тагын нинди җир! Йә күтәрә ул, йә башыңны яра. Мин, ике бармагымны тешемә кысып, сызгырып җибәрдем һәм беренче мәртәбә атыма камчы селтәдем. Уен түгел икәнлекне ат та сизенде булса кирәк, кинәт сикереп алды, мин чак кына артка очып калмадым. Күз алдымда нәрсәләрдер тиз генә яктырып киттеләр, кинәт сүнеп калдылар, битемә үз атымның әчкелтем пары килеп бәрелде. Тагын шул: теге аермадан узып бер-ике генә сикердем, Госманның артына килеп бастым. Аның атының ухылдавы

ишетелә, – бу дәртлелек түгел, хәлсезлек билгесе. Минем Госманнан көләсем килде, тик көлгәнче тагын бер сикерәсе бар иде әле. Атыма тагын бер селтәнеп җибәрдем – без хәзер аның белән тигез барабыз. Тагын бер селтәнсәм мин аны артка калдырачак идем. Госманга бу ошамады. Атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде дә, минем атның алга сузылып бара торган борынына сукты. Күзем» кинәт кан бәрелде, – күрә дә, уйлый да алмадым. Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җибәрдем. Ул чайкалды, аты өстеннән очып төшеп калды. Соңыннан гына белдем, каты сугылган икән мескенгә, алты ай буена яңагын бәйләп йөрде, ә соңыннан гомерлек яра эзе калды.

*Ф. Хөсни «Йөзек кашы»*

## Вариант 2

Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сахралар тора балкып.

Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
Халык йоклый — каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.

Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
Авыл кыръенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.

Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угьлын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде тәңре каршына бармас?

*Г. Тукай «Ана догасы»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап язызыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Шигырьдә лирик төргә хас нинди үзенчәлекләрне билгели аласыз?
**1.2.2.** Нурлы ай образына нинди мәгънәләр салынган дип уйлыйсыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр**

**текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Г. Тукайның «Ана догасы» һәм С. Хәкимнең «Әнкәй» шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин
Күңелемә шулай тоела:
Пар кулыңа пар чиләгең асып,
Син чыгасың, әнкәй, коега.
Су алганчы юлга бер карыйсың,
Чиләкләрең тулгач, тагын бер.
Бала күңеле – далада, дип, бәлки,
Үпкәләп тә йөргән чагыңдыр.
Изге теләк теләп үстерден син,
Бассыннар дип, тизрәк аякка.
Шул теләгең хәзер искә төшә,
Юнәлсәм дә менә кай якка.

*С. Хәким «Әнкәй»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1. – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» романында туган якка мәхәббәт хисе.

**2.2.** Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында автор югары күтәргән сыйфатлар.

**2.3**. Мирсәй Әмирнең «Агыйдел» повестенда хатын-кыз образлары.

**2.4**. Шәриф Камалның «Акчарлаклар» повестенда символик образлар.

## КИҢӘЙТЕЛГӘН ҖАВАПЛАРНЫ ТАЛӘП ИТҮЧЕ БИРЕМНӘРНЕҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮ ҺӘМ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

### 1.1.1, 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәрен (3-5 җөмлә күләмендә) бәяләү

3-5 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| **Критерий** | **Балл** |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) имтихан тапшыручы укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк | **2** |
| б) имтихан тапшыручы укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

### Чагыштырма пландагы 1.1.3. һәм 1.2.3. биремнәрен бәяләү

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| **Критерий** | |
|---|---|
| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, авторлар позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **2** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / сорауга җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | **1** |

| | |
|---|---|
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Җавапның, әдәби текстларны чагыштырып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап чагыштырма планда языла, мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәрләр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **2** |
| б) җавап бирү барышында әсәрләрне чагыштыру җитәрлек күләмдә түгел, мисаллар файдаланып та, җавапны дәлилли алмый, мисаллар нигезле түгел / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **1** |
| в) җавап бирү барышында әсәрләр чагыштырылмый / яки кирәкле аспектта чагыштырылмый | **0** |
| **3. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **1** |
| б) сөйләм хаталары 3тән артык | **0** |
| *Иң югары балл* | **5** |

**Сочинение биремен бәяләү**

2 нче бүлекнең бирем җаваплары иң мөһимнәрдән санала, шулар арасында иң әһәмиятлесе булып беренчесе – эчтәлек ягы санала. Тикшерү барышында җавапның эчтәлеге 0 балл белән бәяләнгән очракта бирем эшләнмәгән булып санала һәм **алга таба тикшерелми**. Калган бәяләү аспектлары буенча 2нче биремнәрнең җавапларын тикшерү бланкына 0 балл куела.

Җавапны бәяләгәндә, язылган иншаның күләме исәпкә алына. Имтихан бирүчеләргә 150 сүздән ким булмаган күләмдәге текстны язу тәкъдим ителә. Әгәр инша тексты 100 сүздән ким булса, мондый эш үтәлмәгән дип санала һәм “0” балл белән бәяләнә.

| **Критерий** | |
|---|---|
| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, автор позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **3** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | **2** |
| в) сорауга җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 3-4 фактик хата | **1** |

| | |
|---|---|
| күзәтелә | |
| г) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлау, алар белән эшләү дәрәҗәсе** | **Балл** |
| а) әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр аңлап, урынлы кулланыла, җавап теоретик яктан югары дәрәҗәдә язылган | **2** |
| б) имтихан тапшыручы әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлый, әмма әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 төгәлсезлек күзәтелә | **1** |
| в) укучы әдәби-теоретик төшенчәләрне дөрес кулланмый яки әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматлы түгел, әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 дән артык хата ясый | **0** |
| **3. Җавапның, әдәби текстларны кулланып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **2** |
| б) җавапта әсәрнең (әсәрләрнең) турыдан-туры эчтәлеге генә урын ала / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **1** |
| в) җавап бирү барышында әсәр (әсәрләр) бөтенләй файдаланылмый, нигезләнми | **0** |
| **4. Җавапның эзлеклелеге, фикерне җиткерү мөмкинлеге** | **Балл** |
| а) җавап логик яктан эзлекле языла, фикерләр үзара бәйләнештә бирелә, төгәл җиткерелә | **2** |
| б) җавапның мәгънәви өлешләре үзара логик яктан эзлекле языла, әмма аерым кабатлаулар, төгәлсезлекләр күзәтелә / җавап эзлекле булып та, фикер еш кабатлана, төп темадан читкә киткән урыннар күзәтелә | **1** |
| в) җавап логик яктан эзлекле язылмаган, эзлеклелек тупас бозылган, җавапта гомуми мантыйк күренми | **0** |
| **5. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) сөйләм хаталары юк яки 1 сөйләм хатасы ясалган | **3** |
| б) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **2** |
| в) 4 сөйләм хатасы ясалган | **1** |
| г) сөйләм хаталары бик күп (5 яки аннан да артык) булып, фикерне аңлауда кыенлыклар тудыра | **0** |
| *Иң югары балл* | ***12*** |

## ТАТАР ТЕЛЕ
## 82 нче код биремнәре

### Аңлатма язуы

2020 нче елгы төп дәүләт имтиханын сочинение элементлары белән киңәйтелгән изложение язу формасында үткәрү тәкъдим ителә. Киңәйтелгән изложение укучыларның лингвистик компетенциясен (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясен (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), коммуникатив (аралашу) компетенциясен (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерә.

Вариантлар имтиханда катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә төп дәүләт имтиханы эшенең төзелеше, биремнең үзенчәлеге, аның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу вариантлардагы биремне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра, чыгарылыш сыйныф укучыларының төп дәүләт имтиханына әзерлек осталыгын булдыра.

### Эшне үтәү өчен күрсәтмә

9 нчы сыйныфны тәмамлаучы укучыларга туган (татар) теленнән төп дәүләт имтиханы өчен 3 сәгать 55 минут вакыт бирелә. Бирем 1 өлештән тора. Укучылар изложение өчен тәкъдим ителгән текстны 2 тапкыр тыңлыйлар. Беренче тапкыр тыңлаганнан соң, уйлану һәм каралама эшләү өчен, вакыт бирелә (5 минут). Текстны икенче тапкыр тыңлаганнан соң, изложение язу эше башлана. Изложение биремдә күрсәтелгән проблемага бәйле сочинение элементлары белән киңәйтелә. Укучылар әлеге проблемага бәйле иҗади фикер йөртергә һәм үз фикерләрен дөрес, логик эзлеклелектә формалаштырырга тиеш.

Язма эшне башкару барышында орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Караламадагы язулар тикшерелми!

Язма эш махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Язма эшне хаталарсыз башкарып, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

**1нче вариант**

| |
|---|
| ***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныклык итеп языгыз.*** |

**Ачсаң күңел тәрәзәләрен**

Тышка карап ял иткәндә, мин үзебезнең ишегалдында һәр көнне бер кызны күрәм. Ә беркөнне бик озак карап та кыз күренмәгәч, тәрәзәләремне яптым да киенеп тышка чыктым. Шул кыз торган йорт янына килдем. Ахырда түзмәдем, аларга керергә булдым. Әмма икенче катка күтәрелүгә, кыз белән йөзгә-йөз очраштык. Сөйләшә-сораша торгач, аның исемен дә белдем – Гөлсинә. Ул кечкенә генә бер бүлмәле фатирда әбисе белән яши икән. Әбисе бик картайган, кеше ярдәменнән башка урыныннан да тора алмый. Ә Гөлсинә үзе иртән укуга йөгерә, укудан кайткач, кибеткә яки базарга китә. Бөтен авырлык Гөлсинәгә төшә.

Беркөнне, җөрьәт итеп, тагын аларга кереп чыгарга булдым. Минем алда яп-якты, бөтен җирләре пөхтәләп җыештырылган, кечкенә булса да, иркен генә бүлмә иде. Түрдә – бердәнбер караватта – кызның әбисе ята. Аның эчкерсез рәвештә үз итеп Гөлсинә турында сөйләве минем күңелемне тиз яулап алды.

Мин түзмәдем, сорап куйдым:

– Ә аның ата-анасы кемнәр соң?

– Ата-анасын кем дип әйтим икән сиңа. Бик әйбәт кешеләр алар. Мин аларда уналты ел бала карап тордым. Аларның дүрт балалары булды. Менә шулай тыныч кына картаеп килгәндә, былтыр аякларым сызлый башлады. Урын өстенә яттым. Чирле кеше дип кыерсытмадылар, киткән чакта елашып ук калдылар. Китмә дип, бик кыстаганнар иде дә, киттем. Ә Гөлсинә баштарак килеп-китеп кенә йөргән иде, соңыннан бөтенләй минем янга күчте. «Әбекәй, син аягыңа басмыйча, мин сездән китмим», – диде. Әти-әниләре дә каршы килмәделәр. «Укуыңа зыян килмәсә, тор әйдә», – диделәр.

Карчыкның әңгәмәсен тыңлап утырганда, Гөлсинә дә кайтып керде.

– Кунак бар икән! – диде ул һәм тиз генә өстен алыштырып ашарга әзерләргә keреште. Мин бер карчыкка, бер Гөлсинәгә карадым. Мәктәп хәлләрен җентекләп әбисенә сөйләүче Гөлсинәнең дә, аны тыңлаучы карчыкның да йөзләрендә шатлык иде. Бу матур күңелле кешеләр арасында миңа да рәхәт булып китте. Мин аларның күңел тәрәзәләрен ачып карагандай булдым. (285 сүз) (*Ф.Яруллиннан*)

| **Изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Безнең ишегалдында яшәүче Гөлсинә исемле кыз. |
| **2** | Гөлсинәнең әбисе белән очрашу. |
| **3** | Матур күңелле кешеләр арасында миңа бик рәхәт булды. |

## 2нче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм tанырлык итеп языгыз.***

### Күңел күзе

Кыш буе әбисе тәрәзә яныннан китмәде. Озаграк авырган чакта Ләйлә дә шулай, тәрәзә тупсасына утырып, урамны күзәтергә ярата. Әмма әбисенең шәһәр тормышында исе юк бугай, аның карашы еракка, бик еракка – офыкка төбәлгән, ә йөзе шундый да моңсу.

– Нәрсә бар соң анда, әбием? – дип сорады беркөнне Ләйлә, бик тә зур сер ачасы килеп.

– Авылым! – диде әбисе, авыр сулап.

Кызчык аяк очларына басып караса да, әбисенең авылын тапмады.

– Кая, кая соң ул, нигә мин күрмим? – дип көйсезләнә үк башлады.

– Аны күрер өчен, күңел күзе кирәк шул, бәбкәм! – дип, оныгының башыннан сыйпады әбисе.

Кызык, анысы тагын нинди күз була икән дип гаҗәпләнде кызчык.

Түбәләрдән тып-тып тамчылар тама башлагач, әбисенә җан керде. Ләйлә еш салкын тидереп чирләп интектергәч, кышкылыкка оныгын карашырга авылдан алып килгәннәр иде аны. Шәһәргә һич кенә дә күңеле ятмады әбисенең.

– Алла боерса, сукмак төшү белән кайтып китәм, Ләйләне дә алырмын, шәһәр һавасы ярамый аңа. Авыл каймагы белән сөтен эчсә, шалкан кебек таза булыр, – дип канатланып йөрде, хәтта төенчеген дә төйнәп куйды.

Әтисенең исә моңа хәтере калды.

– Әллә бер-бер авыр сүз әйтеп рәнҗеттекме, нигә шулай ашкынасың? – дип төпченде.

– Күрмисеңмени, әбием авылын сагынган, – дип, Ләйлә әбисен якламакчы булып сүзгә кушылды.

– И, улым, – дип сыкранды әбисе, – гомер иткән оям бит ул, кәкре казыгына кадәр йөрәккә якын. Ничек шуны аңламыйсың! Күрмисеңмени, җаным коштай талпына!

– Күрмим, күрәсем дә килми, – дип, сүзне кырт кисмәкче булды әтисе.

– Күрергә күңел күзе кирәк бит аны! – дип әйтеп салды шулчак Ләйлә.

*(231 сүз) (Р.Шәриповадан)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Ләйләнең әбисе авылын сагына. |
| **2** | Яз җитү белән, Ләйләнең әбисе авылга кайтырга җыена. |
| **3** | Ләйләнең әтисе аны авылга җибәрергә теләми. |

## Знче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

### Вөждан газабы

Илмир иртә белән әнисе кушкан йорт эшләрен тәмамлады да авыл читендәге Түгәрәк күл буена ашыкты. Җан дуслары Рөстәм, Әнвәр, Рәүф күптән күл буенда иде инде. Малайлар күңелләре булганчы су коендылар, якындагы борчак басуына менеп, кузак җыеп төштеләр. Кесә, кепка тулы кузакларны бушаткач, “Инде нишлибез?” дигән сыман бер-берсенә аптыраулы караш төбәделәр. Бераз сүзсез утырганнан соң, Рөстәм тәвәккәл төс белән:

– Киттек Гали бабайлар бакчасына! – дигән тәкъдим ясады.

Малайларның җиткән көнбагыш тәмләү теләге көчле иде, башларын иеп, Рөстәм белән килештеләр.

Бакчага Илмирны кертергә булдылар. Ул, арткы торыкның рәшәткәсен каерып, бакчага үткәч, чәчкәсен коеп, кояшта саргайган көнбагыш башларын өзде. Дүртенчесенә үрелгән иде, каршында басып торучы чал чәчле Гали картны шәйләп, дертләп китте.

Көтелмәгән хәлгә хәйран калган малай, юеш борынын тарта-тарта, бабайга карап катты.

– Мә, балам, ал, иптәшләреңә дә өлеш чыгар. Башкача рәшәткә җимермәгез, торык яңартырга көчем чамалы хәзер. Ашыйсыгыз килсә, өйгә килегез. Әбиегезнең киптереп куйганы да хәтсез җыелды инде. Ә үзегез үстерергә уйласагыз, орлыгын да бирермен, үзең үстергәннең кадере дә була аның. Болай түбәнчелеккә төшү егет кешегә хас түгел, улым...

Бабайдан гафу үтенеп, бакчадан бер кочак көнбагыш күтәреп чыккан Илмирны җан тирләренә батып көткән дуслары каршылады.

– Нәрсә, өлеш эләктеме бабайдан?

– Юк, Гали бабай башкача рөхсәтсез бакчага кермәскә, көнбагышны сорап алырга кушты.

Җиргә тезеп салынган эре көнбагыш башларын үрелеп алып чүпли башларга берсенең дә ояты җитмәде. (211 сүз) *(А.Хәйртдиновадан)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Илмир дуслары белән су коенып туйганнан соң, Гали бабайлар бакчасына китте. |
| **2** | Бакчада аны көнбагышлар һәм Гали бабай каршылады. |
| **3** | Илмирның бакчадан чыкканын дуслары көтеп торды. |

**4нче вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

## Фронтовик

Көтмәгәндә, күп юудан агарып беткән гимнастеркасына өч Дан ордены таккан фронтовик карт белән таныштым. Уйлап та тормыйча, карт ветеранның сугыш юлларында тап булган иң истәлекле хатирәсе хакында сорадым. Әңгәмәдәшем шунда ук уйчанланып, басылып калды һәм сөйләп китте.

Кырык беренче елның көзе иде. Мәскәү артында оешкан бер частька эләгеп, алгы сызыкка китеп барам. Каршыга хәлсезләнгән, тәмам бетәшкән, тавыш-тынсыз гына атлаучы сугышчылар төркеме очрап тора... Яралылар төшәлгән ат-арбалар үтеп-сүтеп йөри... Кинәт каршыбызга ялгыз ат очрады. Тукталыштык. Үрелебрәк карасак, арбада, канга буялып, бер бала ята. Үзе тумыштанмы, әллә сугыш сөременнәнме − кап-кара, чәчләре генә – ап-ак.

Мин үземне чын солдат итеп әнә шул очрашуда тойдым. Сугышчан гомеремнең исәбе шул очрашудан башланды. Малайның җансыз гәүдәсе, ап-ак чәче, төпсез, тонык күз карашы... Алар мине дүрт еллык фронт гомеремдә артымнан калмый озатып йөрделәр. Бик авыр чакларда да, үлем тырнагыннан котылып булмас кебек тоелганда да, күз алдыма әнә шул малай килә иде. Ул миңа: «Әле бит синең чәчең дә агармаган, ник бирешәсең?» − ди кебек... Ялгызым өч фашист әзмәвере каршына барган чаклар булды, тәнемдә йодрык кадәрле снаряд ярчыгы була торып, ике чакрым шуышып үткән вакытлар бар иде. Теге вакытта күргән ак чәчле малай мине афәт-бәлаләрдән исән-имин котылырга булышып торды.

Хатирәләреннән бушанган фронтовик карт кабат, тыйнак кына елмаеп, моңсуланды, уйчанланды... Миңа да бик авыр иде. Үзе дә сизмәстән, очраклы рәвештә генә юлыма тап булган бу абзый миңа «яшәү мәгънәсе», «иманлылык» төшенчәләрен үз эченә алган һәм алдагы гомеремдә мең мәртәбәләр ярдәмгә киләчәк рухи ныклык, ихтыяр көче биреп киткән иде... (240 сүз)

*(Г. Гыйльмановтан)*

| **Изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Фронтовик карт белән таныштым. |
| **2** | Фронтовик карт хатирәләре белән бүлешә. |
| **3** | Фронтовик карт сөйләгәннәрнең миңа тәэсире. |

## 5нче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

### *Хезмәткә хөрмәт*

Беркөнне без бер танышым белән иртәнге тыныч, бик матур вакытта Аккош күле янындагы яшел алан аша сузылган сукмак буйлап сөйләшә-сөйләшә кайтып килә идек. Менә шушы карап туймаслык гүзәл аланда, аллы-гөлле чәчәкләр үскән палас өстендә ертылып ташланган газета кисәкләре, шешә ватыклары күреп сәерсенеп калдык. Хәер, нигә гаҗәпләнергә? Ял көннәреннән соң безнең урманнарыбызда, елга һәм күл буйларында бу инде гадәти күренешкә әйләнеп бара. Кемнәрдер, ялга чыгып, рәхәтләнеп хозурланалар да киләсе атнада тагын шунда ук ял итәсе урыннарын шулай чүп-чар белән «бизәп» китәләр. Ә бу юлы без анда-монда ташланган икмәк телемнәрен дә күрдек. Хәтта бер агач төбендә бөтен бер икмәк аунап ята иде.

Үзебез дә сизмәстән, шул икмәккә карап туктадык та телсез калган кебек булдык. Шулай рәхимсез ташланып калдырылган изге икмәк өчен безгә дә бик уңайсыз булып тоелды. Дөресен әйткәндә, без оялдык. Кемнеңдер бу мәрхәмәтсезлеге өчен без дә җаваплы идек шикелле. Бу икмәкне кем ташлаган? Ул рәхимсез бәндәнең исеме ничек? Имзасын язмаган, тамгасын да калдырмаган. Бездә тәртип бозучыларга каршы закон буенча чара күрелә, ә менә синең белән нишләргә соң? Сиңа карата да яңа закон чыгарыргамы?

Андый закон бар инде. Ул бик күптән, кешелек белән бергә, бер көндә туган. Ул законның исеме – намус. Бу беркайда да язылмаган закон. Икмәккә ихтирам, кешегә мәхәббәт! Бу сүзләр йөрәктә яши. Шуңа күрә дә алар тормыш законы дип аталырга хаклы. Бу законны үтәү – һәркемнең изге бурычы. (218 сүз)

*(Н. Дәүлидәндән)*

| **Изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Танышым белән аланда күргәннәр. |
| **2** | Икмәкне кем ташлаган? |
| **3** | Язылмаган закон. |

**6нчы вариант**

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

**Борчылу**

Бу өйдә ул инде күптәннән яши иде. Бирегә ничек килеп эләккәнен хәзер бөтенләй хәтерләми, чөнки ул вакытта кечкенә иде әле. Ләкин бер нәрсәне ул яхшы хәтерли: кара мыеклы кеше аның алдына сөт салынган чынаяк куйды. Тамагы туйгач, көчек койрыгын болгады, һәм шул вакытта аның күңелендә бу кешегә карата ихтирам хисе уянды. Бирегә аны яраталар иде. Эт берәр шуклык эшләсә дә, болай гына әрлиләр. Ул үзе дә моны сизә, койрыгын селкетеп, хуҗаның күзенә карый. Хуҗа да моны аңлый һәм елмаеп куя, шул вакытта этнең эченә җылы йөгерә.

Башта алар өчәү генә яшәделәр: ул, хуҗа, хуҗаның әнисе. Аннары дүртәү булдылар: өйгә килен төште. Ә беркөнне, бәби алып кайткач, бөтен игътибар шул балага күчте. Тик хуҗаның гына эткә булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, ул аны элеккечә ярата иде. Хуҗа эштән көн дә бер үк вакытта кайта. Эт аны балконда утырып көтеп ала. Хуҗасы күрше йорт артыннан килеп чыгу белән, эт шатлыгыннан өрә башлый. Нәни дустын күреп, хуҗаның да йөзе яктырып китә.

Беркөнне өй янына кайтып җиткән хуҗаны ниндидер кеше туктатты. Ул, кычкырып, аңа нәрсәдер аңлатырга тырыша, кулларын болгый. Хуҗаның шул кеше белән торуы этне борчуга салды. Эт аңлады: бу кеше хуҗаны җибәрми. Бу минутта эт өчен шушы кешедән дә явыз кеше юк иде. Аның түземлеге бетте, ул аска карады һәм ... җиргә очты. Эт, асфальтка бәрелеп, бер-ике тыпырчынды да тынып калды.

Ирләр бернәрсә аңламадылар, башта эткә, аннары дүртенче кат балконына карадылар. Берничә секундтан хуҗа исенә килде, эткә таба иелде. (234үз)

*(С. Шәмсидәндән)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Эт бу өйдә күптәннән яши. |
| **2** | Хуҗаның эткә мөнәсәбәте. |
| **3** | Ниндидер кеше хуҗаны тоткарлап тора. |

## 7нче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныклык итеп языгыз.***

### Урманның да җаны бар!

Бүген алар урманга барырга уйладылар. Күбесенең туган көннәре бер тирәдә. Гөлнараларның сыйныфы унбиш яшьләре тулганны билгеләп үтәргә булды. Соңгы уку елында матур хатирәләр калсын әле.

Алар урманга килеп җиткәндә, кояш шактый күтәрелгән иде инде. Агачлар тагын да яшәреп киткәндәй тоелды. Чәчәкләр дә көндәгегә караганда матуррак! Тирә-якка соклана-соклана сукмактан кереп барганда, Гөлнара кычкырып җибәрде: «Ә без бит әле урманнан рөхсәт сорамаган!» Бу сүзләрдән кайсы көлде, ә кайберләре тезелешеп басып: «Урман бабай, керергә мөмкинме? Мөмкин булса, бер кошыңны сайратчы», – диде. Шулчак, чыннан да, бер кошчык бик моңлы итеп сайрап җибәрде.

Сыйныфташлары уйнаганда да, бәрәңге пешергәндә дә, ул эшчән кырмыскаларны карап, урман докторы тукранның тавышын тыңлап йөрде. Табигать барысын да аңлый, ә дус егетләре, кызлары ни өчен аңламыйлар соң аны? Сәеррәк шул ул: башкалар кочак-кочак чәчәк җыйганда да Гөлнара берничәне генә өзә, иптәшләре агач ботагын сындырганда да үзенең кулларында авырту сизгәндәй була. «Аерылып йөрү килешмәс», – дип, Гөлнара дуслары янына килде. Сөйләшеп, көлешеп утыргач, кәефе дә күтәрелеп китте.

Кайтыр вакыт җитте. Алар җыена башладылар. Гөлнара консерв банкаларын, кәгазь кисәкләрен җыярга тотынды. Бер-ике иптәше дә аңа килеп кушылды. Урманны пычратып калдырырга ярамас! Кайбер сыйныфташлары: «Җыегыз, җый!» – дип көлештеләр. Әмма ул бер сүз дә дәшмәде, йөрәге әрнеп уйлады гына: «Юк, аңламыйлар мине. Әнә тукран да агачларны кортлардан коткара, кырмыскалар да урманны чистарта. Ә без?» (208 сүз)

*(Ф. Бәдретдиновадан)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Гөлнара сыйныфташлары белән урманга килде. |
| **2** | Гөлнара урманның җаны бар дип саный. |
| **3** | Урманны пычратырга ярамый. |

## 8нче вариант

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

## Сыерчыклар

Туплар гөрелтесенә кушылып, яз килде. Сугыш һәм яз. Берсен берсе инкарь иткән шушы ике дошман бергә җитәкләшеп килделәр. Яз үзенең шифалы сулышы белән табигатьне тергезде. Агачлар бөреләрен ачтылар. Тургайлар һавага күтәрелде. Солдатларның талчыккан йөзләре җиңү шатлыгыннан нурланды.

Буш арада без, солдатлар, сыерчыкларның сайравын тыңлап утырабыз. Өйләребезне сагынабыз. Баласы бары — баласын сагынып көрсенә... Сөйгәне бары — сөйгәнен сагынып ямансылый. Иске хатларны чыгарып укыйбыз, карточкалар карыйбыз. Ә сыерчыклар корт ташыйлар, бала туйдыралар. Кайчан гына карама, я этиләре, я әниләре атылып кайтып җиткән була. Алып кайткан азыкны эти-әни боларның авызларына төя-төя дә, ширрр дип кычкырып, яңадан китеп бара. Бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле шулай өзлексез оча, өзлексез ташый, ашата, өстәвенә ширр дип юатып китәргә дә онытмый торган бу ата белән ананың хәлдән таеп егылмавына мин шаклар катам.

Бер тапкыр, төн урталары булгандыр. Эшләп утыра идек. Кинәт түшәм ишелеп төшә башлаган кебек булды. Тәрәзә пыялалары, чәчрәп, идәнгә коелдылар.

Иртән, бит юарга дип, ишегалдына чыксак, йортыбызның кәрнизе умырылып төшкән. Кәрниздәге сыерчык оясы җирдә кирпеч арасында аунап ята. Әниләре, күңелсез генә сызгырынгалап, өй кыегында утыра. Башын борып, безгә таба карый, гүя ул бездән ярдәм көтә. Никадәр хезмәт әрәм китте! Никадәр ана мәхәббәте, йөрәк җылысы, акыл һәм мускул көче җилгә очты. Дөньяда яңадан зур сугыш уты кабынса, күпме ананың мәхәббәтен, балага түккән йөрәк канын әрәм итәчәк! (208 сүз)

*(И.Газидан)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Сугыш һәм яз. |
| **2** | Содатлар сыерчыкларны күзәтәләр. |
| **3** | Төнлә булган хәл. |

**9нчы вариант**

| |
|---|
| ***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.*** |

**Исемсез күл**

Сүзендә тора белә икән Нәгыйм абый, Рөстәмнең мәктәптән кайтканын көтеп торган. Карурманга барырга күптән хыялланып йөри иде Рөстәм. Алар, умарталыкны сул якта калдырып, ат юлы белән кереп киттеләр. Агач кәүсәләре туннеле аларны «Үрдәкле күл»гә алып чыкты. Бу күл — җиргә уелып кергән зур түгәрәк көзге сыман. Өслегендә, кояш нурларын үзләренә ияртеп, кәрәкәләр сикерешә. Язгы гөрләвекләр күлне тиргәнәйтә, ә яңгырлар саегудан саклый. Күл янында син үзеңне хыялый бер дөньяда дип хис итәсең. Рөстәм монда җае чыккан саен килергә тырыша. Я җир җиләге җыючыларга, я балан, чикләвеккә килүчеләргә иярә. Ә бүген ул – күршесе Нәгыйм абый белән. Күз җиттеме, Нәгыйм абый ике көпшәле ау мылтыгын кулына ала. Санап карасаң, аның мылтыгы ничәмә-ничә тапкыр атылгандыр инде бу якларда. Карурман — бай урман бит ул. «Үрдәкле күл» кебек күлләре дә берәү генә түгел.

Күлгә санаулы адымнар гына калгач, Нәгыйм абый үзе китте. Агачтан агачка бәрелеп, шартлау авазы яңгырады. Куркудан тигезле-тигезсез хәрәкәтләр ясап, ике якка ике кыр үрдәге күтәрелде. Тагын шартлау. Куркынган үрдәкләр ике яклап күлне әйләнеп үттеләр дә, кайдадыр еракта-еракта очрашып, бер ноктага әйләнделәр. Шартлау авазы камышлар арасына кереп югалгач, кинәт кенә тынлык урнашты. Әйтерсең бу тынлык Нәгыйм абыйга, Рөстәмгә, хәтта Актырнакка да уйланыр өчен бирелгән иде.

Хәер, Рөстәмне уйландырганы монысы түгел. Кайтыр юлның зарыктыргыч бер минутында Нәгыйм абыйсы зарланырга кереште:

– Әзәйде үрдәкләр. Элек, ичмасам, ау дисәң дә ау иде. Мә, мылтыкны тотып кайт.

Рөстәм мылтыкны алмады. Бер уй тынгы бирми иде аңа: бу күл элек «Торна күле» дип аталган, хәзер исә анда торнаның каурые да юк. Инде «Үрдәкле күл» диләр. Тора-бара «Кәрәкәле күл» диярләр. Ә кәрәкәләрен дә тотып бетергәч, «Исемсез күл» булып калырмы икән? (260 сүз)

*(К.Ә. Кәримовтан)*

| Изложение өчен текст турында белешмә | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Нәгыйм абый белән Рөстәм урманга китте. |
| **2** | Шартлау авазы үрдәкләрне куркытты. |
| **3** | Рөстәмгә бер уй тынгылык бирмәде. |

## 10нчы вариант

***Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң кызыл юлдан текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.***

### Болын чәчәкләре

Мин шәһәрдә туып үстем. Ләкин һәр җәйне мине авылга – әбиләремә кайтаралар иде. Ул кайтуларны мин әкият дөньясына кайткандай көтеп ала идем. Шәһәрнең кырыс режимыннан соң, кыш буе мәктәп белән үзем яшәгән йорт арасыннан башка дөнья күрмәгән бер кыз бала өчен авыл ул могҗиза иде! Ул әкият иде. Мин, авылга кайтуга, аякларымнан кыйммәтле шәһәр туфлиләрен салып ташлыйм да болынга йөгерәм. Андагы чәчәкләр минем билемә җитә. Шунда ук мең төрле бөҗәкләр мәш килә, болын өстендә әллә нинди кошлар сайрый. Чәчәкләр, иелеп-иелеп, минем битләремнән, күзләремнән үбеп алалар, муенымны кытыклыйлар. Мин аларны өзмим, өзгәч, алар шунда ук шиңәләр, ямьсезләнәләр.

Ә беркөнне, бирегә йөгереп килгәч, мин чәчәкләремне тапмадым. Чәчәкләр бер рәт булып җиргә ауганнар. Мин, елый-елый, печән чабучы ирләр янына йөгерәм.

– Ник тиясез сез ул чәчәкләргә?! – дип кычкырам мин килә-килешкә.

Мин аларның җавапларын тыңлап та тормыйм.

Икенче җәйдә мин инде болынның чабылачагын алдан ук белә идем. Өченче җәйдә мин инде аның чабылырга тиешлеген аңладым. Калган җәйләрдә мин инде беркайчан да, елый-елый, ул болынга йөгермәдем. Барсам да, тыныч кына, ял итәргә генә бара идем. Тик беркайчан да, беркайчан да мин ул чәчәкләрне өзмәдем! Минем балачак хыялларымны шулай үткен чалгы белән бер селтәнүдә юк итә алсалар да, матурлыкка табынган җанымны сындыра алмадылар. Мин ул чәчәкләрне беркайчан да өзмәдем. (203 сүз)

*(Ф.Бәйрәмовадан)*

| **Изложение өчен текст турында белешмә** | |
|---|---|
| **Абзац номеры** | **Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)** |
| **1** | Һәр җәй авылга кайтуга мин болынга йөгерәм. |
| **2** | Ә беркөнне мин чәчәкләрне тапмадым. |
| **3** | Матурлыкка табынган җанымны сындыра алмадылар. |

**Язма эшне бәяләү критерийлары**

*1 нче таблица*

| № | Критерий | Балл |
|---|---|---|
| **ИК1** | **Изложениенең эчтәлеге** | |
| | Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган **барлык** мәсьәләләр язмада урын алган. | 2 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма**<br>бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 1 |
| | Текстның эчтәлеге ачылган,<br>**әмма**<br>бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән) | 0 |
| **ИК2** | **Язманың мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге** | |
| | Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә:<br>- логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган;<br>- текст кызыл юлларга дөрес бүленгән | 3 |
| | Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә,<br>**әмма** бер логик хата бар<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар | 2 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** ике логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән | 1 |
| | Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган,<br>**әмма** икедән артык логик хата<br>**яки** кызыл юлны билгеләүдә икедән артык хата җибәрелгән | 0 |
| **ИК3** | **Язманың композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хатасы бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар. | 0 |
| **ИК4** | **Дәлил-мисал (-лар) ның булуы** | |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (**2 дән ким булмаган дәлил китергән, шуларның берсе матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка карый**). | 3 |
| | Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, **2 дән ким булмаган** дәлил китергән),<br>**яки**<br>**матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка караган 1 генә дәлил китергән**. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Укучы фикерен белдергән, белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып дәлилләгән (**1** дәлил китергән). | 1 |
| | Укучы фикерен белдергән, **ләкин дәлилләмәгән,**<br>**яки**<br>укучы фикере формаль рәвештә генә (мәсәлән, “Мин автор фикере белән риза / риза түгел”) бирелгән,<br>**яки**<br>укучы фикере язмада бөтенләй чагылыш тапмаган. | 0 |
| **ИК1-ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл** | | 10 |

**Язма эшнең грамоталылыгы һәм анының фактик төгәллеге аерым бәяләнә**

*2 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә, изложениенең күләмен исәпкә алырга кирәк. Язма эшнең гомуми күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш.

2 нче таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 150 һәм 150 сүздән күбрәк булган изложениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 100-149 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК – 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК – 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК – 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 75 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **20.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-5 балл – «2» ле билгесе;

6-10 балл – «3» ле билгесе;

11-15 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 5 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 5 баллдан кимрәк балл җыйса, «3» ле билгесе куела.

16-20 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 10 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 10 баллдан кимрәк балл җыйса, «4» ле билгесе куела.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ
## 72 нче код

### Аңлатма язуы

Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек өчен материаллар 9 нчы сыйныфта имтиханга әзерләнүчеләргә йөз тотып төзелде. Аның төп максаты – укучыларга сайлап алу имтиханына мөстәкыйль әзерләнергә юнәлеш бирү.

Әлеге материаллар укучыларда контроль бәяләү материалларының структурасы, биремнәрнең күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм гомумән киң җәмәгатьчелектә бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый.

Әлеге мәгълүматлар барысы да укучыларга татар әдәбиятыннан сайлап алу имтиханына әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итәр.

### Биремнәрне башкару өчен күрсәтмә

Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эше 2 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлек тәкъдим ителгән әдәби текстларга эчтәлек һәм форма ягыннан бәя бирүне күздә тота. Текстларны башта игътибар белән уку, бары шуннан соң гына әсәргә яки тәкъдим ителгән өзеккә карата куелган сорауларга җавап бирә башлау мөһим. Беренче бүлектә ике вариант тәкъдим ителә. Укучы үз теләге белән шуларның БЕРСЕН генә сайлап алып эшләргә тиеш. Эпик яки драма әсәренә анализны эченә алган беренче вариантта киңәйтелгән җавап таләп иткән 3 сорау тәкъдим ителә. Лирик әсәргә анализны эченә алган икенче вариантта киңәйтелгән җавап таләп иткән 3 сорау бирелә.

Беренче бүлектәге беренче һәм икенче вариантлардагы 1.1.1., 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәренә җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә, 3-5 җөмлә күләмендә формалаштыру мөһим. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Өченче бирем исә (1.1.3. һәм 1.2.3.) чагыштырма планда җавап язуны таләп итә һәм аны 5-8 җөмлә күләмендә формалаштыру сорала.

Өченче бүлек дүрт сочинение темасын үз эченә ала. Алар аерым әсәрләргә мөнәсәбәтле кечкенә күләмле сочинение язуны күздә тота. Җавап бирү барышында шуның БЕРСЕНӘ генә сочинение форматында 150 сүздән дә ким булмаган сочинение язу сорала, 100 сүздән дә ким булган язмалар 0 балл белән бәяләнә.

Биремнәрне башкару өчен 210 минут вакыт каралган. Эшнең беренче бүлеген башкару өчен – 2 сәгать, өченче бүлекне үтәүгә калган вакыт күздә тотыла.

## 1нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Мин, пәрдә алдына чыгып, спектакльнең биш минуттан башланачагы, Галиябану ролендә яңа артистка уйнаячагы турында хәбәр бирдем. Көчле алкышлар мәктәпне күтәрә яздылар...

Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты.

Андый көчле җырны, андый йөрәк җырын гомеремдә беренче тапкыр ишеткәнмендер. Шул кадәр дәртләнеп, шул кадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, әйтерсең лә ул чын-чынлап Галиябану кичергәннәрне үз йөрәгендә кичерә. Аның вакытлыча гына Галиябану роленә кергән һәвәскәр артистка икәнлеген онытасың. Йөрәгең үзеңә дә сиздермәстән, аның йөрәге белән кушыла. Ул куанганда куанасы, ул көлгәндә көләсе килә. Ул боекканда боегасы, ул елаганда аның белән бергә елыйсы килә. Бер күтәрелеп, бер төшеп сулый торган калку күкрәгеннән агып чыккан үтә саф тавышның кеше тавышы булуына ышанасы килми. Анда гади кешегә аңлашылмый торган ниндидер сер яшерелгәндер сыман тоела...

Бүгенге кичәнең җитәкчесе – үзенә күрә режиссеры булуым мине беразга айнытты. Бу сихерле музыка әсирлегеннән йөрәгемне тартып алып, үзен үзе оныткан залга карадым. Залдагылар, чын-чынлап, үзләре үзләрен онытканнар иде. Бик күпләрнең кыяфәтләре миңа көлке тоелды. Кем нинди хәлдә булса, гипноз белән йоклатылган шикелле, шул хәлендә катып калган. Күпләрнең аскы ияклəрен дә ябып тотарлык ихтыяры калмыйча, авызлары ачылган, күпләр муеннарын тота алмыйча, көлке кыяфәтләргә кереп, башларын кыегайтканнар, һәрберсе үзенә бер төргә ия булган күзләр, барлык көчләренә киерелеп ачылып, сәхнәгә текәлгәннәр... Бөтен зал шулай катып калган.

Бу тиңе булмаган йөрәк көче алдында үзен үзе югалтмаган бер генә кеше күрдем мин – ул Низамый иде. Аның аптырашта калган ачулы күзләре ниндидер авыр сорауга җавап эзлиләр. Ләкин мондый минутта кем аңа җавап бирсен. Аның барлыгын белүче дә юк... Ул, залда урнашкан йөрәк тынлыгын җимерергә теләмәгән сыман, әкрен генә урыныннан кузгалды. Кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады. Аның чыгып китүен миннән башка беркем күрмәде дә, сизмәде дә. Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым. Йөрәгем яңадан Артыкбикә йөрәге белән тоташты.

*М.Әмир «Агыйдел»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: «*Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым. Йөрәгем яңадан Артыкбикә йөрәге белән тоташты*». Ильяс ни өчен җиңүче кебек хис итә? Әлеге өзектә аның холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.2.** Әсәрнең идеясен ачуда Артыкбикә образының роле нинди? Аның функциясен ачыклап языгыз.

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** М.Әмирнең «Агыйдел» повестенда Ильяс һәм Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясендә егетнең кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның үзләренең яраткан кызларына мөнәсәбәтендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

...Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

... Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йә, Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы куркынып, аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды...

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи халәтендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына – Таһирәнең кул сузымы гына җирдән җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да, барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, Туган ил җыры... Аһ, моңардан да кадерле һәм ләззәтле нәрсә булырга мөмкинме?!

*Ә.Еники «Кем җырлады?»*

### Вариант 2

Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч я сабырлык,
Сиздермичә ярдәм иткән иткәнсез –
Сез иң күркәм кеше икәнсез.

Балаларның теле – кыңгырау,
Гел чыңгылдый – ява мең сорау.
Барысына да җавап биргәнсез –
Сез иң галим кеше икәнсез.

Укып чыгып, дөнья тануны,
Бәхетебезне эзләп табуны
Зур ышаныч белән көткәнсез –
Сез иң сабыр кеше икәнсез.

Мактагансыз тиеш урында,
Яклагансыз тиеш урында.
Күңелебезгә ак нур сипкәнсез –
Сез иң гүзәл кеше икәнсез.

*Ф.Яруллин «Сез иң гүзәл кеше икәнсез»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** «*Сез иң гүзәл кеше икәнсез*» юлларында Ф.Яруллин гүзәллек төшенчәсен ничек аңлый? Аңа нинди мәгънәләр сала?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик төргә хас нинди үзенчәлекләрне билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Ф.Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» һәм Х.Туфанның «Туган тел турында җыр» шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И безнең батыр телебез,
И безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

*Х.Туфан «Туган тел турында җыр»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** М.Юнысның «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» повестенда сугыш темасы.
**2.2.** Г.Тукай иҗатында күтәрелгән проблемалар.
**2.3**. Г.Камалның «Беренче театр» комедиясендә Хәмзә бай образы.
**2.4**. М.Җәлил иҗатында яшәү һәм үлем турында уйланулар.

## 2нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!..

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңелем еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән сагынасыңмы, дип сорыйлар. Минем бугазыма төер тыгыла. Мин төерне йота-йота җавап язам:

*Телеграм баганасы – олы юлга маяк ул,*
*Сагынасыңмы дип сорыйсыз – сагынмаган кая ул!*

Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге Туган ил!

*Г.Кутуй «Сагыну»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның*

*суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем».* Хикәяләүче күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә хикәяләүче холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Кутуйның «Сагыну» нәсерендә хикәяләүче һәм Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясендә егетнең кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның сагынуында нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

...Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

... Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йә, Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы куркынып, аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды...

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи халәтендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына – Таһирәнең кул сузымы гына җирдән җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да, барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, Туган ил җыры... Аһ, моңардан да кадерле һәм ләззәтле нәрсә булырга мөмкинме?!

*Ә.Еники «Кем җырлады?»*

## Вариант 2

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Көлмәк җиңен ертасымы? –
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада.
– Кайт!. – дип хатлар килделәр...
Юллар озын иделәр...
Кайттым.
– Бусы – алкалары,
Бусы – кабере... – диделәр.
Әгәр тагын килсәләр,
Сау! – дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.
Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы? –
Бәйлисе бар йөрәкне...

*Х.Туфан «Кайсыгызның кулы җылы?»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** «*Кайсыгызның кулы җылы? – / Бәйлисе бар йөрәкне...*» юлларында автор нинди фикер җиткерә дип уйлыйсыз? Җылы куллар образына ул нинди мәгънәләр сала?

**1.2.2.** Шигырьдә нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Х.Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» һәм М.Җәлилнең «Катыйльгә» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә;
Кирәк икән, үләм аягүрә,

Балта белән башым киссәң дә.
Меңен түгел, бары йөзен генә
Юк итәлдем синең сыңарның.
Һәм халкымнан, кайткач, шуның өчен
Мин тезләнеп гафу сорармын.

*М.Җәлил «Катыйльгә»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.
**2.2.** Ф.Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда автор идеясе.
**2.3**. И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә Сәет һәм Мөнирә образлары.
**2.4**. М.Әмирнең «Агыйдел» повестенда мәхәббәт темасы.

**Знче ВАРИАНТ**

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

...Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез!

Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең, мәхшәр көне!

Старостаның бер кулында зур сөлге – бусы икенче килгәнгә билгеләнгән.

Тузан, шау-шу эчендә староста, ялгышыпмы, ничектер, чапанны Күк биягә сузды, минем Алмачуарның муенына сөлге ташлады:

– Син икенче килдең бугай, – ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем. Камчы тигәндерме, юкмы – белмәдем...

–Аны карап торырга вакыт та юк: чабып килгән атны туктатырга ярамавы һәркемгә билгеле бит!

Ул арада Сафа бабай, әткәй, күршеләр килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар. Һәммәсе мактый, һәммәсе рәхмәт укый. Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап:

– Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең, – ди.

Әткәй Алмачуарны җитәкләп йөртә башлады. Мин яулыкны ташлап, кәләпүш кидем дә кайнашып торган халык туфанына барып кердем.

Малайлар мине куркыта башладылар:

–Камчы белән сугып, старостаның битен яргансың. Ну, бирер үзеңә дә кирәгеңне! – диештеләр.

Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе чыннан да ярылган булса кирәк: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләнгән.

Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым. Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

–Мин бала чакта үзем дә атка менеп күп чапкан кеше... Алдан килеп тә, икенченең бүләген бирсәләр, җан түзәлми аңа... мин сиңа ачуланмыйм, арыгансың, бар кайт инде, – дип миңа егерме тиенлек көмеш бирде.

Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.

*Г.Ибраһимов «Алмачуар»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән**

**күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем»*. Закир күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Закир холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясендә Закир һәм М.Әмирнең «Агыйдел» повестенда Ильяснең кичерешләрен чагыштырып карагыз. Нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Мин, пәрдә алдына чыгып, спектакльнең биш минуттан башланачагы, Галиябану ролендә яңа артистка уйнаячагы турында хәбәр бирдем. Көчле алкышлар мәктәпне күтәрә яздылар...

Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты.

Андый көчле җырны, андый йөрәк җырын гомеремдә беренче тапкыр ишеткәнмендер. Шул кадәр дәртләнеп, шул кадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, әйтерсең лә ул чын-чынлап Галиябану кичергәннәрне үз йөрәгендә кичерә. Аның вакытлыча гына Галиябану роленә кергән һәвәскәр артистка икәнлеген онытасың. Йөрәгең үзеңә дә сиздермәстән, аның йөрәге белән кушыла. Ул куанганда куанасы, ул көлгәндә көләсе килә. Ул боекканда боегасы, ул елаганда аның белән бергә елыйсы килә. Бер күтәрелеп, бер төшеп сулый торган калку күкрәгеннән агып чыккан үтә саф тавышның кеше тавышы булуына ышанасы килми. Анда гади кешегә аңлашылмый торган ниндидер сер яшерелгәндер сыман тоела...

Бүгенге кичәнең җитәкчесе – үзенә күрә режиссеры булуым мине беразга айнытты. Бу сихерле музыка әсирлегеннән йөрәгемне тартып алып, үзен үзе оныткан залга карадым. Залдагылар, чын-чынлап, үзләре үзләрен онытканнар иде. Бик күпләрнең кыяфәтләре миңа көлке тоелды. Кем нинди хәлдә булса, гипноз белән йоклатылган шикелле, шул хәлендә катып калган. Күпләрнең аскы ияклəрен дә ябып тотарлык ихтыяры калмыйча, авызлары ачылган, күпләр муеннарын тота алмыйча, көлке кыяфәтләргә кереп, башларын кыегайтканнар, һәрберсе үзенә бер төргә ия булган күзләр, барлык көчләренә киерелеп ачылып, сәхнәгә текәлгәннәр... Бөтен зал шулай катып калган.

Бу тиңе булмаган йөрәк көче алдында үзен үзе югалтмаган бер генә кеше күрдем мин – ул Низамый иде. Аның аптырашта калган ачулы күзләре ниндидер авыр сорауга җавап эзлиләр. Ләкин мондый минутта кем аңа җавап бирсен. Аның барлыгын белүче дә юк... Ул, залда урнашкан йөрәк тынлыгын җимерергә теләмәгән сыман, әкрен генә урыныннан кузгалды. Кепкасын кулына тоткан килеш, аяк очларына гына басып, ишеккә таба атлады. Аның чыгып китүен миннән башка беркем күрмәде дә, сизмәде дә. Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым. Йөрәгем яңадан Артыкбикә йөрәге белән тоташты.

*М.Әмир «Агыйдел»*

**Вариант 2**

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән:
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»

*Г.Тукай «Милли моңнар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Әлеге шигыре белән Г.Тукай нинди фикерләр җиткерә дип уйлыйсыз? Моң образына ул нинди мәгънәләр сала?

**1.2.2.** Шигырьдә нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Г.Тукайның «Милли моңнар» һәм Х.Туфанның «Кемнәр сез?» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Һәр елда
Бөек Тукайның
Бәйрәме таңы туса
Эндәшә сезгә, яшьләргә,
Һәйкәлдән Җәлил Муса:

«Кемнәр сез?
Безнең дәваммы?
Һәм безнең нәселме сез?
Тукайлар изге йоласын
Үтәргә әзерме сез?

Якладым соңга кадәр мин
Туган ил гадәтләрен,
Кулымны бәйләсәләр дә
Телемне бәйләтмәдем!

Сез балык баласы түгел,
Сез халык баласы бит.
Киләчәк көнгә Тукайны
Сез алып барасы бит!

Киселде башлар... тиделәр...
Тик телгә тидертмәдек;
Агабыз Тукай йөзенә
Каралык китертмәдек!» –

Һәр елда бөек Тукайның
Бәйрәме таңы туса

Эндәшә сезгә һәйкәлдән –
Эндәшә шулай Муса.

*Х.Туфан «Кемнәр сез?»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Г.Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.
**2.2.** Ф.Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда Фәнияр образы.
**2.3**. И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә мәхәббәт темасы.
**2.4**. Г.Кутуйның «Сагыну» нәсерендә автор идеясе.

## 4нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр. Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәр»не җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнгәме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә яки тиктомалга яндыра да башлый. Менә бүген дә гел туңып тора, аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк», – ди ул, үз-үзенә иренеп кенә һәм авылга таба борыла.

Бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән?

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Аның хәзер бер генә эше бар – ул ялан таптарга ярата. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да төгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр.

Карт әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач, дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

– Нихәл, арумы, Миңлебай агай? – диде.

– Каян кайтып киләсең болай? – диде карт.

– Менә кизәк җыярга чыккан идем.

– Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

– Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора, – диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

– Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, – диде карт. – Ярый, кортка, юлыңда бул! Һәм карт озын аякларын сыга биреп китеп барды.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗалы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде.

*Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Казан астында утның өзелмәве яхшы»*. Миңлебай картның бу сүзләре аша укучыга нинди фикер җиткерелә? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Акъәби холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә һәм М.Әмирнең «Агыйдел» повестенда табигать күренешләрен – пейзаж бирелешен чагыштырып карагыз. Алар нинди функция башкарып килә, нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

...Һичкем кыңгырау шалтыратмады, өстемә ябынган чикмәнне һичкем килеп тартмады, фәкать күксел урман белән капланган көчле таулар артыннан көлеп күтәрелгән иртәнге кояш нурларының йомшак кына итеп битемнән сыйпавы җитте – уяндым...

Без йоклаган арба төбендәге кичә генә чабып кайтарылган печән исе дә мине исертә. Хәтта хуш исле чәчәкләр арасына кысылган әрем исе дә кыйммәтле хушбуйлар исеннән тәмлерәк булып тоела. Әллә ничә төрле яшел

белән бизәлеп, иртәнге кояш яктысында күзләрне иркәләрлек булып күренгән урманлы таулар гына түгел, хәтта читән буйларына сырышып үскән алабуталар да, кычытканнар да Шишкин пейзажларыннан матуррак булып күренәләр.

«Әйе, дөнья матур, чиксез матур!..» – шулай дип, үз алдыма кычкырып җибәрә яздым. Күңелле минутны якын иптәшем белән уртаклашасым килде. Ә иптәшем уянмаган әле.

Аның өстендә дә, минеке кебек үк, җиңсез челтәр күлмәк, арзанлы материядән тегелгән кара чалбар. Таза мускуллы ялангач беләкләре ике якка ташланган, тыгыз күкрәк итләре белән ныгытылган авыр гәүдәсе чи печәнгә чумган. Куе яшел печән белән кушылып киткән кара бөдрәләре астыннан ап-ак, шома булып күренгән киң маңгае аны әкиятләрдә сөйләнә торган гүзәлләргә охшата. Тырышып төзәтелгән төсле тигез булып сызылган коңгырт кара кашлар, көлеп чыккан кояш нурлары кебек, түбәнгә табан атылган озын керфекләр, “каш-күз, маңгай тирәсендәге бөтенлеккә зыян китерә күрмәсен” дип, саклык белән генә эшләгән төсле кечкенәрәк авыз-борын аны тагын да матуррак итеп күрсәтәләр. Чынлап та, аның йөзендә нииндидер нур балкый төсле күренә иде ул минутта. Мин аның матурлыгына, җанлылыгына, ягымлылыгына сокланып, шактый вакыт сүзсез генә карап тордым. Мин аны яратам. Техникумда укый башлаганыма менә быел – 1927 елның көзендә – ике ел тула. Шул ике ел эчендә без, аның белән икебез, бер кеше төсле яшәдек. «Ишәй белән Кушай» дип бездән көләләр, берәр җирдә ялгызыбызны гына очратсалар: «Кушаең кайда?» дип сорамыйча булдыра алмыйлар иде. Чыннан да, безне ялгыз очрату кыен булгандыр. Бер-беребездән аерылып, бер генә сәгать тору да безнең өчен ямансу-күңелсез иде шул. Шуңа күрә дә җәйге ял чорында өч ай буенча аерылышып тору беребезнең дә башына сыя алмады. Бергәләшеп, Агыйдел буена – минем туган авылыма кайттык.

Кайткан вакытта, олаучыбызның бездән башка да егерме биш потлап йөге булганга күрә, чемоданнарыбыз гына утырып кайттылар. Үзебезгә йөз километрдан артыкка сузылган юлның күбрәк өлешен җәяүләп үтәргә туры килде. Ямьле җәйге юл буенча җәяүләү җиңелчә киенгән яшьләр өчен авыр булмаса да, авылга кайтып җитү белән, буыннарыбызда арыганлык сизелде. Агыйдел буенда утырган авылның матурлыгы, авыл өстенә ишелә язып күтәрелгән күксел түбәле тауларның мәһабәтлеге белән дә кызыксынмадык, фәкать каймаклы чәй эчү белән генә канәгатьләнеп, кояш батар-батмастан йокларга яттык.

*М.Әмир «Агыйдел»*

**Вариант 2**

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,-
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңлениләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән:
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»

*Г.Тукай «Милли моңнар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Әлеге шигыре белән Г.Тукай нинди фикерләр җиткерә дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик төргә хас нинди үзенчәлекләрне билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Г.Тукайның «Милли моңнар» һәм Х.Туфанның «Туган тел турында җыр» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,

Кукрәүләр теле бүген.

И безнең батыр телебез,
И безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

*Х.Туфан «Туган тел турында җыр»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Г.Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.

**2.2.** Г.Тукай иҗатында лирик герой образы.

**2.3**. И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә мәхәббәт темасы.

**2.4**. Ф.Кәрим лирикасында сугыш темасы.

## 5нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Мин читеккә карадым, караган саен ул миңа дошман төсле күренә килде. Мәхәббәтсез читек...

– Эч, угылым, чәеңне. Иртәгә менә мулла абыең үзеңә чалма чалып бирер. Чапаныңны киярсең. Читегеңне әллә, угылым, гаеткә киеп барырга мулла абыеңа бирәмсең? Аның, мескеннең, гаеткә читеге дә иске...

Мин күземне күтәреп карадым, читек тә кызганыч, мулла абый да кызганыч. Бәхетсез читек, нәни түгел читек! Бу кәҗүл дә түгелдер әле... Түгел!

Мин читекләрне мулла абыйга суздым.

Әти, әни һәм әби һәммәсе:

– Менә рәхмәт, менә рәхмәт, мулла абыең менә сиңа чалма чалып бирер. Киләсе гаеткә кәҗә Вәлинең килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер. Казанның үзеннән: «Ошбу читек тапшырылса иде Габдулла авылында Әхмәдулла мәхдүмгә», дип, атыңа язылып килер. Килер шул!

Мин ураза бәйрәмендә өр-яңа кәҗүл читек киеп гаеткә барырмын.

«Әти! Ураза гаете еракмы?» – дияргә башымны күтәрдем. Мулла абый, әти, әни бер-берсенә карашып елмаешып торалар.

Миңа, бердән, минем хәзер дә читегем юк, ураза гаетендә дә читегем булмас, аннары да булмас кебек тоелды. Тамагымны әллә нәрсә кытыклады, борынга әллә ни тулды, күзне әллә нәрсә юешләтте. Биттән кайнарланып әллә нәрсә агып төште...

«Минем читегем юк, минем кәҗүл читегем юк», – дип, әллә кем минем эчемдә сыкранып кычкырына башлады.

Мин тавышланып еларга тотындым. Саплы калачны алмадым. Чәйне эчмәдем. Акырып барып мендәргә яттым; мине әти дә яратмый, миннән мулла абый да көлә; мине әни дә, әби дә сөйми... Читегем юк... Рәбиганың читеге бар, минем читегем юк.

Мулла абый:

– Мин сине зур булды, мәдрәсәгә алып барырмын дип тора идем. Син анда да шулай елап йөдәтсәң, алмыйм инде, – диде.

Әби:

– Мин сиңа үзем кәҗүл читек тегәм, үзем тегәм. Менә күр дә тор, үзем тегәм. Иртәгә чапаныңны киярсең. Читегеңне киярсең. Мәхдүм булып гаеткә барырсың.

Минем күз алдыма нәни генә читек, кәҗүл читек килеп басты. Ул минеке. Кил, кил, кәҗүл читек. Иртәгә гает, кәҗүл читек, иртәгә гает!

*Г.Исхакый «Кәҗүл читек»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Хикәя сюжетында язучы нинди проблемалар күтәрә?

**1.1.2.** Әлеге өзектә бала (Әхмәдулла) холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек» һәм Г.Ибраһимовның «Яз башы» хикәяләрендә төп геройларның күңел халәтен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

– Ни дисең, әни, ярыймы? – дигән бер караш белән аның күзләренә текәлдем. Җавап көтәм. Ул берничә кат салмак кына күз йөртеп чыкты да, миңа ишеттерерлек итеп «биш, биш ярым» дип укып китте.

Эчемнән бер нәрсә, бер көчле ялкын кайнап бугазыма, битемә таба килә. Әни моны белде ахры. Арык, талган кулларының, аркамнан сөеп, җылы вә мәхәббәтле кочакка алганын, нәкъ йөрәгенең өстенә кысылганымны әле дә бик ачык хәтерлим. Тавышы чыгышы вә һәрбер хәрефе эчке бер теләк, мәхәббәт вә изге уй белән тулган: «Рәхмәт, балам, рәхмәт, күз нурым, бәгырем... тырышкансың», – дигән сүзләр әле дә колагымда тора кеби тоям. Шул сүзләрдән соң әнинең күземнән, маңгаемнан үбүен кабергә кергәнче онытa алмаслык бер тойгы белән каршы алганлыгымны хәзер дә исемдә саклыйм.

Шуннан соң арада рәхәт вә тәмле бер тынлык алды.

Артык сүз, артык рәхмәт ишетмәдем. Ләкин өмет вә мәхәббәт белән тулган ул өлкән, матур вә тирән мәгънәле күзләрдә төшәргә калтырашып торган эре бөртекле яшьләр ялтырый, алар ничаклы ишерелергә теләнсә дә, иреклеирексез керфек очына килеп, берәм-берәм саргылт йөздән тәгәриләр иде.

Боларның нидән вә ни өчен килгәнен мием белмәсә дә, эчем сизә иде. Йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан гбу яшьләргә эремәскә көчем

җитмәде; белмим, нидәндер күңелем йомшарды. Күзләрем яшәреп, яңак буйларым чылана башлады.

Һәр нәрсәм, һәр теләгем камил, артык һич... һичбер нәрсә кирәк түгел иде. Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, өрмәгән җиргә утыртмый – шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем. Ул арада чәй хәзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып йөргән сыйлар берәм-берәм өстәлгә тезелделәр.

Озак һәм тәмле эчтек. Әни искиткеч ваклык белән минем мәктәптәге тормышны сораша башлады. Минем укуым, иптәшләрем, имтиханнарым, хәлфәнең минем ха-кымда әйткән сүзләре инәсеннән җебенәчә сөйләшелде, кат-кат кичелде.

*Г.Ибраһимов «Яз башы»*

## Вариант 2

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

*Г.Тукай «Туган тел»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** «*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы*» юллары белән Г.Тукай нәрсә әйтергә тели дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә үз фикерен җиткерү өчен Г.Тукай нинди образлардан файдалана?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Г.Тукайның «Туган тел» һәм Х.Туфанның «Туган тел турында җыр» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

И телем, сансыз гасырны
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И безнең батыр телебез,
И безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

*Х.Туфан «Туган тел турында җыр»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** М.Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәлендә автор идеясе.

**2.2.** Г.Камалның «Беренче театр» комедиясендә драматург күтәргән проблемалар.

**2.3**. М.Җәлил иҗатында лирик герой һәм аңа хас үзенчәлекләр.

**2.4**. Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясендә мәхәббәт темасы.

## 6нчы ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Миңа, күп куйганда, җиде-сигез яшь булгандыр, әллә нинди коточкыч кара йөзле, усал елтыр күзле бер башкорт һич көтелмәгән җирдән үзенең кара бурлы, матур, зур симез биясен безгә бүләк итте, – алай-болай гына түгел, үз кулы белән йортыбызга китерә, капка төбендәге зур ташка утыра да кешеләр алдында дога кылдырып бирә.

Авыл халкы бу эшкә башта аптырап калалар: ни сәбәптән бу тирә-якка усаллыгы, саранлыгы белән даны чыккан явыз көрәшче Әлемгол тик торганда, үзенең гомерлек дошманы Хафизга (безнең әткәйгә) бер бия китереп, фатыйха кылдыра?!

Эштән чыккан бер мал булса, тагы бер хәл иде! Биясе нәрсә бит: бөтен тирә-якта дан тоткан ике алмачуар чабышкының анасы! Җитмәсә тагы карынында бер колын бар!!!

Мондый бер хәл һичкемнең башына сыя алмый. Безнең күрше карчык Фатыйха әби башкорт баһадирының үз күзе алдында ук:

– Балалар, бу эш хәерлегә булмас!! Моның астында берәр хәйлә бардыр, – ди.

Безнең кардәш Сафа карт та, ак сакалын сыйпап, бу сүзне куәтләп куя:

– Китапча итеп әйтсәң инде, – ди, – мин әйтәм, ди, таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, ди, Әбүҗәһел иманга килер. Әмма, ди, Әлемгол бай, ди, бу данлыклы бияне карынындагы колыны белән тиктән-тик Хафизга китереп бирмәс, монда берәр этлек юкмы икән, балалар, – ди.

Башкорт боларның һәммәсен тыныч кына тыңлап тора да, бераз елмаеп, кара күзләрен тагы ныграк елтыратып, үзенең хәлен сөйләп бирә.

Ул сөйләгәч, халыкның аптыравы шатлыкка, хәер- догага әйләнә.

*Г.Ибраһимов «Алмачуар»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: *«Мондый бер хәл һичкемнең башына сыя алмый. Безнең күрше карчык Фатыйха әби башкорт баһадирының үз күзе алдында ук:*

*– Балалар, бу эш хәерлегә булмас!! Моның астында берәр хәйлә бардыр, – ди».* Фатыйха әби күңелендәге мондый шикләнү, икеләнү хисе нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә хикәяләүче нинди хис-кичерешләр кичерә?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрендә хикәяләүче һәм Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек» хикәясендә малайның (Әхмәдулла) кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

... Ни күзем белән күрим! Минем читегемнең битлеге бөтенләй кып-кызыл, Балтырының кайбер җирендә кап-кара нәрсә ялтырап торса да, кай җирләрендә кызылланып киткән, ул ала-кола.

Рөкүгъда малайлар «сөбханә Раббел-газыйм» урынына: «Әнисе читеген кигән, әнисе читеген кигән», – диләр.

Түгел, ул болай гына кызарган. Минем чапаным да бар. Чапаным ямь-яшел.

Менә тагы тордык. Малайлар пырых-пырых көләләр:

– Әхмәдулланың чапанына корым ягылган! Кап-кара корым...

– Әнисенең читеген кигән. Әтисенең чапанын корымлаткан...

Тагы рөкүгъга бардык.

Ни күзем белән күрим: чапанымның алгы чабулары дегеткә буяган кебек кап-кара булган.

Әттәхияттә малайлар:

– Әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән, катымша, катымша, – дип укыдылар.

Әти сәлам бирде.

Аллаһе әкбәр! Бөтен халык сикереп торды. Мине малайлар чормап алдылар.

Һәммәсе авызын җәйгән, һәммәсе көлә: «Әнисенең кызыл читеген кигән».

Мин һаваланып кына:

– Таз шайтан, айбагар карагы!.. – дип киттем. Барып башмакларны кидем.

*Г.Исхакый «Кәҗүл читек»*

**Вариант 2**

И, телем, сансыз гасырны,
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И, безнең батыр телебез,
И, безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

Тарихым истәлеге син,
Болгарым истәлеге,
Гасырлар аша үтелгән
Юлларым истәлеге.

Чишмәләр исән чагында
Иделләр кибәмени?
Гасырлар күммәде сине,
Дәверләр күмәмени?

Иңгә-иң безнең теләкләр,
Кулга-кул уйларыбыз,
Якты язмышларга таба
Барасы юлларыбыз.

Син - минем тере тарихым,
Син - минем киләчәгем,
Тик синдә газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем.

И, телем, синдә нәфислек
Чишмәсе кибәрмени?
Гасырлар сиңа тимәде
Дәверләр тиярмени?

*Х.Туфан «Туган тел турында җырлар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** «*И, телем, синдә нәфислек - / Чишмәсе кибәрмени?...*» юлларында автор нинди фикер җиткерә дип уйлыйсыз? Нәфислек чишмәсе образына ул нинди мәгънә сала?

**1.2.2.** Шигырьдә нинди тел-сурәтләү чараларын билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Х.Туфанның «Туган тел турында җырлар» һәм Г.Тукайның «Милли моңнар» шигырьләрендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән:
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»

*Г.Тукай «Милли моңнар»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.
**2.2.** Һ.Такташның «Мокамай» шигырендә дуслык темасы.
**2.3**. Г.Исхакыйның «Җан Баевич» комедиясендә төп конфликт.
**2.4**. М.Гафуриның «Сарыкны кем ашаган?» мәсәлендә тәрбия мәсьәләсе.

## 7нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Мин читеккә карадым, караган саен ул миңа дошман төсле күренә килде. Мәхәббәтсез читек, дәүкәди читек...

– Эч, угылым, чәеңне. Иртәгә менә мулла абыең үзеңә чалма чалып бирер. Чапаныңны киярсең. Читегеңне әллә, угылым, гаеткә киеп барырга мулла абыеңа бирәмсең? Аның, мескеннең, гаеткә читеге дә иске...

Мин күземне күтәреп карадым, читек тә кызганыч, мулла абый да кызганыч. Бәхетсез читек, нәни түгел читек! Бу кәҗүл дә түгелдер әле... Түгел!

Мин читекләрне мулла абыйга суздым.

Әти, әни һәм әби һәммәсе:

– Менә рәхмәт, менә рәхмәт, мулла абыең менә сиңа чалма чалып бирер. Киләсе гаеткә кәҗә Вәлинең килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер. Казанның үзеннән: «Ошбу читек тапшырылса иде Габдулла авылында Әхмәдулла мәхдүмгә», дип, атыңа язылып килер. Килер шул!

Мин ураза бәйрәмендә өр-яңа кәҗүл читек киеп гаеткә барырмын.

«Әти! Ураза гаете еракмы?» – дияргә башымны күтәрдем. Мулла абый, әти, әни бер-берсенә карашып елмаешып торалар.

Миңа, бердән, минем хәзер дә читегем юк, ураза гаетендә дә читегем булмас, аннары да булмас кебек тоелды. Тамагымны әллә нәрсә кытыклады, борынга әллә ни тулды, күзне әллә нәрсә юешләтте. Биттән кайнарланып әллә нәрсә агып төште...

«Минем читегем юк, минем кәҗүл читегем юк», – дип, әллә кем минем эчемдә сыкранып кычкырына башлады.

Мин тавышланып еларга тотындым. Саплы калачны алмадым. Чәйне эчмәдем. Акырып барып мендәргә яттым; мине әти дә яратмый, миннән мулла абый да көлә; мине әни дә, әби дә сөйми... Читегем юк... Рәбиганың читеге бар, минем читегем юк.

Мулла абый:

– Мин сине зур булды, мәдрәсәгә алып барырмын дип тора идем. Син анда да шулай елап йөдәтсәң, алмыйм инде, – диде.

Әби:

– Мин сиңа үзем кәҗүл читек тегәм, үзем тегәм. Менә күр дә тор, үзем тегәм. Иртәгә чапаныңны киярсең. Читегеңне киярсең. Мәхдүм булып гаеткә барырсың.

Минем күз алдыма нәни генә читек, кәҗүл читек килеп басты. Ул минеке. Кил, кил, кәҗүл читек. Иртәгә гает, кәҗүл читек, иртәгә гает!

*Г.Исхакый* «*Кәҗүл читек*»

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: «*Мин күземне күтәреп карадым, читек тә кызганыч, мулла абый да кызганыч. Бәхетсез читек, нәни түгел читек! Бу кәҗүл дә түгелдер әле... Түгел!*

*Мин читекләрне мулла абыйга суздым.*

*Әти, әни һәм әби һәммәсе:*

*— Менә рәхмәт, менә рәхмәт, мулла абыең менә сиңа чалма чалып бирер. Киләсе гаеткә кәҗә Вәлинең килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер.*» Малай күңелендәге мондый халәт нәрсәгә бәйле дип уйлыйсыз? Әсәр сюжетына бәйләп җавап бирегез.

**1.1.2.** Әлеге өзектә Әхмәдулла холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек» хикәясендә төп герой һәм Г.Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендәге төп геройның холыкларын чагыштырып карагыз. Аларның күңелендәге хисләрдә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

– Ни дисең, әни, ярыймы? – дигән бер караш белән аның күзләренә тегәлдем. Җавап көтәм. Ул берничә кат салмак кына күз йөртеп чыкты да, миңа ишеттерерлек итеп «биш, биш ярым» дип укып китте. Эчемнән бер нәрсә, бер көчле ялкын кайнап бугазыма, битемә таба килә. Әни моны белде ахры. Арык, талган кулларының, аркамнан сөеп, җылы вә мәхәббәтле кочакка алганын, нәкъ йөрәгенең өстенә кысылганымны әле дә бик ачык хәтерлим. Тавышы чыгышы вә һәрбер хәрефе эчке бер теләк, мәхәббәт вә изге уй белән тулган: «Рәхмәт, балам, рәхмәт, күз нурым, бәгырем... тырышкансың», – дигән сүзләр әле дә колагымда тора кеби тоям. Шул

сүзләрдән соң әнинең күземнән, маңгаемнан үбүен кабергә кергәнче онытa алмаслык бер тойгы белән каршы алганлыгымны хәзер дә исемдә саклыйм.

Шуннан соң арада рәхәт вә тәмле бер тынлык алды. Артык сүз, артык рәхмәт ишетмәдем. Ләкин өмет вә мәхәббәт белән тулган ул өлкән, матур вә тирән мәгънәле күзләрдә төшәргә калтырашып торган эре бөртекле яшьләр ялтырый, алар ничаклы ишерелергә теләнсә дә, иреклеирексез керфек очына килеп, берәм-берәм саргылт йөздән тәгәриләр иде. Боларның нидән вә ни өчен килгәнен мием белмәсә дә, эчем сизә иде. Йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан гбу яшьләргә эремәскә көчем җитмәде; белмим, нидәндер күңелем йомшарды. Күзләрем яшәреп, яңак буйларым чылана башлады.

Һәр нәрсәм, һәр теләгем камил, артык һич... һичбер нәрсә кирәк түгел иде. Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, өрмәгән җиргә утыртмый - шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем. Ул арада чәй хәзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып йөргән сыйлар берәм-берәм өстәлгә тезелделәр.

Озак һәм тәмле эчтек. Әни исkиткеч ваклык белән минем мәктәптәге тормышны сораша башлады. Минем укуым, иптәшләрем, имтиханнарым, хәлфәнең минем ха-кымда әйткән сүзләре инәсеннән җебенәчә сөйләшелде, кат-кат кичелде.

*Г.Ибраһимов «Яз башы»*

**Вариант 2**

И, телем, сансыз гасырны,
Исән-сау кичкән телем!
Сыкраулар теле түгел син,
Күкрәүләр теле бүген.

И, безнең батыр телебез,
И, безнең гәүһәр мирас!
Күпләрне күргән башыңны
Инде син күтәр бераз.

Тарихым истәлеге син,
Болгарым истәлеге,
Гасырлар аша үтелгән
Юлларым истәлеге.

Чишмәләр исән чагында
Иделләр кибәмени?
Гасырлар күммәде сине,
Дәверләр күмәмени?

Иңгә-иң безнең теләкләр,
Кулга-кул уйларыбыз,
Якты язмышларга таба
Барасы юлларыбыз.

Син – минем тере тарихым,
Син – минем киләчәгем,
Тик синдә газиз туган тел,
Бәхеткә җитәчәгем.

И, телем, синдә нәфислек
Чишмәсе кибәрмени?
Гасырлар сиңа тимәде
Дәверләр тиярмени?

*Х.Туфан «Туган тел турында җырлар»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен баштa җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** *«Гасырлар күммәде сине, / Дәверләр күмәмени?»* юлларында автор нинди фикер җиткерә дип уйлыйсыз?

**1.2.2.** Шигырьдә нинди тропларны билгели аласыз?

**1.2.3 биремен башкару өчен баштa җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Х.Туфанның «Туган тел турында җырлар» һәм Г.Тукайның «Туган тел» шигырьләрендә лирик геройның туган телгә мөнәсәбәтен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең белән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:

Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!

*Г.Тукай «Туган тел»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Ә.Еникиның «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә күтәрелгән проблемалар.
**2.2.** Ш.Камалның «Буранда» хикәясендә автор идеясе.
**2.3**. Ф.Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда автор идеясе.
**2.4**. М.Әмирнең «Агыйдел» повестенда төп образлар.

## 8нче ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Хәят Михаилның үзенә нәрсәдер, бик кирәкле бер нәрсә әйтергә теләп тә, әйтеп бетерә алмаганлыгын томанлы гына сизенә, ләкин, никтер, ул кирәкле нәрсәнең әйтеп бетерелми калганлыгын теләгән шикелле була иде. Кулындагы чәчәкләр бәйләмен борыны янынарак китерде дә, шул чәчәкләргә әйткән шикелле итеп, ул:

– Ишетегез әле, сез әүвәлләрдә бик матур җырлыйдыр идегез. Җырлагыз әле берәр нәрсә, – диде.

Михаил чәчәкләргә карап әйтелгән бу сүзнең үзенә әйтелә икәнен белә иде, назланып тормады: уң кулын чалбар кесәсенә тыкты, йомшак кына тамак кырды да зәгыйфь, ләкин сөйкемле тенор белән:

*В темной аллее заглохшего сада*
*Сидя вдвоем на дерновой скамье, –*

дип башлады да, үз-үзеннән көлеп җибәреп, җырын кисте һәм:

– Юк, Хаят, мондый тавыш белән җырлаганны тыңлап утырганчы, әнә ул агачта сайрый торган кошчык сайравын тыңлагыз. Ул сезнең өчен һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый, – диде.

Чынлап та, ниндидер бер кошчык, башкаларыннан аерым бер осталык вә аерым бер дәрт белән, болар утырган скамья каршысындагы агачның яфраклары арасына яшеренеп сайрана иде. Соңгы сүзләрне әйткәндә Михаилның тавышы бик чынлыклы вә бераз каушанкырак чыга иде. Хәятның йөрәге тыпырчынган шикелле итеп тибә башлады: Михаилга әйтергә аның теленә җавап килми иде. Бер минутлык тик торыштан соң Михаил, уң кулы белән Хәятның сул кулыннан йомшак кына тотып, уйчан гына тавыш белән:

– Ачуланмагыз, Хаят, мин сезне сөям... Минем күңелемдә сез генә... – ди башлаган иде, Хәятның кулының үз кулыннан ычкынган икәнен сизде.

Хәят болай итеп әйтелгән «сөям» дигән сүзне әүвәл мәртәбә ишетә иде. Ул әле күптән түгел генә укып чыккан русча бер романда сөю, сөелү дигән сүзләрне күргән вә хәтта үзен шул романда язылган кызларның берсе итеп уйлап укыган булса да, һәм мондый эшләрне үзеннән зуррак иптәш марҗа кызларыннан әллә ничә мәртәбәләр ишеткән булса да, хәзер аптыраште калган: кирәк укыган романындагы кызның вә кирәк үзенең иптәш кызларының үзләрен мондый вакытларда ничек тотканлыкларын хәтереннән чыгарган иде. Михаилның «сөям» дигән сүзен ишеткәч тә, ул ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

– Сез бик мәхәббәтле!.. – диде дә, йөзен куллары белән каплап, олы юлга таба йөгерде.

Михаил да аның артыннан китте. Аның колагындагы Хәятның сүзе шатлыклы яңгырый иде:

– Сез бик мәхәбббәтле!

Хәят үзенең кызарганлыгын белә, колакларының ялкынсыз янганлыгын да сизә; һәм хәзер генә булып узган эш аның алдында томан эченнән карап, шатлыклы елмаеп торган шикелле була да, йөздәге кызыллык, колаклардагы яну тагы да көчәя иде.

Яңадан бер минут – Хәят күңелендә куркугарак охшый торган бер китеклек сизде: кинәт бу бик күңелле һәм бераз оялткычрак эшнең бер чите җимерелеп төште. Кай җире җитешми? Кай җире китек? Анысын Хәят әле белеп җиткерми иде. Ләкин сизгер яшь йөрәк бу китеклекне тойды. Бары акыл гына әле аның кай җирдә икәнен анык билгеләп өлгерә алмады.

*Ф. Әмирхан «Хәят»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Тәкъдим ителгән өзектә мондый юллар бар: «*Яңадан бер минут – Хәят күңелендә куркугарак охшый торган бер китеклек сизде: кинәт бу бик күңелле һәм бераз оялткычрак эшнең бер чите җимерелеп төште. Кай җире җитешми? Кай җире китек?*». Ни өчен Хәят күңелендә мондый хис туа? Әлеге өзектә аның холкындагы нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.2.** Әсәрнең идеясен ачуда Михаил образының роле нинди? Аның функциясен ачыклап языгыз.

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда Хәятнең һәм Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясендә Таһирәнең кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның яраткан кешеләренә мөнәсәбәтендә нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

...Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

... Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йә, Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы куркынып, аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды...

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи халәтендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына – Таһирәнең кул сузымы гына җирдән җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да, барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, Туган ил җыры... Аһ, моңардан да кадерле һәм ләззәтле нәрсә булырга мөмкинме?!

*Ә.Еники «Кем җырлады?»*

## Вариант 2

Тирән окопта каршылыйм
Икенче язны;
Язгы таңда безнең якка
Кайта кыр казы.

Кайта диңгез артындагы
Ерак илләрдән,
Һәм яши ул төнбоеклы
Тонык күлләрдә.

Әй, кыр казы, түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында
Ут эченнән языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Дәһшәтле сугыш кырында

Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп йөртәм
Йөрәк ялкынын.

Халкыма бәхет, дан даулап
Үтә көннәрем;
Анабыз-җирне кочаклап,
Бәлки, үләрмен.

Үлсәм, җырларымда калыр
Сөю, сагышлар;
Кыр казы йөзгән күлләрдә
Шаулар камышлар..

*Ф.Кәрим «Кыр казы»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** «*Каләм ясап каурыеңнан, / Язгы ялкында / Ут эченнән языйм бер җыр / Сөйгән халкыма*» юлларында Ф.Кәрим «кыр казы каурые белән ут эченнән язылган җыр» образы аркылы нәрсә әйтергә тели? Аңа нинди мәгънәләр сала?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик геройның хис-кичерешен, аның нинди вакыйгаларга бәйле үсү-үзгәрүен аңлатыгыз.

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Ф.Кәримнең «Кыр казы» һәм Х.Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы? » шигырендә лирик геройның кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы? –
Бәйлисе бар
Йөрәкне.

Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада.
– Кайт!. – дип хатлар килделәр...
Юллар озын иделәр...
Кайттым.
– Бусы – алкалары,
Бусы – кабере... – диделәр.
Әгәр тагын килсәләр,
Сау! – дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.
Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы? –
Бәйлисе бар йөрәкне...

*Х.Туфан «Кайсыгызның кулы җылы?»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** М.Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда сугыш темасы.

**2.2.** Ф.Кәрим иҗатында күтәрелгән проблемалар.

**2.3**. Г.Камалның «Беренче театр» комедиясендә Хәмзә бай образы.

**2.4**. М.Җәлил иҗатында яшәү һәм үлем турында уйланулар.

## 9нчы ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук алъяпкыч буган оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самовар артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та, минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга тора кебек иде. Әйтерсең, бу һич йомылмас моңсу күз аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән? Без гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек, Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да бик тирән яшерә беләме?...

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне каpладык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

– Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле, – диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык...

– Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар, – диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

– Кайдан бу синдә?

– Үзем мәтәштергән булдым инде, – диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тонык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чиртеләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

– Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең? – дидек без. – Мәдрәсәдә Сәгыйт скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

– Оста барда кулың тый! – диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шулчак мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы, – гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караштa, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем...

Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез, нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң – мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә, – моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

*Ә.Еники «Матурлык»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Хикәяләүче матурлык төшенчәсен ничек аңлый? Әсәр дәвамында аның фикере үзгәрәме?

**1.1.2.** Әсәрдән өзектә Бәдретдиннәр гаиләсендәге нинди сыйфатлар ачыла?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр**

**текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Ә.Еникинең «Матурлык» һәм Г.Ибраһимовның «Яз башы» хикәяләрендә Ана образларын чагыштырып карагыз. Алар арасында нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

– Ни дисең, әни, ярыймы? – дигән бер караш белән аның күзләренә тегәлдем. Җавап көтәм. Ул берничә кат салмак кына күз йөртеп чыкты да, миңа ишеттерерлек итеп «биш, биш ярым» дип укып китте.

Эчемнән бер нәрсә, бер көчле ялкын кайнап бугазыма, битемә таба килә. Әни моны белде ахры. Арык, талган кулларының, аркамнан сөеп, җылы вә мәхәббәтле кочакка алганын, нәкъ йөрәгенең өстенә кысылганымны әле дә бик ачык хәтерлим. Тавышы чыгышы вә һәрбер хәрефе эчке бер теләк, мәхәббәт вә изге уй белән тулган: «Рәхмәт, балам, рәхмәт, күз нурым, бәгырем... тырышкансың», – дигән сүзләр әле дә колагымда тора кеби тоям. Шул сүзләрдән соң әнинең күземнән, маңгаемнан үбүен кабергә кергәнче онытa алмаслык бер тойгы белән каршы алганлыгымны хәзер дә исемдә саклыйм.

Шуннан соң арада рәхәт вә тәмле бер тынлык алды.

Артык сүз, артык рәхмәт ишетмәдем. Ләкин өмет вә мәхәббәт белән тулган ул өлкән, матур вә тирән мәгънәле күзләрдә төшәргә калтырашып торган эре бөртекле яшьләр ялтырый, алар ничаклы ишерелергә теләнсә дә, ирекле-ирексез керфек очына килеп, берәм-берәм саргылт йөздән тәгәриләр иде.

Боларның нидән вә ни өчен килгәнен мием белмәсә дә, эчем сизә иде. Йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан гбу яшьләргә эремәскә көчем җитмәде; белмим, нидәндер күңелем йомшарды. Күзләрем яшәреп, яңак буйларым чылана башлады.

Һәр нәрсәм, һәр теләгем камил, артык һич... һичбер нәрсә кирәк түгел иде. Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, өрмәгән җиргә утыртмый – шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем. Ул арада чәй хәзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып йөргән сыйлар берәм-берәм өстәлгә тезелделәр.

Озак һәм тәмле эчтек. Әни искиткеч ваклык белән минем мәктәптәге тормышны сораша башлады. Минем укуым, иптәшләрем, имтиханнарым, хәлфәнең минем ха-кымда әйткән сүзләре инәсеннән җебенәчә сөйләшелде, кат-кат кичелде.

*Г.Ибраһимов «Яз башы»*

## Вариант 2

Ул,
Эретеп туңган тәрәзәне,
Моштым гына карый урамга, –
Ак чәчәкләр ява урамда...

Бераү,
Борын очын кулына кысып,
Сүгенеп узды кышкы салкыннан, –
Җил ияреп китте артыннан...

Алар,
Чана тартып җырлый-җырлый,
Тау шуарга икәү уздылар, –
Ә бераздан кире сыздылар...

* * *

Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...
Яз янгыны җирдә кабынганчы,
Кар астында йоклар урамнар,
Төне матур булса, төн үтүгә,
Таңнар алып килер бураннар...
Дөнья матур,
Шуның өчен дә бит,
Сүгнә-сүгнә кайтам салкыннан;
Ә җил моштым гына, эндәшмичә,
Ияреп килә минем артымнан...
Белмим, нигә, әллә гыйшкы төшкән,
Кайда барсам – шунда бара ул;
Өйгә кергәндә, җиргә ятып,
Чыкканымны саклап кала ул...
Шуның өчен дә мин чыкмый гына
Тәрәзәдән карыйм урамга –
Ак чәчәкләр ява урамда...
Ак чәчәкләр ява, дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...

*Һ.Такташ «Ак чәчәкләр»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** Һ.Такташ җил образы аркылы нәрсә әйтергә тели? Аңа нинди мәгънәләр сала?

**1.2.2.** Шигырьдә лирик геройның хис-кичерешен, аның нинди вакыйгаларга бәйле үсү-үзгәрүен аңлатыгыз.

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** Һ.Такташның «Ак чәчәкләр» ак чәчәкләр һәм М.Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигырендә кызыл ромашка образлары аша җиткерелгән фикерләрне чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.

Назлады җил аларны,
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.

Чәчкәләр, кәефләнеп,
Җай гына селкенделәр.
Һәм кинәт шунда гаҗәп
Бер яңа хәл күрделәр.

Ерак түгел моңаеп,
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

Ромашкалар бар да ак,
Аерылмый бер-береннән;
Ничек болай бер үзе
Ул кызылдан киенгән?

Әйттеләр: «Син, сеңелкәй,
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нидән кызыл чукларың?

Нидән алсу төсләрең?»

Әйтте кызыл ромашка:
– «Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.

Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.

Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик охшады Чулпанга.

Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә аны сагынып,
Балкыйм мин таң нурында».

*М.Җәлил «Кызыл ромашка»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** М.Җәлил иҗатында сугыш темасы.

**2.2.** Г.Кутуйның «Сагыну» нәсерендә күтәрелгән проблемалар.

**2.3**. Г.Камалның «Беренче театр» комедиясендә автор идеясе.

**2.4**. И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә автор идеясе һәм аның бирелеше.

## 10нчы ВАРИАНТ

## 1 БҮЛЕК

**1 бүлектәге ике вариантта тәкъдим ителгән өзекләрне укыгыз һәм шул вариантларның берсендә каралган биремнәргә генә җаваплар языгыз.**

### Вариант 1

**Тәкъдим ителгән өзекне укыгыз һәм 1.1.1 – 1.1.3 биремнәренә җавап бирегез.**

– Ни дисең, әни, ярыймы? – дигән бер караш белән анын күзләренә тегәлдем. Җавап көтәм. Ул берничә кат салмак кына күз йөртеп чыкты да, миңа ишеттерерлек итеп «биш, биш ярым» дип укып китте.

Эчемнән бер нәрсә, бер көчле ялкын кайнап бугазыма, битемә таба килә. Әни моны белде ахры. Арык, талган кулларының, аркамнан сөеп, җылы вә мәхәббәтле кочакка алганын, нәкъ йөрәгенең өстенә кысылганымны әле дә бик ачык хәтерлим. Тавышы чыгышы вә һәрбер хәрефе эчке бер теләк, мәхәббәт вә изге уй белән тулган: «Рәхмәт, балам, рәхмәт, күз нурым, бәгырем... тырышкансың», – дигән сүзләр әле дә колагымда тора кеби тоям. Шул сүзләрдән соң әнинең күземнән, маңгаемнан үбүен кабергә кергәнче оныта алмаслык бер тойгы белән каршы алганлыгымны хәзер дә исемдә саклыйм.

Шуннан соң арада рәхәт вә тәмле бер тынлык алды.

Артык сүз, артык рәхмәт ишетмәдем. Ләкин өмет вә мәхәббәт белән тулган ул өлкән, матур вә тирән мәгънәле күзләрдә төшәргә калтырашып торган эре бөртекле яшьләр ялтырый, алар ничаклы ишерелергә теләнсә дә, иреклеирексез керфек очына килеп, берәм-берәм саргылт йөздән тәгәриләр иде.

Боларның нидән вә ни өчен килгәнен мием белмәсә дә, эчем сизә иде. Йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан гбу яшьләргә эремәскә көчем җитмәде; белмим, нидәндер күңелем йомшарды. Күзләрем яшәреп, яңак буйларым чылана башлады.

Һәр нәрсәм, һәр теләгем камил, артык һич... һичбер нәрсә кирәк түгел иде. Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, өрмәгән җиргә утыртмый – шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем. Ул арада чәй хәзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып йөргән сыйлар берәм-берәм өстәлгә тезелделәр.

Озак һәм тәмле эчтек. Әни искиткеч ваклык белән минем мәктәптәге тормышны сораша башлады. Минем укуым, иптәшләрем, имтиханнарым, хәлфәнең минем ха-кымда әйткән сүзләре инәсеннән җебенәчә сөйләшелде, кат-кат кичелде.

*Г.Ибраһимов «Яз башы»*

**1.1.1 һәм 1.1.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.1.** Г.Ибраһимов ни өчен әсәрен «Яз башы» дип атый? Әсәрнең исеме белән сюжеты арасында нинди бәйләнеш бар дип уйлыйсыз?

**1.1.2.** Әсәрдән өзектә Ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләгәндә язучы нинди алымнан файдалана?

**1.1.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.1.3.** Г.Ибраһимовның «Яз башы» һәм Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәяләрендә Ана образларын чагыштырып карагыз. Аларның кичерешләре арасында нинди охшаш һәм аермалы яклар бар?

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр. Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәр»не җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнгәме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә яки тиктомалга яндыра да башлый. Менә бүген дә гел туңып тора, аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк», – ди ул, үз-үзенә иренеп кенә һәм авылга таба борыла.

Бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән?

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Аның хәзер бер генә эше бар – ул ялан таптарга ярата. Бу күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да төгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр.

Карт әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач, дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап аңа:

– Нихәл, арумы, Миңлебай агай? – диде.

– Каян кайтып киләсең болай? – диде карт.

– Менә кизәк җыярга чыккан идем.

– Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

– Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора, – диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

– Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, – диде карт. – Ярый, кортка, юлыңда бул! Һәм карт озын аякларын сыга биреп китеп барды.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗалы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде.

*Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»*

**Вариант 2**

Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.

Назлады җил аларны,
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.

Чәчкәләр, кәефләнеп,
Җай гына селкенделәр.
Һәм кинәт шунда гаҗәп
Бер яңа хәл күрделәр.

Ерак түгел моңаеп,
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

Ромашкалар бар да ак,

Аерылмый бер-береннән;
Ничек болай бер үзе
Ул кызылдан киенгән?

Әйттеләр: «Син, сеңелкәй,
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нидән кызыл чукларың?
Нидән алсу төсләрең?»

Әйтте кызыл ромашка:
– «Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.

Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.

Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик охшады Чулпанга.

Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә аны сагынып,
Балкыйм мин таң нурында».

*М.Җәлил «Кызыл ромашка»*

**1.2.1 һәм 1.2.2 биремнәрен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 3-5 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.1.** М.Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигырендә автор идеясен аңлатып языгыз.

**1.2.2.** Шагыйрь нинди тел-сурәтләү чараларыннан файдалана?

**1.2.3 биремен башкару өчен башта җаваплар бланкына биремнең номерын язып куегыз, аннан соң һәр биремгә таләп ителгән күләмдә тулы җавап языгыз (якынча 5-8 җөмлә). Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез. Ике әсәрне чагыштырып, җавапларыгызны аңлаешлы һәм төгәл итеп языгыз.**

**1.2.3.** М.Җәлилнең «Кызыл ромашка» һәм Ф.Кәримнең «Ватаным өчен» шигырьләрендә лирик геройның хис-кичерешләрен чагыштырып карагыз. Аларның нинди охшаш һәм аермалы яклары бар?

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иң дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

*Ф.Кәрим «Ватаным өчен»*

## 2 БҮЛЕК

**2 бүлек биремнәренә сочинение язу барышында тәкъдим ителгән темаларның (2.1 – 2.4) бары БЕРСЕН генә сайлап алыгыз. Җаваплар бланкында үзегез сайлаган теманың номерын күрсәтегез. Үзегез сайлаган темага, әдәби материалга таянып, 150 сүз күләмендә киңәйтелгән җавап языгыз. Куелган проблемаларны, автор позициясен үзегез аңлаганча ачыклап, тулы җавап бирүегез сорала. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дәлилләгез. Иншаның төзелешен уйлагыз, эзлеклелекне саклагыз, анализ барышында теоретик төшенчәләргә таяныгыз. Сочинениенең күләме 100 сүздән дә ким булмаска тиеш, шуннан ким булган очракта инша 0 балл белән бәяләнә.**

**2.1.** Г.Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрендә кечкенә Апуш образы.
**2.2.** Г.Ибраһимов иҗатында күтәрелгән проблемалар.
**2.3**. Һ.Такташның лирик герое һәм аңа хас үзенчәлекләр.
**2.4**. Х.Туфан лирикасында күтәрелгән мәсьәләләр.

## КИҢӘЙТЕЛГӘН ҖАВАПЛАРНЫ ТАЛӘП ИТҮЧЕ БИРЕМНӘРНЕҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРҮҺӘМ БӘЯЛӘҮ КРИТЕРИЙЛАРЫ

### 1.1.1, 1.1.2. һәм 1.2.1., 1.2.2. биремнәрен (3-5 җөмлә күләмендә) бәяләү

3-5 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) имтихан тапшыручы укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк | **2** |
| б) имтихан тапшыручы укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган | **0** |
| **3. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

### Чагыштырма пландагы 1.1.3. һәм 1.2.3. биремнәрен бәяләү

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | |
|---|---|
| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, авторлар позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **2** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / сорауга җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан | |

| | |
|---|---|
| сорауга туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Җавапның, әдәби текстларны чагыштырып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап чагыштырма планда языла, мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәрләр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **2** |
| б) җавап бирү барышында әсәрләрне чагыштыру җитәрлек күләмдә түгел, мисаллар файдаланып та, җавапны дәлилли алмый, мисаллар нигезле түгел / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **1** |
| в) җавап бирү барышында әсәрләр чагыштырылмый / яки кирәкле аспектта чагыштырылмый | **0** |
| **3. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **1** |
| б) сөйләм хаталары 3тән артык | **0** |
| *Иң югары балл* | **5** |

**Сочинение биремен бәяләү**

2 нче бүлекнең бирем җаваплары иң мөһимнәрдән санала, шулар арасында иң әһәмиятлесе булып беренчесе – эчтәлек ягы санала. Тикшерү барышында җавапның эчтәлеге 0 балл белән бәяләнгән очракта бирем эшләнмәгән булып санала һәм **алга таба тикшерелми**. Калган бәяләү аспектлары буенча 2нче биремнәрнең җавапларын тикшерү бланкына 0 балл куела.

Җавапны бәяләгәндә, язылган иншаның күләме исәпкә алына. Имтихан бирүчеләргә 150 сүздән ким булмаган күләмдәге текстны язу тәкъдим ителә. Әгәр инша тексты 100 сүздән ким булса, мондый эш үтәлмәгән дип санала һәм “0” балл белән бәяләнә.

| **Критерий** | |
|---|---|
| **1. Җавапның төгәллеге, тирәнлеге, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) укучы сорауны аңлап, төгәл җавап бирә, автор позициясенә нигезләнеп, үз фикерен җиткерә ала, соралган төп үзенчәлекләрне билгели, мисаллар ярдәмендә ныгыта, анализлау сәләтен күрсәтә, җавабын дәлилли, фактик хаталары юк | **3** |
| б) укучы сорауны тулаем аңлап та, җавап бирү барышында гомуми җөмләләр белән чикләнә, мисаллар белән ныгытып, төгәл җавап бирми / яки 1-2 фактик хата күзәтелә | **2** |
| в) сорауга җавап өстән-өстән генә, бик гади аңлатыла, әдәби-теоретик төшенчәләр ярдәмендә ныгытылмый / яки 3-4 фактик хата күзәтелә | **1** |

| | |
|---|---|
| г) укучы сорауга бөтенләй җавап бирми / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны яза / яки 4 тән артык фактик хата күзәтелә | **0** |
| **2. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлау, алар белән эшләү дәрәҗәсе** | **Балл** |
| а) әсәрне анализлау яки чорга характеристика бирү барышында әдәби-теоретик төшенчәләр аңлап, урынлы кулланыла, җавап теоретик яктан югары дәрәҗәдә язылган | **2** |
| б) имтихан тапшыручы әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлый, әмма әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 төгәлсезлек күзәтелә | **1** |
| в) укучы әдәби-теоретик төшенчәләрне дөрес кулланмый яки әдәби-теоретик төшенчәләрдән мәгълүматлы түгел, әдәби материалга анализда аларны куллану барышында 1 дән артык хата ясый | **0** |
| **3. Җавапның, әдәби текстларны кулланып, нигезле, дәлилләнгән булуы** | **Балл** |
| а) җавап мисаллар ярдәмендә ныгытыла, соралган әсәр (әсәрләр) җитәрлек күләмдә файдаланыла (өзекләр китерелә, кыскача эчтәлек сөйләнә, текстның микротемаларына мөрәҗәгать ителә, әсәрләргә сылтамалар бирелә һ.б.) | **2** |
| б) җавапта әсәрнең (әсәрләрнең) турыдан-туры эчтәлеге генә урын ала / яки текстның бу җавапны дәлилли торган өлешләре файдаланылмый | **1** |
| в) җавап бирү барышында әсәр (әсәрләр) бөтенләй файдаланылмый, нигезләнми | **0** |
| **4. Җавапның эзлеклелеге, фикерне җиткерү мөмкинлеге** | **Балл** |
| а) җавап логик яктан эзлекле языла, фикерләр үзара бәйләнештә бирелә, төгәл җиткерелә | **2** |
| б) җавапның мәгънәви өлешләре үзара логик яктан эзлекле языла, әмма аерым кабатлаулар, төгәлсезлекләр күзәтелә / җавап эзлекле булып та, фикер еш кабатлана, төп темадан читкә киткән урыннар күзәтелә | **1** |
| в) җавап логик яктан эзлекле язылмаган, эзлеклелек тупас бозылган, җавапта гомуми мантыйк күренми | **0** |
| **5. Җавапның әдәби сөйләм нормаларына туры килүе** | **Балл** |
| а) сөйләм хаталары юк яки 1 сөйләм хатасы ясалган | **3** |
| б) 2-3 сөйләм хатасы күзәтелә | **2** |
| в) 4 сөйләм хатасы ясалган | **1** |
| г) сөйләм хаталары бик күп (5 яки аннан да артык) булып, фикерне аңлауда кыенлыклар тудыра | **0** |
| *Иң югары балл* | ***12*** |

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 83 нче код биремнәре

## Аңлатма язуы

Әлеге вариантлар белән танышканда, шуны күз алдында тотарга кирәк: алардагы биремнәр 2020 нче елда үтәчәк имтихан эшенең барлык эчтәлек вариантларын да чагылдырмый.

2020 нче елда үтәчәк имтиханда тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге төп дәүләт имтиханын үткәрү өчен укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторында китерелә.

Әлеге вариантлар имтиханда катнашучыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең төзелеше һәм биремнәр саны, шулай ук аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау булдыру мөмкинлеге бирүгә юнәлтелгән.

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән төп дәүләт имтиханын тапшыру өчен, 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше **33 биремне** үз эченә алган **4** бүлектән тора. **1 нче бүлектәге** 13 бирем (1 – 13 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән. **2 нче бүлектәге** 7 бирем (14 – 20 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә. **3 нче бүлектәге** 8 бирем (21 – 28 нче биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала. **4 нче бүлектәге** 29 – 32 нче биремнәр җөмлә калыпларын үзгәртеп язуны күздә тота. Ачык типтагы 33 нче бирем укучыларның язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән.

**Уңышлар телибез!**

## Инструкция по выполнению работы

Время, отведенное на выполнение заданий – 3 часа 55 минут (235 минут). Экзаменационная работа по татарскому языку состоит из четырех разделов, включающих 33 задания. **Раздел 1** (задания по аудированию) включает 13 заданий на понимание аутентичных текстов (задания 1 - 13). **Раздел 2** (задания по чтению) включает в себя 7 заданий (задания 14 - 20). **Раздел 3** (задания по лексике и грамматике) состоит из 8 заданий (задания 21 - 28). **Раздел 4** (задания по письменной речи) состоит из 4 заданий на трансформацию предложений (задания 29 – 32) и задания, в котором предлагается написать личное письмо (задание 33).

**Желаем успеха!**

## 1 нче вариант

### Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Дуслар кичен нишләргә булганнар?**

1) урамда йөрергә
2) театрга барырга
3) дискотекада дуслар белән очрашырга

**2** **Әнәс ни өчен соңга калган?**

1) йокыдан соң торган
2) тукталышын узып киткән
3) тренировкада булган

**3** **Бакчага ничә кеше барган?**

1) биш
2) өч
3) ун-унике

**4** **Әнәс китапны кайдан алган?**

1) дустыннан
2) почта аша
3) китапханәдән

**5** **Фильм сәгать ничәдә булачак?**

1) унда
2) өчтә
3) бишенче яртыда

**6** **Азат кемгә кунакка бара?**

1) Алсуларга
2) Апаларына
3) Сеңлесенә

**7** **Мәскәү автобусы ничәнче платформада туктый?**

1) беренче
2) бишенче
3) алтынчы

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Мөнирә әбисен озатырга бара.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Мөнирә шимбә көнне укыган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Мөнирә бакчада булырга ярата.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Самат һәр көн кичен йөгерергә чыга.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Самат машина йөртү таныклыгы алырга тели.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Самат фатирында эссе булуын әйтә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Яңа кибеткә рәхим итегез!
Өегезгә заманча спорт җиһазлары аласыгыз килсә, безнең кибеткә килегез! Без тәнәфессез һәм ялсыз эшлибез. Биредә сез үзегезгә, балаларыгызга кирәкле әйберләрне таба аласыз. Сәламәт тормыш бездән башлана! Шәһәрдә иң арзан бәяләр бездә!
Адресыбыз: Казан шәһәре, Сибгат Хәким урамы, 100 нче йорт.
Эш вакыты: 10.00- 20.00.

**Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**

1) Яңа кибеттә кешеләр үзләре өчен барлык өй җиһазлары таба алалар.
2) Сәламәт буласыгыз килсә, бу кибеттә барлык кирәк-яракларны табарга мөмкин.
3) Спорт белән шөгыльләнү өчен, монда барлык мөмкинлекләр булдырылган.

**15**

Тамашачылар игътибарына!
“Татар жыры” фестиваленең девизы аның эчтәлеген тулысынча ачып бирә: “Кайда гына булсаң да,

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

1) Җыр фестивалендә чыгыш ясаучылар мәхәббәт турында җырлаячаклар.
2) Җырчылар үзләренең чыгышларын якты хисләргә багышлаячаклар.
3) Фестивальдә катнашучыларның җырлары туып үскән як турында булачак.

күңелеңдә туган як җыры!”. Туган якка мәхәббәт - һәркем өчен иң якты хисләрнең берсе. Кайларга гына барсак та, без туган ягыбызны онытмыйбыз. “Татар Җыры” фестивале туган якка булган бер зур мәхәббәт җыры булып яңгыраячак. Көтеп калабыз!

**16**

| | |
|---|---|
| Сәлам, Алинә! Хатыңны алдым, рәхмәт. Мин дә сиңа яңалыклар турында язарга телим. Февраль аенда безнең мәктәптә Рәзил Вәлиев иҗатына багышланган Шигырь бәйрәме булды. Мин дә, бу чарада катнашып, “Яшә, көмеш кыңгырау!” шигырен сөйләдем һәм призлы урын алдым. Мине котлый аласың! Үзем дә бик шатландым.<br>Хат көтәм. Яз.<br>Дустың Гөлшат | **Электрон хатта Гөлшат дустына нәрсә турында язган?**<br>1)Танылган шагыйрьнең бәйрәмдә чыгыш ясавы турында.<br>2) Шигырь бәйрәмендә җиңүе турында.<br>3) Шагыйрьнең иҗатына багышланган кичә турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Кемгә кирәк, кемгә кирәкми

Әтисе белән Таҗи балык тотарга барды. Көн әле бик иртә. Кояш та юк. Су өсте тып-тын. Җил дә юк.

Мондый вакытта балык яхшы эләгә. Таҗиның әтисе балыкларны сөйри дә чыгара, ә Таҗи аларны чиләккә җыеп бара. Менә чиләк тулып та килә инде. Балык бик шәп эләгә. Шуңа күрә вакыт тиз үтә. Әнә кояш та күтәрелеп килә. Көндез кояш бик нык кыздыра башлады. Моны Таҗи да сизде. Әтисе дә. Әтисе, кесәсеннән кулъяулык алып,  маңгаеннан тирләрен сөртте. Ә Таҗи:

- Фу... Нәрсәгә кирәк инде бу кояш?! – дип, кояшны ачулана башлады.

- Кемгә кирәк, кемгә кирәкми, - диде әтисе, шуннан дәвам итте, - кояш булмаса, җир өстендә үсемлекләр үсмәс, син дә, мин дә булмас идек, - диде.

Кояш кыздыргач, балык эләкми башлады. Таҗи кояшны ачуланган вакытта җил исә башлады. Дулкын кузгалды, калкавычлар бер күтәрелделәр, бер төштеләр. Балык чиртүе күренми башлады. Таҗи:

- Фу, нигә кирәк бу җил?! – диде.

- Кемгә кирәк, кемгә кирәкми, - диде әтисе.

Әтисе Таҗига:

- Әнә, күрәсеңме, җил җилкәнле көймәне этеп бара. Җил әнә тегермәннәрне дә әйләндерә. Ул тегермәндә орлыклар онга әйләнә. Ә ул оннан әниең күмәч пешерә, - диде.

Шул арада җил болытларны куып китерде дә яңгыр ява башлады.

- Фу, яңгыр нигә кирәк инде, елгада су күп бит! – диде Таҗи.
- Кемгә кирәк, кемгә кирәкми, - диде әтисе. Безнең кебек балык тотканда, яңгыр кирәкми. Ә менә болыннарда үләннәр, урманнарда агачлар үссен өчен, яңгыр кирәк.

Яңгыр астында алар икәүләп кармакларын җыйдылар. Шулвакыт яшен яшьнәде, күк күкрәде. Коеп яңгыр ява башлады. Таҗи әтисенең сүзләрен аңлаган иде инде.

Ул:

- Яңгыр яу, яу! – дип кычкыра-кычкыра агач астына таба йөгерде. Бераздан әтисе дә килеп җитте.

- Табигатьтә барысы да кирәкле, улым, - диде. – Эх, яңгырдан соң балык шәп эләгәчәк, - дип өстәде. (*А. Алиштан)*

Таҗи белән әтисе балык тотарга кайсы вакытта баралар?

**17**

1) Кояш чыкканчы баралар.
2) Кич җиткәч баралар.
3) Төштән соң баралар.

**18**

Әтисе улына кояшның кирәклеген ничек аңлата?
1) Кояшсыз балык эләкми.
2) Кояшсыз тереклек булмый.
3) Кояшсыз җил исми.

**19**

Җил нинди файда китерә?
1) Ул булганда, балык яхшырак эләгә.
2) Ул елга өстен тынычландыра.
3) Ул бар нәрсәне хәрәкәткә китерә.

**20**

Таҗи әтисенең көчле сүзләреннән нәрсәне аңлады?
1) Табигатьне сакларга кирәклеген аңлады.
2) Табигатьтә һәр нәрсә файда китергәнен аңлады.
3) Табигатьне пычратырга ярамаганлыгын аңлады.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Эш урынында телефоннан сөйләшү

Эштә телефон шалтыраса, трубканы алырга һәм фирмагызның (21) ... әйтергә кирәк. Ә шалтыратучы исәнләшергә, үзе турында әйтергә һәм «Гафу итегез, мин кем белән (22) ...?», «Гафу итегез, телефонда кем?» - дип сорарга тиеш. Шалтыраткан кеше үз турында әйтмәсә, телефон трубкасын алган кеше бу турыда (23) .... ала. Монда инде, гафу үтенеп, исемеңне әйтергә кирәк. Әгәр кеше үзенең кем икәнлеген әйтмәсә, трубканы (24) ... да мөмкин.

Телефонга чакырылган кеше урынында булмаса, «Аңа нәрсә (25) ...?» - дип сорарга киңәш ителә. Мөмкин булганда, мәсьәләне үзегезгә дә (26) ... ярый. Шуны да истә тотарга кирәк: телефоннан чакыручыга «Кем сорый?» дип әйтү әдәпсезлек була. Мондый сорауны сәркатип кенә бирә ала.

Эш телефоныннан озак сөйләшергә ярамый. Әгәр телефонлы бүлмәдә берничә (27) ... эшләсә, әкренрәк тавыш белән сөйләшергә кирәк.

Шалтыратучы озак (28) ... башласа, аңа «Телефон башка хезмәткәрләргә кирәк» дип әйтергә мөмкин. Эш телефоныннан эшлекле итеп сөйләшә, фикерне кыска итеп әйтә белергә кирәк.

**21** 1) исемне 2) исемен 3) исеменә

**22** 1) сөйләшәм 2) сөйләшеп 3) сөйләштем

**23** 1) сорап 2) сорагач 3) сорый

**24** 1) Куярга 2) алырга 3) бирергә

**25** 1) торды 2) тапшырырга 3) алырга

**26** 1) ярдәм итәргә 2) хәл итәргә 3) киңәш итәргә

**27** 1) кешеләр 2) кешегә 3) кеше

**28** 1) сөйли 2) сөйләп 3) сөйләгәч

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

| ҮРНӘК | **0** Кичә кичен, концерттан соң кайту сәбәпле, мин татар теленнән хикәя язарга җитешмәдем. |
|---|---|

**Кичә кичен мин татар теленнән өй эшен эшләмәдем, чөнки өйгә соң ...**

| **0** | **КАЙТТЫМ** |
|---|---|

**29** Якшәмбе көнне караган тапшыру минем өчен бик файдалы булды.

**Ял көнне мин бик файдалы тапшыру ...**

**30** Дустым, волейбол буенча спорт ярышында катнашып, җиңүче булды, һәм мин аны чын күңелдән тәбрик иттем.

**Дустымны волейбол ярышында ... котладым.**

**31** Әбиемә шалтыратып, аның хәлләрен сораштырдым, чөнки ул авылда бер үзе яши.

**Әбиемнең хәлләрен белү өчен, мин аңа ... .**

**32** Белемле булу өчен, китаплар күп укырга кирәк, чөнки алар – белем чыганагы. күп.

**Белемле булырга теләүче кешеләр күп ... .**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Миңа спорт төрләреннән волейбол бик ошый. Әти-әнием дә студент елларында волейбол белән шөгыльләнгәннәр. Мин дә мәктәптә волейбол секциясенә йөрим, ярышларда катнашам.*

*... Сиңа спортның кайсы төре күбрәк ошый?... Мәктәбегездә нинди спорт секцияләре эшли? ... Спортчы нинди булырга тиеш?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**
**Инструктор. Бер. Дуслар кичен нишләргә булганнар?**

**Алсу**: Әнәс, кичен Галиәсгар Камал театрына барабызмы? Анда бүген яңа спектакльнең премьерасы була.
**Әнәс**: Синең билетларың бармы инде?
**Алсу**: Юк, баргач, кассадан алырбыз.
**Әнәс**: Премьерага билетлар алдан ук сатылып бетә. Әйдә, дискотекага барыйк. Бүген "Фан-клуб"та рок музыкасы концерты була. Биербез, музыка тыңларбыз. Дусларны очратырбыз. Соңыннан урамда йөрергә мөмкин. Кафеда да утыра алабыз.
**Алсу**: Минем кичне тыныч кына үткәрәсем килә. Шау-шуны яратмыйм. Саф һавада гына йөрик. Мин сиңа сыйныфыбызда булган яңалыклар турында сөйләрмен.
**Әнәс**: Ярый. Мин Алия белән Азатны да чакырам. Бергә күңеллерәк булыр.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Ике. Әнәс ни өчен соңга калган?**
**Әнәс**: Исәнме, Алсу! Син рус әдәбияты дәресендә булдыңмы?
**Алсу**: Сәлам, Әнәс! Әйе, әлбәттә, булдым. Ә мин сине анда күрмәдем.
**Әнәс:** Мин дәрестә юк идем. Без ярышларга әзерләнәбез. Кичә тренировкадан соң кайттым. Аннары кызыклы китап укый башладым. Укып бетерергә теләдем, аерыла алмадым. Бүген йокыдан соңрак тордым, барыбер йокым туймады.
**Алсу:** Китап нәрсә турында? Укып бетердеңме инде...
**Әнәс:** Китап могҗизалар иле турында. Фантастик әсәр. Кичә укып бетерә алмадым. Мәктәпкә килгәндә, троллейбуста укып бетердем. Шуңа күрә тукталышны да узып киткәнмен.
**Алсу:** Мәктәпкә кире җәяү килдеңме?
**Әнәс:** Әйе, саф һава сулап, китаптагы ил турында уйлап килдем.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Өч. Бакчага ничә кеше барган?**
**Алсу:** Шимбә көнне син бакчага бардыңмы?
**Әнәс**: Әйе. Әти-әнием белән бардык. Күршебезнең туган көне иде, эштән соң апа белән җизни дә килделәр.

**Алсу:** Туган көндә кеше күп идеме?

**Әнәс:** Ун-уникe кеше бар иде. Анда барлык күршеләр һәм дуслары килгән иде. Бәйрәм күңелле булды.

**Алсу:** Сез якшәмбе көнне кайттыгызмы?

**Әнәс:** Әти белән әни шимбә көнне кичен кайтып киттеләр. Мин, апа һәм җизни белән якшәмбе көнне кайттым.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Әнәс китапны кайдан алган?**

**Алсу:** Әнәс, син нәрсә укыйсың?

**Әнәс:** Джоан Роулингның Гарри Потер турындагы романын татар теленә тәрҗемә иткәннәр. Шуны укыйм.

**Алсу:** Кызыкмы? Каян таптың? Аны мин бик озак эзләдем. Базардан да, китапханәдән дә сорадым, таба алмадым. Интернет аша җибәрүләрен сораган идем, килеп җитмәде әле.

**Әнәс:** Мин дә китапханәдә дә булдым, Интернет аша да соратып карадым, ләкин тапмадым. Дустым үз китабын бер көнгә генә биреп торды. Шуңа күрә бүген укып бетерергә телим.

**Алсу:** Ярый, алайса. Миңа эчтәлеген сөйләрсең. Минем китап та тиздән почта аша киләчәк.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Фильм сәгать ничәдә булачак?**

**Әнәс:** Алсу, исәнме! Син чит планета кешеләре турында яңа фильмны карадыңмы әле?

**Алсу**: Исәнме, Әнәс! Юк шул. Кичә сәгать өчтә кинотеатрга барган идек, соңга калганбыз. Ул бүген иртән сәгать унда да булырга тиеш иде, ләкин ул вакытта минем дәресләрем бар. Кичке сеанс кайчан булуын мин белмим. Ә син карадыңмы?

**Әнәс:** Юк әле, шуны карарга барам. Фильм ярты сәгатьтән башлана.

**Алсу**: Билетларың бармы соң?

**Әнәс:** Әйе, сәгать бердә барып алдым. Ике билетым бар. Минем белән барырга телисеңме?

**Алсу**: Әлбәттә! Хәзер сәгать ничә соң? Без өлгерәбезме?

**Әнәс:** Әйе. Хәзер сәгать дүрт. Әйдә, киттек.

**Алсу**: Рәхмәт!.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Азат кемгә кунакка бара?**

**Әнәс:** Алсу, бүген Азатны кунакка чакырыйк әле. Бергә сөйләшеп утырырбыз. Бер атна күрешмәдек бит инде.

**Алсу:** Мин каршы түгел. Ул килгәч, үткән атнада бик кызык булган иде. Ләкин ул килә алмас шул. Хәтерлиседме, ул бу атнада җизнәсенең туган көне булуын әйтте. Үзен кунакка чакырдылар диде. Ул туган көнгә китеәндер.

**Әнәс:** Ә-ә. Мин онытканмын да инде. Энҗе дә апаларына кунакка барулары турында әйткән иде. Алар - бертуганнар бит.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Мәскәү автобусы ничәнче платформада туктый?**

**Әнәс**: Гафу итегез, сорарга мөмкинме?

**Алсу:** Әйе, рәхим итегез.

**Әнәс:** Мәскәүдән килгән автобус кайсы тукталышта туктар икән?

**Алсу:** Ул һәрвакыт беренче тукталышка килә.

**Әнәс**: Әйе, әлек шулай иде. Хәзер анда ремонт ясыйлар.

**Алсу**: Гафу итегез, онытканмын. Хәзер әйтәм. Пенза автобусы бишенче платформага килә, ә Мәскәүнеке алдагысында.

**Әнәс**: Башкортстан автобусы җиденчедә туктый, Мәскәүнеке аңа кадәргедәме?

**Алсу**: Әйе, дөрес.

**Әнәс**: Рәхмәт.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**

[пауза 20 секунд]

**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.

**Самат**: Сәлам, Мөнирә!

**Мөнирә**: Исәнме, Самат!

**Самат**: Болай соң кая киттең, Мөнирә? Тиздән караңгы төшәчәк бит инде. Курыкмыйсыңмы?

**Мөнирә:** Юк. Син дә урамда йөрисең бит әле. Син йөгерергә чыктыңмы? Син иртән генә йөгермиседмени?

**Самат**: Әйе, мин һәр көн иртән укуга барганчы ярты сәгать йөгерәм. Бүген кич һава суларга чыктым. Фатирда эссерәк. Ә син болай соң кая барырга җыендың?

**Мөнирә:** Мин вокзалга барам. Әбием кичке электричка белән бакчадан кайтырга чыктым дип хәбәр бирде. Аны каршы алырга барам.

**Самат:** Мөнирә, ни өчен Азат абый белән машинада бармыйсыз? Сезнең машинагыз бар бит.
**Мөнирә:** Әти белән әни Сочига ялга киттеләр. Мин бүген укыдым. Иртәгә әбием янына бакчага барырмын дигән идем. Ә ул үзе кайтырга уйлаган. Ә син ник бакчада түгел? Сезнең дә бакчагыз бар бит.
**Самат:** Әйе, бар. Мин дә укыйм бит әле машина йөртү таныклыгы алырга телим. Автомәктәптә укулар шимбә һәм якшәмбе көннәрендә дә була. Шәһәрдә эссе, бакчада рәхәт инде. Анда су коенырга, саф һавада йөрергә мөмкин.
**Мөнирә:** Әйе, мин дә җәй көннәрендә табигатьтә ял итәргә яратам. Бакчада җиләк, яшелчәләр дә өлгерде бит. Самат, сиңа укуыңда уңышлар телим! Машина йөртү таныклыгын тизрәк ал.
**Самат:** Рәхмәт, Мөнирә! Таныклык алгач, бакчага машинада бергә барырбыз.
**Мөнирә:** Ярый, рәхмәт! Самат, гафу ит, мин китим инде. Вокзалга соңга калуым бар. Сау бул!
**Самат:** Сау бул, Мөнирә!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 | 17 | 1 |
| 2 | 2 | 18 | 2 |
| 3 | 1 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 2 |
| 5 | 3 | 21 | 2 |
| 6 | 2 | 22 | 1 |
| 7 | 3 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 1 |
| 9 | 1 | 25 | 2 |
| 10 | 1 | 26 | 2 |
| 11 | 2 | 27 | 3 |
| 12 | 1 | 28 | 1 |
| 13 | 1 | 29 | КАРАДЫМ |
| 14 | 2 | 30 | ҖИҢҮЕБЕЛӘН |
| 15 | 3 | 31 | ШАЛТЫРАТТЫМ |
| 16 | 2 | 32 | УКЫЙЛАР |

## 2нче вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Дуслар театрга ничек барырга булганнар?**

1) метро белән
2) алтмыш өченче автобус белән
3) уникенче троллейбус белән

**2** **Әнәс ничәнче дәрескә соңга калган?**

1) дүртенче
2) өченче
3) икенче

**3** **Бакчага ничә кеше барган?**

1) алты
2) биш
3) дүрт

**4** **Газеталар кайсы бүлмәдә калган?**

1) аш бүлмәсендә
2) кунак бүлмәсендә
3) йокы бүлмәсендә

**5** **Бу атнада театрда нинди спекталь бара?**

1) «Яңа ел маҗаралары»
2) «Кәҗә белән Сарык»
3) «Сертотмас үрдәк»

**6** **Азатның спорт костюмы нинди?**

1) Зәңгәр төстәге, ике сызыклы чалбар һәм ак футболка.
2) Зәңгәр төстәге, өч сызыклы чалбар һәм ак футболка.
3) Кара төстәге, ике сызыклы чалбар һәм ак футболка.

**7** **Поезд ничәнче юлда туктый?**

1) беренче
2) бишенче
3) сигезенче

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Мөнирә әбисенең бакчасына бара.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Мөнирә кичә туган көн бәйрәмендә булган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Мөнирә автобус тукталышына ашыга.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Самат дусты белән йөгерергә чыккан.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Саматларның бакчасында слива белән кура җиләге үсә.

1) 1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Самат әтисенең кайтуын көтә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Ял итүчеләр игътибарына!
Вакытыгызны күнелле һәм файдалы итеп үткәрәсегез килсә, безнең үзәктә көтеп калабыз. Биредә сез теләгәнчә ял итә аласыз. Бездә бию залы, караоке залы, спорт уенары залы, боулинг залы эшли. Заллар 17 сәгатьтән 23 сәгатькә кадәр ачык. Монда сезгә яңа дуслар белән танышырга, күңел ачарга барлык мөмкинлекләр булдырылган.

**Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**

1) Ял итүчеләрне спорт белән актив шөгыльләнергә чакыру турында.
2) Үзәкнең ял итүчеләргә юнәлтелгән эшчәнлеге турында.
3) Ял итүчеләр белдергән теләкләр турында.

**15**

Укучылар!
Киләсе атнада безнең мәктәптә зур вакыйга көтелә. Без мәктәпнең 100 еллык юбилеен билгеләп үтәчәкбез. Шул сәбәпле мәктәпкә күп кунаклар, ветеран укытучылар чакырылган. Шушы чараны уңышлы

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

1) Мәктәп юбилеен үткәрү өчен, чакырулар әзерләү турында.
2) Мәктәптә үткәреләчәк бәйрәмне оештыручылар турында.
3) Юбилей үткәрү өчен, укучыларны ярдәмгә чакыру турында.

үткәрү өчен, волонтерлар кирәк. Кем бу эшне башкарырга тели, 123 нче кабинетка мөрәҗәгать итүегезне сорыйбыз.

| 16 | Сәлам, дустым Наил! Сиңа бер күңелле яңалык турында хәбәр итәсем килә, шуңа күрә ашыгып хат язам. Мине бер айга чит илгә укырга җибәрәләр. Бу турыда бүген иртән сыйныф җитәкчебез әйтте. Шәһәрдән бер төркем укучылар барачак, безнең мәктәптән мине сайлаганнар. Мин бик шатландым. Барып урнашкач, сиңа хат язармын. Дустың Алмаз | **Электрон хат аша Алмазның дустына нәрсә турында әйтәсе килгән?**<br>1) Чит илгә китүе турында.<br>2) Чит илдә булып кайтуы турында.<br>3) Чит илдән килгән бер төркем укучылар белән очрашуы турында. |
|---|---|---|

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Коррида

*(Испаниягә сәяхәт)*

«Тореадор», «матадор», «коррида» кебек сүзләрне китаплардан укып беләбез. Әмма аларны үз күзең белән күрү күпкә кызыграк булды.

Билгеле һәр халыкның ерак гасырлардан килә торган милли уеннары, ярышлары була. Аларның кайберләре халык яшәгән җирдә үткәрелә, шунда гына популяр була. Икенчеләре күп җирләргә тарала. Коррида – әнә шундый уен, куркыныч уен.

«Пласа де торос» аренасы халык белән тулы. Трибуналары һәм утыргычлары белән безнең стадионнарга охшаган, ә арена – башка төрле.

Аренада тантаналы көй ишетелә. Бу - тамаша башлану көе. Коррида президенты (бу уен-тамашаның режиссёры) махсус келәмнәр белән бизәлгән ярус ложасыннан, ак яулык селки, тамашаны башларга рөхсәт бирә. Мәйданга борынгы рыцарьларча киенгән ике егет атларда чыга. Оркестр уйный. Алар халыкка баш иеп, мәйдан тирәли әйләнәләр. Аннары аренаның ян капкаларыннан матадорлар һәм аларның ярдәмчеләре чыга. Барлыгы егермеләп

кеше. Матадорлар алтын чигүле камзуллары белән ерактан ук аерылып торалар. Шулай булырга тиеш, матадорлар - бу уенның корольләре! Алар җыелган халыкны баш киемнәрен салып сәламлиләр, елмаялар... Церемония өч-дүрт минут дәвам итә.

Аннары арена уртасына зур бер үгез чыга. Ул шома мөгезләре белән һавада хәрәкәтләр ясый. Үгез аренада бик ярсып йөри, мондый көчне берни дә тыя алмас шикелле. Очраган һәрбер нәрсәне ул мөгезе белән күккә чөя, юлындагы һәрнәрсәне таптап уза. Шул вакытта, ал җәймәсен җилкән кебек җилфердәтеп, аренага мотодорлар чыга. Үгез күзенә беренче күренгән фигурага ташлана. Ә кеше кире борылып китәргә уйламый да, баскан урынында тора. Ай! Бу хәл бик куркыныч! Ләкин мотодорлар да исән, үгез дә сау! ... (*Р. Фәйзулиннан)*

Халык уеннары турында нәрсә мәгълүм?

**17** 1) Алар бары тик шушы халык яши торган урында үткәрелә.
2) Аларны башка җирләрдә дә уздыралар.
3) Алар ерак гасырларда гына үткәрелгән.

**18** Коррида хуҗасы уен-тамашага килүчеләрне ничек сәламли?
1) Ул яулык болгый.
2) Ул халыкка баш ия.
3) Ул мәйдан тирәли әйләнә.

**19** Аренага атылып чыккан үгез нишли?
1) Тамашачыларны сәламли.
2) Барлык әйберләрне таптый.
3) Матадорга ташлана.

Аренадагы кешеләр үзләрен ничек тоталар?

**20** 1) Алар тыныч кына басып торалар.
2) Аларның тыны кысыла.
3) Алар үгездән куркалар.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Татарстанның табигате матур, бай, төрле һәм (21) ... . Калын зур урманнар да, (22) ... далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә, шуңа күрә катнаш урманнар да, ылыслы урманнар да шактый. Куе агачлар (23) ... аюлар, бурсыклар, бүреләр, төлкеләр һәм куяннарны очратасың.

Татарстан Республикасын «дүрт елга иле» дип йөрткәннәр. Аның (24) ... Идел, Кама, Агыйдел, Нократ елгалары ага. Ык, Зәй, Мишә, Чирмешән, Зөя,

Казансу елгалары исә — аларның кушылдыклары. Кечкенә елгалар, күлләр дә күп анда: Аккош күле, Кабан күле, Зәңгәр күл, Тирән күл һәм башкалар. Алар бик уңайлы (25) ... урыннары булып тора.

Татарстанның климаты уртача: кышлары артык салкын түгел, ә җәйләре түзә алмаслык эссе (26) ... . Болын-кырларда аллы-гөлле чәчәкләр, (27) ... үләннәр бик күп. Татарстан кырларында кукуруз, карабодай, борчак, чөгендер, көнбагыш үстерәләр.

Һәр кеше табигатьне яратырга, аны саклау өчен көрәшергә тиеш. Табигать үзен яраткан кешеләрне генә ярата!

Чиста табигать — сәламәтлек нигезе. (28) ... аны карап, чистартып торырга кирәк. Табигатьне саклау — Ватанны саклау дигән сүз ул!

**21** 1) салкын 2) эссе 3) серле

**22** 1) тугыз 2) тигез 3) тугры

**23** 1) арасында 2) арасыннан 3) арасын

**24** 1) аша 2) башка 3) саен

**25** 1) ял итәргә 2) ял итү 3) ял иткән

**26** 1) була 2) булмас 3) булмый

**27** 1) шәфкатьле 2) шифалы 3) итагатьле

**28** 1) чөнки 2) ләкин 3) шуңа күрә

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Безнең монда яши башлавыбызга ун ел үткән инде.
**Без биредә ... яши башладык.**

| | |
|---|---|
| **0** | УНЕЛЭЛЕК |

**29** Ул белә: бу ярышта көндәшен җиңәргә аның көче җитмәячәк.
**Ул бу ярышта ... белә.**

**30** Кемнең киеме матур, шул кешегә һәрвакыт игътибар итәләр.
**... һәрчак игътибар бирәләр.**

**31** Сез кайчан әйтәсез, без шул вакытка килербез.
**... вакытка килербез.**

**32** Кемнең башы эшләми, шуның аягы күп йөри.
**Башың ...., .... күп йөрер.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**

**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*Якшәмбе көнне мин дусларым белән Чәй йортына бардым. Без анда милли ризыклар ашадык, аралаштык, рәхәтләнеп күңел ачтык. Әлеге кафе безгә бик тә ошады.*
*... Син ял көннәрендә кайларга барырга яратасың? Син кайсы милли кафеларда булдың? Анда сиңа нәрсәләр ошады?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Дуслар театрга ничек барырга булганнар?**
**Алсу**: Дустым, Галиәсгар Камал театрына кадәр нәрсә белән барабыз?
**Әнәс**: Театр моннан еракмы соң?
**Алсу**: Юк, ерак түгел. 63 нче автобуска утырсак, 5 тукталыш барасы. Метро белән барсак, бик тиз инде, ләкин 5 минут җәяү барырга кирәк булачак. Менә бу 12 нче троллейбус та шул якка бара. Ул “Божра” тукталышында туктый һәм аннан да 5 минут җәяү барырга туры киләчәк.
**Әнәс**: Минем яраткан артистыма чәчәкләр дә аласым килә. Метродан чykканда, чәчәкләр сата торган киосклар бар. Спектакль башланганчы, безнең чәчәк сайларга вакытыбыз да кала әле. Әйдә, шуннан барабыз.
**Алсу**: Ярый. Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Ике. Әнәс ничәнче дәрескә соңга калган?**

**Әнәс**: Исәнме, Алсу! Син рус әдәбияты дәресендә булдыңмы?
**Алсу**: Сәлам, Әнәс! Әйе, әлбәттә, булдым. Ә мин сине анда күрмәдем, әллә арткы партада утырдыңмы?
**Әнәс:** Мин дәрестә юк идем. Бүген йөзү буенча шәһәр беренчелегендә катнашабыз, икенче дәрес вакытында тренировкада булдым. Кичә дә бик соң кайттым, шуңа күрә беренче дәрескә - рус әдәбиятына килмәдем.
**Алсу:** Син бу дәрескә дә соңга калдың ахры. Шулаймы?
**Әнәс:** Әйе, чишенү бүлмәсендә тоткарландым. Алсу, математика дүртенче дәрестә буламы? Әйдә, бергә барабыз.
**Алсу:** Әйе. Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Өч. Бакчага ничә кеше барган?**
**Алсу:** Якшәмбе көнне кайда булдыгыз?
**Әнәс**: Гөмбә җыйдык. Бакчага бардык. Иртән иртүк әтием белән әнием машинада киттеләр. Дәресләрдән соң, апам белән автобуста бардык.
**Алсу:** Гөмбә җыярга өлгердегезме соң?
**Әнәс:** Ничек кенә әле! Дүрт кешегә ике чиләк гөмбә җыйдык. Төш вакытында күрше апа да малае белән безгә кунакка килгде. Барыбыз бергә саф һавада гөмбә җыеп йөрдек. Рәхәт булды!
**Алсу:** Кичен ничек кайттыгыз? Бер машинага алты кеше утырдыгызмы?
**Әнәс:** Юк. Күршеләр үз машиналарында ккайттылар.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Дүрт. Газеталар кайсы бүлмәдә калган?**
**Алсу:** Хәерле кич! Әнәс, без әти белән кичәге газеталарны эзләдек, таба алмадык. Син алмадыңмы? Мин аларны йокы бүлмәсендәге өстәлгә куйган идем, ләкин анда юк.
**Әнәс:** Алдагы көнне Миләүшә аларны аш бүлмәсендә укып утырды. Телефоны шалтырады да ул, шунда журналлар янында калдырып, кунак бүлмәсенә кереп китте. Мин моны күрдем.
**Алсу:** Мода журналларын сеңлем кунак бүлмәсендә укып утыра иде. Рәхмәт! Хәзер журналлар арасыннан карыйм, бәлки шундадыр.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Биш. Бу атнада театрда нинди спектакль була?**
**Шалтыратучы**: Исәнмесез, хәзер театрда балалар өчен нинди спектакльләр бара? Әйтә алмассызмы?

**Алсу**: Исәнмесез. Шалтыратуыгыз өчен зур рәхмәт! Бу атнада “Сертотмас үрдәк”, ә киләсе атнада балалар өчен “Кәҗә белән Сарык” әкиятен куябыз. Әкият балаларга бик ошый, ул заманчалаштырып куела. Сез бу әкиятне карамадыгызмы әле?

**Шалтыратучы**: Юк шул, күрмәдек.

**Алсу**: Кызганыч. Карарга тәкъдим итәм. Ике атнадан соң «Кыш бабай мажаралары» дигән яңа спектакль күрсәтә башлыйбыз. Ул нәниләр өчен бигрәк тә кызыклы булачак.

**Шалтыратучы**: Рәхмәт. Ә билетлар сатуда бармы?

**Алсу**: Күп түгел, ләкин бар. Театр кассаларыннан ала аласыз.

**Шалтыратучы**: Яхшы, рәхмәт. Сау булыгыз.

**Алсу**: Сау булыгыз.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Азатның спорт костюмы нинди?**

**Әнәс:** Гафу итегез, Азат спорт костюмын югалтканмы? Ул нинди иде? Төгәлрәк тасвирлап бирегезче.

**Алсу:** Әйе шул, югалткан. Былтыр Алмазныкы кебек костюм алган идек. Костюмнар зәңгәр төстә, уртача киңлектәге чалбар һәм озын футболкалы. Алмазның чалбарында ике сызык, ә Азатныкында өч сызык бар. Футболкасы ак төстә, җиңендә ике кара сызыгы бар. Азат костюмын чишенү бүлмәсендә онытып калдырмады икән. Табылса, бик рәхмәтле булыр идек.

**Әнәс:** Хәзер эзләп карыйбыз.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Поезд ничәнче юлда туктый?**

**Әнәс**: Гафу итегез, сорарга мөмкинме?

**Алсу:** Әйе, рәхим итегез. Тыңлыйм Сезне.

**Әнәс:** Мәскәү поезды кайсы юлда туктый икән?

**Алсу:** Сез “Татарстан” поезды белән барасызмы? Ул һәрвакыт беренче юлдан китә.

Әнәс: Юк, мин Мәскәүдән килә торган поездны көтәм.

Алсу: Пензага бара торган поезд бишенче юлда туктап тора, ә Уфага бара торганы 8 нче юлга киләчәк. Сезгә кайсысы кирәк?

Әнәс: Башкортстанда яшәүче туганнарым Мәскәүдән кайтып киләләр. Шулар белән күрешеп алырга теләгән идем. Ярдәмегез өчен рәхмәт Сезгә!

**Алсу**: Яхшы, Сез көткән поезд 10 минут туктап торачак.

**Әнәс**: Рәхмәт.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**
[пауза 20 секунд]
**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.
**Самат**: Сәлам, Мөнирә!
**Мөнирә**: Исәнме, Самат!
**Самат**: Якшәмбе көнне болай иртә кая киттең, Мөнирә? Син җәйге ялда бит әле. Нигә йокламыйсың?
**Мөнирә:** Йокым туйды инде. Син йөгерергә чыктыңмы?
**Самат**: Әйе, мин һәр көн иртән ярты сәгать йөгерәм, шуңа күрә иртә торам. Бүген дә җиденче яртыда тордым. Гадәттә без дустым Салих белән йөгерә идек, ул җәйге ялга авылына кайтып китте. Ә син иртән кая барырга җыендың?
**Мөнирә:** Мин бакчага барам. Бакчабыз шәһәр читендә, анда автобус белән бер сәгать барырга кирәк, шуңа күрә иртәрәк чыктым.
**Самат:** Мөнирә, ни өчен Азат абый белән машинада бармыйсың? Сезнең машинагыз бар бит.
**Мөнирә:** Әти белән әни кичә кич үк бакчага киттеләр инде. Мин дус кызымның туган көненә бардым, шуңа күрә алар белән бара алмадым. Ә син ник бакчада түгел? Сезнең дә бакчагыз бар бит.
**Самат:** Әйе, бар. Мин дә бүген кичен бакчага китәм. Сәгать унда әтием командировкадан кайта, аны каршы алырга теләгән идем. Аннары аның белән бергә бакчага китәрбезз. Шәһәрдә эссе, бакчада рәхәтләнеп су коенырга, саф һавада йөрергә мөмкин.
**Мөнирә:** Әйе, мин дә җәй көннәрендә табигатьтә ял итәргә яратам. Бакчада җиләк, яшелчәләр дә өлгерде бит. Рәхәтләнеп кура җиләге белән чәй эчәргә була.
**Самат:** Мин мәтрүшкәле чәй эчәргә яратам. Кура җиләгеннән әнием кайнатма әзерли. Кышын ул бик тәмле була.
**Мөнирә:** Әйе, килешәм. Быел без бакчада карбыз да үстердек. Алмалар да өлгерде, тиздән слива да өлгерер. Сездә слива бармы?
**Самат:** Слива бар, ләкин карбыз үсми.
**Мөнирә:** Ярый, мин сине сыйлармын. Самат, гафу ит, мин китим инде. Автобуска соңга калуым бар. Киләсе атнада мәктәптә очрашырбыз. Сау бул!
**Самат:** Сау бул, Мөнирә!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

## ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 | 17 | 2 |
| 2 | 2 | 18 | 1 |
| 3 | 1 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 1 |
| 5 | 3 | 21 | 3 |
| 6 | 2 | 22 | 2 |
| 7 | 3 | 23 | 1 |
| 8 | 2 | 24 | 1 |
| 9 | 1 | 25 | 2 |
| 10 | 1 | 26 | 3 |
| 11 | 2 | 27 | 2 |
| 12 | 1 | 28 | 3 |
| 13 | 1 | 29 | КӨЧЕҖИТМӘЯЧӘГЕН |
| 14 | 2 | 30 | КИЕМЕМАТУРГА |
| 15 | 3 | 31 | СЕЗӘЙТКӘН |
| 16 | 1 | 32 | ЭШЛӘМӘСӘАЯГЫҢ |

**3нче вариант**

**Раздел 1**

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Дуслар Әмирләргә ничек барырга булганнар?**

1) 43 нче автобус белән
2) 5 нче трамвай белән
3) 2 нче троллейбус белән

**2** **Әнәс ничәнче дәрескә килгән?**

1) Беренче
2) Икенче
3) Өченче

**3** **Балыкка ничә кеше барган?**

1) Алты
2) Биш
3) Дүрт

**4** **Әкият китабы кайсы бүлмәдә калган?**

1) Аш бүлмәсендә
2) Кунак бүлмәсендә
3) Йокы бүлмәсендә

**5** **Бу атнада циркта нинди тамаша уза?**

1) «Еланнар, тигрлар һәм гепард»
2) «Экзотик хайваннар белән»
3) «Кыш бабай һәм җәнлекләр

**6** **Малайның сумкасы нинди?**

1) Кара төстә, бер магнит төймәсе дә бар.
2) Кара төстә, кечкенә, аса торган бавы да бар.
3) Коңгырт төстә, уртача зурлыкта, ике төймәсе дә бар.

**7** **Әфәнде сәгать ничәдәге автобусны көтә?**

1) 11.45
2) 8.30
3) 7.45

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Мөнирә һәр көн җиденче яртыда тора.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Мөнирә туган көнгә нинди бүләк алачагын Самат ярдәмендә ачыклый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Мөнирә автобус тукталышына ашыга.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Самат якшәмбе саен иртән әтисе белән йөгерә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Самат дустына рок-төркем концертына билет алган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Самат егетләргә бүләк сайлау авыр түгел дип уйлый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

**Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.**

**14**

| | |
|---|---|
| Хәерле көн, Алсу ханым! Ял вакытында минем Мәскәүгә барасым килә. Ялым август ахырында булыр дим уйлыйм. Башкалабызга килгәч, Сезнең белән дә очрашасы иде. Минем белән күрешергә вакытыгыз булырмы? Сездән хат көтеп калам.<br>Сиринә ханым | **Сиринә ханымның нәрсә беләсе килгән?**<br>1) Алсу ханымның җәйге ялы турында беләсе килгән.<br>2) Алсу ханым белән очрашу мөмкинлеген ачыклыйсы килгән.<br>3) Алсу ханым белән очрашу вакытын билгеләргә теләгән. |

**15**

| | |
|---|---|
| Кадерле укучылар! Шахмат уены белән кызыксынсагыз, безнең түгәрәккә килегез. Монда без сезне уйнарга өйрәтербез. Аннары сез төрле ярышларда катнашырсыз. Шимбә | **Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**<br>1) Шахмат уйнарга өйрәнергә теләүчеләрне чакыру турында.<br>2) Шахмат белән кызыксынучылар түгәрәгенең эш сәгате |

| | |
|---|---|
| көнне сәгать өчтә 217 нче кабинетта сезне көтеп калабыз. | турында.<br>3) Шахмат буенча ярыш үткәрү турында. |

| | | |
|---|---|---|
| **16** | Сеңлем, сиңа сыйныфташың Гөлназ шалтыратты һәм бүген мәктәптә яшь шагыйрьләр белән очрашу булачагы турында әйтте. Очрашуда син дә шигырь сөйләргә тиеш икән, шуңа күрә әзерләнеп баруыңны сорады.<br>Апаң | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Шагыйрьләр белән очрашуга һәркем әзерләнә.<br>2) Мәктәптә төрле чор шагыйрьләре белән очрашу булачак.<br>3) Мәктәптәге очрашуда укучылар да чыгыш ясаячак. |

**Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.**

**Менә кем иде ул Алиш**

Кем соң ул Алиш?

Абдулла Алиш балаларны бик яраткан, алар өчен әкиятләр, шигырьләр, кечкенә хикәяләр язган, ләкин явыз сугыш аның гөрләп торган эшләрен бүлә. Меңләгән кешеләр белән бергә Алиш сугышка китә.

Абдулла Алиш туган илен бик ярата, ул чын патриот була. Яраткан язучыбыз Аркадий Гайдар кебек, кулына корал тотып, Ватанны фашистлардан саклый. Ул бик батыр солдат була, бернәрсәдән дә курыкмый. Каты яраланып, 1941 нче елның октябрендә Дёсна елгасы буенда дошман кулына төшкәч тә, ул аңа баш ияргә уйламый. Аны Алитус лагерена ябалар, аннары Чехословакиягә, Германиягә озаталар. Алиш, тугрылыклы иптәшләре белән бергә, качу турында хыяллана, ләкин алар кача алмыйлар, серләре ачыла. Шуннан соң аларны бик каты газаплыйлар, ашарларына берни дә бирмиләр. Гитлерчылар алардан борчак зурлыгындагы ташлар җыйдырталар. Котелоклары тулгач:

- Хәзер менә шул ташлардан үзегезгә аш пешерегез, -  дип көләләр.

Алиш лагерьда, гитлерчыларга каршы көрәшкә өндәп, шигырьләр яза, рухлары төшкән иптәшләренә кулыннан килгән кадәр ярдәм итә.

Лагерьларның берсендә Алиш Муса Җәлилне очрата. Алар бер-берсен элек-электән яхшы беләләр, икесенең дә йөрәгендә фашистларга карата нәфрәт уты яна.  Алар соңгы сулышларына кадәр көрәшергә ант итәләр. Дуслар бергәләп листовкалар язалар. Фашистлар хәрби әсирләрдән легионнар төзи башлагач, әсирләргә фашистлар сүзенә ышанырга ярамавын, илгә хыянәт итү – иң зур җинаять икәнен аңлаталар. Аларның агитацияләре уңышлы була.

Легионерлар, фронтка җибәрелгәч, үзләренең немец командирларын үтереп, партизаннар ягына чыгалар.

Шуннан соң гитлерчылар шикләнә башлыйлар. Ниндидер бер сатлык җан аларга яшерен оешма турында әйтә. Муса Җәлил, Абдулла Алиш һәм аларның якын дуслары, кулга алынып, Моабит төрмәсенә ябылалар. Биредә аларны тагын бик каты газаплыйлар, ләкин алар дошманнан шәфкать сорамыйлар, батырларча һәлак булалар (*Г. Әпсәләмовтан)*

**17** Сугышка кадәр Абдулла Алиш нәрсәләр иҗат иткән?
1) Сугыш турында хикәяләр
2) Әкиятләр һәм мәсәлләр
3) Кечкенәләр өчен әсәрләр

**18** Сугышта яраланып, дошман кулына эләккән язучы үзен ничек тота?
1) Ул фашистларга буйсынмый.
2) Аның рухы төшә.
3) Ул фашистлар лагереннан кача.

**19** Муса Җәлил белән Абдулла Алиш нишләргә сүз бирәләр?
1) Фашистларны юк итәргә.
2) Ахыргы сәгатьләренә кадәр фашистларга каршы көрәшергә.
3) Хәрби әсирләрне азат итәргә.

**20** Җәлилчеләр үлемне ничек каршылыйлар?
1) Алар бөтен газапларга түзәләр.
2) Алар сатлык җанны белергә телиләр.
3) Алар яшерен оешма турында борчылалар.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

### Канатлы дусларыбызны онытмыйк

Менә кыш та килеп җитте. Бер-ике көн эчендә әллә никадәр кар (21) ... . Бөтен тирә-як (22) ... юрган астында калган кебек иде.

Укытучыбыз Сания апа кошларга җимлекләр ясап (23) ... һәм анда нинди кошлар очып килүен күзәтергә кушты. Без моңа шатланып риза булдык. Мәктәптән кайткач, һәрберебез җимлек ясарга керештек.

Мин дә тактадан кечкенә (24) ... өстәл һәм җимлек ясадым. Аны урман

янындагы карт чыршы төбенә куйдым. Чыршының (25) ... ботаклары җимлектәге азыкны кар басудан сакларлык иде. Җимлек әйбәт булып чыкты. Ул тәрәзәбездән дә күренеп тора әле. Дөресе шулай. Минем әтием урманчы булып эшли. Шуңа күрә урман (26) ... өйдә яшибез.

Якшәмбе көн иде. Җимлегемә ипи, ярма, кипкән миләшләр салдым. Бер читтән (27) ... башладым. Менә ике песнәк килеп кунды. Ярма белән икмәкне ашадылар. Шул арада кызылтүшләр очып килеп җитте. Алар миләш яраталар икән. Рәхәтләнделәр миләш ашап. Ә чыпчыклар? Алар җимлектән (28) ... ашыкмыйлар әле. (*Ш.Бикколдан*)

**21** 1) яуды 2) каплады 3) эреде

**22** 1) кап-кара 2) ап-ак 3) ямь-яшел

**23** 1) эшләргә 2) алырга 3) куярга

**24** 1) әле 2) бит 3) генә

**25** 1) куе 2) тигез 3) нечкә

**26** 1) өстендәге 2) янындагы 3) төбендәге

**27** 1) күрә2) аңлый 3) күзәтә

**28** 1) китәргә 2) утырырга 3) башларга

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Безнең монда яши башлавыбызга ун ел үткән инде.
**Без биредә ................................ яши башладык.**

| | |
|---|---|
| **0** | УНЕЛЭЛЕК |

**29** Дустымның кичә кая баруы турында беләсем килеп, аңа сорау бирдем.
**Мин дустымнан сорадым: « Кичә син ....?»**

**30** Туганнарыбызны яңа йортка күчүләре белән котлап, затлы бүләк бирәсебез килә.

**Безнең туганнар яңа өйгә күчтеләр, шул сәбәпле без аларга затлы бүләк ...**

**31** Без яхшы беләбез: дуслар шатлык килсә дә, кайгы килсә дә кирәк.
**Дусларның һәрвакытта кирәклеген һәркем ... .**

**32** Быел Сабан туена туганнарыбыз белән бергәләп баруыбызга бик тә шатландым, чөнки бу искиткеч күңелле бәйрәм булды.

**Без туганнарыбыз белән быелгы ... булдык, һәм мин моңа чын күңелемнән куандым.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы. Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

| |
|---|
| *... Ял көнне без гаиләбез белән татар театрына бардык. Анда бик кызыклы спектакль карадык. Ул мәхәббәт турында иде.*<br>*... Син ял көннәрендә кайларга барырга яратасың? Син кайсы театрларда булдың? Анда син нәрсәләр карадың?* |

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Дуслар Әмирләргә ничек барырга булганнар?**
**Алсу**: Дустым, Әмирләргә кадәр нәрсә белән барабыз?
**Әнәс**: Аларның йортлары еракмы соң?
**Алсу**: Юк, ерак түгел. 43 нче автобуска утырсак, ике тукталыш барасы һәм 5 минутка якын җәяү барырга кирәк булачак. 5нче трамвай аларның йортлары янында ук туктый. Аның белән барсак, борылыштагы тукталышка кадәр 3 минут җәяү барырга кирәк. Менә бу 2 нче троллейбус та шул якка бара, ләкин Әмирләрнең йортларын узып, «Ашамлыклар» кибете янында туктый. Теге син ярата торган конфетларны шул кибеттә саталар инде.

**Әнәс**: Борылышта газета киоскы бар бит, шулаймы? Мин әтигә бүгенге газеталар да алырга вәгъдә иткән идем, әйдә, шул яктан барабыз.
**Алсу**: Ярый. Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Ике. Әнәс ничәнче дәрескә килгән?**
**Әнәс**: Исәнме, Алсу! Син дә философиядән лекция тыңларга килдеңме?
**Алсу**: Сәлам, Әнәс! Әйе, лекциягә килдем. Ә мин сине алдагы дәресләрдә күрмәдем, син кайсы рәттә утырдың соң?
**Әнәс:** Мин практик дәрестә юк идем. Бүген без ансамблебез белән концертта катнашабыз, икенче дәрес вакытында шуның репетициясендә булдым. Кичә дә репетициядән бик соң кайттык, шуңа күрә беренче дәрескә йоклап калганмын.
**Алсу:** Ярый, сиңа уңышлы чыгышлар телим.
**Әнәс:** Рәхмәт, Алсу! Алдагы ике дәрестә үтелгән материалларны күчереп алу өчен, дәфтәрләреңне биреп торчы.
**Алсу:** Ярар, бирермен.
**Әнәс:** Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Өч. Балыкка ничә кеше барган?**
**Алсу:** Ял көнне кайда булдыгыз?
**Әнәс**: Балыкка бардык. Иртән әтием белән икәү машина белән киттек. Бераз соңрак энем дусты белән килде.
**Алсу:** Балык эләктеме соң?
**Әнәс:** Ничек кенә әле! Дүрт кешегә ике чиләк балык тоттык. Төш вакытына абый белән сеңлем дә килеп җиттеләр. Барыбыз бергә уха пешердек, су коендык. Ялыбыз бик яхшы үтте.
**Алсу:** Кичен ничек кайттыгыз? Бер машинага алты кеше утырдыгызмы?
**Әнәс:** Юк. Энем белән дусты велосипедта килгәннәр иде.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Дүрт. Әкият китабы кайсы бүлмәдә калган?**
**Алсу:** Хәерле кич! Әнәс, без Миләүшә белән әкиятләр китабы эзләдек, таба алмадык. Аны син алмадыңмы? Мин аны йокы бүлмәсендәге шкафка куйган идем, ләкин ул анда юк.
**Әнәс:** Алдагы көнне Миләүшә аны аш бүлмәсендә укып утыра иде. Телефоны шалтырады да ул, китапны шунда газеталар янында калдырып, кунак бүлмәсенә кереп китте. Мин моны күрдем.

**Алсу:** Газеталарны иртән эти кунак бүлмәсендә укып утыра иде. Рәхмәт! Хәзер газеталар арасыннан карыйм, бәлки шундадыр.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Бу атнада циркта нинди тамаша уза?**

**Шалтыратучы**: Исәнмесез, хәзер циркта нинди тамаша уза? Әйтә алмассызмы?

**Алсу**: Исәнмесез. Шалтыратуыгыз өчен зур рәхмәт! Бу һәм киләсе атнада циркта Мәскәүдән бертуган Запашныйлар чыгыш ясый. Аларның искиткеч кызыклы программаларын күргәнегез бардыр инде. Алар былтыр “Еланнар, тигрлар һәм гепард” исемле тамаша тәкъдим иткәннәр иде.

**Шалтыратучы**: Юк шул, күрмәдек.

**Алсу**: Кызганыч. Әмма быелгы «Экзотик хайваннар белән» дигән тамаша да былтыргы программадан калышмый. Ике атнадан соң «Кыш бабай һәм җәнлекләр» дигән яңа тамаша күрсәтә башлыйбыз. Ул программа нәниләр өчен бигрәк тә кызыклы булачак.

**Шалтыратучы**: Рәхмәт. Ә билетлар сатуда бармы соң?

**Алсу**: Күп түгел, ләкин бар. Цирк кассаларыннан ала аласыз.

**Шалтыратучы**: Яхшы, рәхмәт. Сау булыгыз.

**Алсу**: Сау булыгыз.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Малайның сумкасы нинди?**

**Энәс:** Гафу итегез, ханым, Сезнең улыгыз сумкасын югалтканмы? Ул нинди иде? Төгәлрәк тасвирлап бирегезче.

**Алсу:** Әйе шул, югалткан. Үткән ел кара төстәге 2 яктан магнит төймәле сумкасын югалткач, коңгырт төстәге шундый ук сумка алган идек. Ул аны троллейбуста онытып калдырган. Сумкасы уртача зурлыкта, эчендә кечкенә блокнот, ручкалар һәм ике папкасы да булган. Сумканың аса торган бавы да бар. Сумка табылса, бик рәхмәтле булыр идек.

**Энәс:** Тырышып карарбыз!

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Әфәнде сәгать ничәдәге автобусны көтә?**

**Энәс**: Гафу итегез, сорарга мөмкинме?

**Алсу:** Әйе, рәхим итегез. Тыңлыйм сезне.

**Әнәс:** Ярдәм итә алмассызмы?Автовокзалга бик иртә килгәнмен. Мин Уфага барам.

**Алсу:** Иртәнге рейс беләнме?

Әнәс: Юк, икенче рейс белән.

Алсу: Унике туларга унбиш минуттамы?

Әнәс: Әйе. Чемоданнарым бик авыр. Саклык камерасының кайда икәнлеген әйтә алмассызмы? Аларны шунда калдырырга телим.

**Алсу**: Саклык камералары билет кассаларыннан сулда урнашкан. Әмма алар сәгать тугызынчы яртыдан гына эшли башлыйлар. Сезгә бераз көтәргә туры килер. Хәзер әле сигез туларга унбиш минут кына.

**Әнәс**: Рәхмәт.

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**

[пауза 20 секунд]

**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.

**Самат**: Сәлам, Мөнирә!

**Мөнирә**: Исәнме, Самат!

**Самат**: Якшәмбе көнне болай иртә кая киттең, Мөнирә? Мин сине әле йоклыйсыңдыр дип уйлаган идем.

**Мөнирә:** Син дә йокламыйсың икән бит. Йөгерергә чыктыңмы?

**Самат**: Әйе, мин һәр көн иртән ярты сәгать йөгерәм, шуңа күрә иртә торам. Бүген дә җиденче яртыда тордым. Гадәттә без әтием белән йөгерәбез, бүген әтием юк. Ул командировкада, шуңа күрә үзем генә йөгерәм. Ә син кая барасың?

**Мөнирә:** Мин якшәмбе саен әбиемә барам. Ул шәһәрнең башка районында яши, автобус белән бер сәгать барырга кирәк, шуңа күрә иртәрәк чыктым.

**Самат:** Мөнирә, син бүген Азатның туган көненә барасыңмы? Ул сине дә чакырам дигән иде.

**Мөнирә:** Әйе, чакырды. Барырга телим, ләкин әле бүләк алып өлгермәдем. Ә син өлгердеңме инде?

**Самат:** Әйе. Мин аңа ул яраткан рок-группа концертының видеоязмасын бүләк итәчәкмен. Ул бу концертка бара алмады, ләкин бик теләгән иде. Мин кичә шул язманы таптым.

**Мөнирә:** Син өлгер. Ә мин нәрсә бүләк итәргә дә белмим. … Самат, сез Азат белән дуслар бит, киңәш бир әле, бүләккә нәрсә алсам яхшырак булыр?

**Самат:** Татарлар энә дә бүләк, дөя дә бүләк, диләр. Нәрсә бүләк итсәң дә ярый, иң мөһиме: ул чын күңелдән бирелгән бүләк, теләнгән теләк булсын.

**Мөнирә:** Әйе, анысы шулай. Ләкин, минемчә, егетләргә бүләк сайлау кыенрак. Безгә, кызларга, нәрсә дә бүләк итеп була: чәчәк тә, хушбуй да, китап та…. Ә егетләргә….
**Самат:** Ник егетләргә  бүләк сайлау кыен дип уйлыйсың әле син? Бер дә алай түгел. Анысы дөрес: чәчәк  бүләк итә алмыйсың инде, ләкин китап - менә дигән бүләк булачак.
**Мөнирә:** Син чынлап әйтәсеңме? Ә нинди китап? Азат нәрсә турында укырга ярата?
**Самат**: Ул күбрәк фантастик әсәрләр укый. Чит планеталар, галактика  серләре белән кызыксына.
**Мөнирә**: Самат, киңәшең өчен зур рәхмәт! Син мине бер бәладән коткардың. Мин инде бүләгем булмагач, әллә туган көнгә бармыйммы дип уйлый башлаган идем. Ә хәзер әбиемнән кайтканда, китап кибетенә кереп, бүләк алып чыгачакмын. Аның йорты янында «Китаплар дөньясы» кибете бар. Бик зур кибет.
**Самат:** Ярдәм итә алуыма мин бик шат!
**Мөнирә:** Ярый, Самат, кичен очрашырбыз. Мин автобуска йөгердем.
**Самат:** Сау бул, Мөнирә.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.**  Җавапларны  махсус бланкка күчерү өчен,  6 минут вакытыгыз бар.

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 17 | 3 |
| 2 | 3 | 18 | 1 |
| 3 | 1 | 19 | 2 |
| 4 | 1 | 20 | 1 |
| 5 | 2 | 21 | 1 |
| 6 | 3 | 22 | 2 |
| 7 | 1 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 3 |
| 9 | 1 | 25 | 1 |
| 10 | 1 | 26 | 2 |
| 11 | 2 | 27 | 3 |
| 12 | 2 | 28 | 1 |
| 13 | 1 | 29 | КАЯБАРДЫҢ |
| 14 | 2 | 30 | БИРЕРГӘТЕЛИБЕЗ |
| 15 | 1 | 31 | ЯХШЫБЕЛӘ |
| 16 | 3 | 32 | САБАНТУЕНДАБЕРГӘ |

## 4нче вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Алмаз китап кибетенә ни өчен килгән?**
1) яңа китап сатып алырга
2) Наилә белән очрашу өчен
3) дустына ярдәм итү өчен

**2** **Наилә кая ашыга?**
1) Боз сараена
2) дискотекага
3) дәү әниләренә

**3** **Алмаз нинди җырлар ярата?**
1) эстрада җырларын
2) халык җырларын
3) классик авторлар әсәрләрен

**4** **Дуслар якшәмбе көнне нишләргә булалар?**
1) концертка барырга
2) 23нче кабинетта очрашырга
3) Азатка сюрприз ясарга

**5** **Очрашу сәгать ничәдә булачак?**
1) 11.30да
2) 11.20 дә
3) 11.50 дә

**6** **Наиләгә нинди фильмнар ошый?**
1) комедияләр
2) сәяхәтчеләр турында фильмнар
3) могҗизалы фильмнар

**7** **Бишенче дәрес ни өчен булмаячак?**
1) ветераннар белән очрашу булганга
2) укытучы авырганга
3) экскурсиягә барганга

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Җәмилә җиңел сәнәгать колледжында укый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Кыз эшче һөнәрләр буенча халыкара бәйгедә катнашырга әзерләнә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Самат Җәмиләнең пианинода яхшы уйнавын белә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Җәмилә – булачак дизайнер.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Самат Россия күләмендә үткәрелә торган спорт бәйгесенә әзерләнә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Җәмилә белән Самат бер йортта яшиләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Татар китапларын укырга яратучыларны "Әдәби марофон" бәйгесендә катнашырга чакырабыз. Моның өчен marofon.2019.com сылтамасы буенча теркәлү узарга гына кирәк. "Әдәби марофон" да сез яраткан китабыгыз турында сөйли, Интернет челтәре аша аны башкаларга тәкъдим итә алачаксыз. Шулай ук сезне танылган татар шагыйрьләре һәм язучылары белән очрашулар көтә. "Әдәби марофон" 1нче марттан 30 нчы мартка кадәр барачак. 30нчы март көнне бәйгенең җиңүчеләре билгеле булачак. Җиңүчеләрне төрле мәдәни чараларга билетлар һәм автор имзасы куелган өр-яңа китаплар көтә! Бәйгедә катнашырга ашыгыгыз! Теркәлү 1нче мартта тәмамлана.
Белешмә өчен телефон:
8 (843) 5-11-12-13

**Белдерү нәрсә турында?**

1) Татар китапларына реклама турында.

2) "Әдәби марофон" бәйгесендә катнашырга чакыру турында.

3) "Әдәби марофон" бәйгесе җиңүчеләрен котлау турында.

| | | |
|---|---|---|
| **15** | Хөрмәтле остазларыбыз!<br>Сезне авыр, ләкин мактаулы һөнәри бәйрәмегез белән котлыйбыз. Сез - яшь буынга белем орлыклары чәчүчеләр, илебезнең киләчәге өчен яңа кадрлар әзерләүчеләр. Шундый олы җанлы, тырыш һәм таләпчән остазларыбыз булу белән һәрберебез горурлана. Сезгә озын гомер, нык сәламәтлек, ак бәхетләр телибез! Сабырлык чишмәләрегез беркайчан да саекмасын. Һәрчак гадел булып калыгыз.<br>Тирән ихтирам белән укучыларыгыз. | **Бу котлау нәрсә хөрмәтенә язылган?**<br>1) Туган көн белән котлап<br>2) Белем көне хөрмәтенә<br>3) Укытучылар көненә багышлап |
| **16** | Сәлам, Алсу! Хәлләрең ничек? Имтиханнарыгыз башланмадымы әле? Син һәрвакыттагыча бик тырышып әзерләнәсеңдер инде. Мин дә имтиханнарга әзерләнәм. Быел 3 имтихан тапшырачакмын. Шуңа күрә һәр көн өстәмә әзерлек курсларына йөрим. Беренче имтиханым 5 нче майда булачак. Хәзер сынап карау имтиханнары тапшырып йөрибез. Мин рус теленнән мондый имханны тапшырдым инде. 89 балл җыйдым. Ә син рус теленнән имтихан тапшырып карадыңмы инде?<br>Алсу, сиңа бер үтенечем бар иде. Үткән очрашуда син инглиз теленнән сөйләмгә өйрәнү буенча тренажерың бар дигән идең. Бу электрон тренажермы? Мөмкин булса, миңа сылтамасын җибәр әле. Киләсе имтиханым инглиз теленнән булачак, шуңа күрә үземне сынап карарга телим.<br>Уңышлар сиңа! Хәбәрләр көтәм. Яз!<br>Дустың Алисә. | **Электрон хат аша Алисә дустыннан нәрсә сорый?**<br>1) Имтиханга әзерлек материалы турында мәгълүмат җибәрүне сорый.<br>2) Имтиханнарының ничек үтүе турында язуын сорый.<br>3) Дустының имтиханныры кайчан булуы турында язарга куша. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Безнең республикабызда чишмәләр бик күп. Алар һәр авылда, һәр районда бар. Кайбер урыннарда саны дистәдән артып китә. Кайберләре Изгеләр чишмәсе дип атала. Бу чишмәләрнең суы тәнне савыктыра. Начар күрүчеләрнең

күзләре  ачыла, бик күп авыруларны юып төшерә чишмә суы. Мондый чишмәләрнең даны ераkларга кадәр җитә. Кешеләр чишмә суы алырга берничә дистәләгән километр ераклыклыктан да киләләр. Чишмәләр, милләткә, дини карашларга карамыйча, һәркемне сихәтләндрәләр.

Без чишмәләрдән чиста, тәмле су эчәбез, ләкин аларны карап, чистартып торабызмы соң?

Әби-бабаларыбыз заманында чишмәләргә игътибар зур булган. Аерым кешеләр аларны карап торган. Чишмә башларын күз карасыдай саклаганнар. Авылларда “Чишмә көне”, “Чишмә бәйрәм”нәре үткәргәннәр.  Кеше исемнәре белән аталган чишмәләр бу кешеләрне мәңгеләштергән.

Чишмәләр  –  барлык төр сулыкларның башлангычы, туклáндыра торган чыганаклары. Чишмә яшәүдән туктаса, елга-күлләрдә су бетәчәк, авылда ямь калмаячак. Хәзерге авыллар бай һәм матур. Хәзер урамнарда, көянтә-чиләк асып, чишмәдән кайтучы кызлар, яшь киленнәр дә  сирәк очрый. Һәр йорттан диярлек бер яки берничә  транспорт чыга, суны машина белән ташыйлар яки торбалар аша өйдән генә агызыа алалар. Ә табигать ярлылана бара. Урамнарда инде чирәм, үлән үсми, авыл эчендәге һәм тирә-юнендәге чишмә чыганакларын чистартып тормагач, алар тилмереп кибәләр.

Чишмәләр - халкыбыздагы чисталык, сафлыкны күрсәтү символы. Саф һәм пакъ, киң күңелле кеше турында сөйләгәндә, гадәттә, чишмә суы сафлыгы күздә тотыла. Тикмәгә генә яшҗләргә чишмә суыдай саф мәхәббәт теләмиләр бит.

Чишмә-чыганакларны карауга әби-апаларыбыз зур әһәмият биргәннәр. Татарстандагы һәр авылда диярлек берәр хатын-кыз исеме белән аталган чишмә очрамый калмый. Әйтик, Абыстай чишмәләре шактый еш очрый. Зөбәйдә, Канифә чишмәләре, Зәбидә, Сәрия күлләре, Сәлия, Оркыя елгалары шул исемдәге хатын-кыз исемнәрен киләчәк буыннарга истәлек итеп мәңгеләштергәннәр.

Соңгы вакытта элек-электән килә торган традиция юкка чыга бара. Техника үскән саен, табигатькә зыян күбрәк килә. Һәрберебез чиста  чишмә суы эчәргә яратса да,  чишмәләрне чистартып, карап торырга ашыкмый. Аларны чистартып, тирә-юненә рәшәткә тотып, кечкенә генә агачлар утыртып була. Моның өчен күп вакыт та кирәкми.   Ә күңел җылысы кирәк, туган төбәгеңне ярату кирәк. *(Фирдәвес Гариповадан) )*

**17** Татарстанда  саф сулы  чишмәләр кайда урнашкан?

1) Изгеләр чишмәләре кайбер  районнарда бар.
2) Чишмәләр һәр  авыл һәм район җирлегендә бар.
3) Татарстанда хәзер чишмәләр югала бара.

**18** Чишмәләргә ни өчен кеше исемнәре бирелгән?

1) Чишмә үзенә иң  еш йөрүченең исеме белән атала башлаган.

2) Чишмә авылын яраткан хатын-кыз исеме белән аталган.
3) Чишмәләр үзләрен карап торучыларның исемнәрен мәңгеләштергән.

**19** Авыл табигате ни өчен үзгәрә?
1) Авылда транспорт күбәйгәнгә.
2) Табигатькә кешеләр игътибарсыз булганга.
3) Авылда кеше азрак яши башлаганга.

**20** Чишмәләр яшәсен өчен нишләргә кирәк?
1) Аларны даими карап, чистартып торырга кирәк.
2) Тирә-ягына рәшәткә генә утыртырга кирәк.
3) Тирә-ягына агачлар утыртырга гына кирәк.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Хыял

Рахман сәяхәтче (21) ... тели. Ул сәяхәт (22) ... китаплар укыды, Россия картасын да бик яхшы белә. Рахман үз илебездә генә сәяхәт итәчәк. Африка чүлләре, Һиндстан урманнары, Амазонка елгасы шулай ук кызыктыра, (23) .... үзебездә дә андый җирләрне табып була. (24) ... илебездә барысы да бар.

Их, болытлар өстенә (25) ..., сәяхәт итеп йөрсәң икән! Менә бу сәяхәт булыр иде. Менәрбез, тормышта (26) ... генә башладык бит әле без. Барысына да өлгерербез, хыяллар зур һәм (27) ... күкрәтеп яшәрбез! Рахман, сәяхәтләрдә йөреп, моңарчы билгеле булмаган байлыкларны кешелеккә (28) ....

(М.Хуҗиннан)

**21** 1) булырга 2) булган 3) булу

**22** 1) кебек 2) турында 3) белән

**23** 1) һәм 2) яки 3) ләкин

**24** 1) безнең 2) бездә 3) безне

**25** 1) менәргә 2) менеп 3) менгән

**26** 1) яши 2) яшәргә 3) яшәдек

| **27** | 1) яшен | 2) болыт | 3) күк |
|---|---|---|---|

| **28** | 1) бүләк итәр | 2) бүләк итте | 3) бүләк итә |
|---|---|---|---|

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кичә, авыру сәбәпле, мин укуга бара алмадым.

**Кичә мин мәктәпкә бара алмадым, чөнки ...**

| **0** | **АВЫРДЫМ** |
|---|---|

**29** Якшәмбе көнне концертка баргач, дустыбызны очраттык.
**Ял көнне без концертка бардык, шунда ... очрады.**

**30** Мин олимпиадада җиңдем, сыйныфташларым мине бу сәбәпле котладылар.
**Сыйныфташларым мине олимпиадада .... тәбрик иттеләр.**

**31** Әтием командировкага китү сәбәпле, мин тренировкаларымны туктатып тордым.
**Әтием командировкага..., минем тренировкаларым тукталып торды.**

**32** Дәресләр бетсә дә, укучылар өйләренә кайтырга ашыкмадылар.
**..., шулай булуга карамастан укучылар өйләренә ашыкмадылар.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин сәяхәт итәргә яратам. Гаиләбездә һәркем табигатьне яратканга, без урманнарга, күлләргә, тауларга сәяхәт итәбез. Кышын чаңгыда, җәен велосипедта сәяхәткә чыгабыз. Табигатьне күзәтү, елгада балык тоту, учакта аш әзерләү, палаткада йоклау безгә бик ошый.*
*... Ял көннәрендә син нишләргә яратасың? ... Гаиләгез белән бергә кайларга барасыз? ... Иң зур хыялың нинди?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Алмаз китап кибетендә нишли?**

**Наилә**: Сәлам, Алмаз! Син кичә генә яңа китап сатып алган идең бит. Бүген дә китап кибетенә килдеңмени?

**Алмаз**: Сәлам, Наилә! Әйе, мин кичә бик кызык китап сатып алдым. Аны төне буе рәхәтләнеп укыдым. Беләсеңме, анда Арктикада яшәүче кешеләр турында язылган. Нинди батыр алар!

**Наилә**: Алай икән! Бүген инде яңа китап сатып алырга килдеңме?

**Алмаз**: Юк, мин әле кичә алган китабымны укып бетермәдем. Мин дустым белән килдем. Ул рус теленнән эш дәфтәре сатып алырга тели. Берничә китап кибетендә булган, ләкин кирәкле дәфтәрне тапмаган. Мин аны бирегә алып килдем. Безнең китап кибетендә эш дәфтәрләре күп бит. Бәлки монда бардыр.

**Наилә**: Син бик ярдәмчел, Алмаз! Алмаз, син Арктика турында китабыңны укып бетергәч, миңа да биреп торчы. Кызыктырдың, укыйсым килә башлады.

**Алмаз:** Бик рәхәтләнеп, Наилә! Иртәгә мәктәпкә алып килермен. Мин аны бүген кичен укып бетерәчәкмен.

**Наилә**: Яхшы, Алмаз, рәхмәт

**Алмазә**: Сау бул, Наилә! Иртәгә очрашканга кадәр.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Наилә кая ашыга?**

**Наилә**: Алмаз, сәлам!

**Алмаз**: Сәлам, Наилә! Син кая җыендың? Син бүген мәктәпкә дискотекага бармыйсыңмыни?

**Наилә:** 63нче автобусны көтәм. Бүген Боз сараенда бик матур тамаша булачак. Дустым белән шунда барасы идек. 10 инде минут автобус көтәм. Ә ул һаман килми.

**Алмаз:** Мин дә дискотекага бара алмыйм. Дәү әниләргә барырга кирәк. Ә анда 63нче автобус белән генә барып була. Тамаша сәгать ничәдә башлана соң?

**Наилә:** Сәгать биштә. Тамаша башланырга кырык минут кына вакыт калды инде.

**Алмаз:** Наилә, борчылма! Автобус хәзер килеп җитәр. Боз сараена кадәр 10 минутта барып җитәчәкбез. Ә дустың кайда соң?

**Наилә:** Ул мине Боз сарае янында көтә. Шунда очрашабыз дип сөйләштек.

**Алмаз**: Бик яхшы. Әнә автобус та килә. Әйдә, утырабыз!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау.  Алмаз нинди җырлар ярата?**
**Алмаз:** Наилә, якшәмбе көнне концертка барасыңмы? Минем 2 билетым бар.
**Наилә**: Әйе, әлбәттә, барам. Концерт кайда була? Нинди концерт?
**Алмаз:** Татарча солянка. Төрле татар җырчылары җырлаячак. Эстрада җырлары да, татар халык җырлары да, классик авторлар әсәрләре дә булачак дип уйлыйм.
**Наилә:** Бик яхшы! Мин татар эстрадасын бик яратам. Ә сиңа нинди җырлар ошый?
**Алмаз:** Миңа халык җырлары ошый. Анда Филүс Каһиров һәм Ришат Төхфәтуллин булачак. Алар татар халык җырларын башкарырлар дип өметләнәм.
**Әминә:** Әйе, алар - бик моңлы башкаручылар. Чакыруың өчен рәхмәт, Алмаз! Концертта очрашырбыз.
Алмаз: Яхшы, Наилә.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау.  Дуслар якшәмбе көнне нишләргә булалар?**
**Алмаз:** Наилә, сәлам! Син кичә Алияне күрдеңме? Сез тәкъдимне кабул иттегезме?
**Наилә:** Исәнме, Алмаз! Кичә Алия белән очраша алмадык. Ул кичек шалтыратырга тиеш иде, ләкин ни өчендер шалтыратмады.
**Алмаз:** Алайса, сез якшәмбе көн турында сөйләшмәдегез. Шулаймы?
**Наилә:** Әйе, сөйләшмәдек.
**Алмаз:** Наилә, якшәмбе көнне Азатның туган көне. Ул сыйныфташларны кунакка чакырырга җыена. Безгә инде әйтте. Сезгә чакыруны бүген бирәчәк. Без Азатка сюрприз әзерләргә телибез. Сезнең дә ярдәм кирәк булачак.
**Наилә:** Яхшы. Мин риза. Ләкин Миңа Алия белән бу хакта әйтмәде әле. Якшәмбе көнне концертка барырга җыенган идек. Дөрес, әлегә билетлар алмадык әле.
**Алмаз:** Концертка башка вакытта барырсыз. Сыйныфташларның туган көне һәр көнне булмый!
**Наилә:** Әлбәттә! Мин Азатның туган көнен бергә үткәрүгә каршы түгел. Без нәрсә эшләргә тиеш булабыз соң?
**Алмаз:** Сез Алия белән бүген 23нче кабинетка килегез. Озын тәнәфестә барысын да аңлатам.
**Наиә:** Яхшы.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Очрашу сәгать ничәдә булачак?**

**Наилә:** Алмаз, әйт әле, яшь шагыйрьләр белән очрашу актлар залында булачакмы?

**Алмаз**: Әйе. шунда булачак.

**Наилә:** Алия очрашу өч дәрестән соң башлана диде. Бу дөресме?

**Алмаз**: Өч дәрестән соң озын тәнәфес була бит. Очрашуны дүртенче дәрес вакытында оештыралар.

**Әминә:** Өч дәрес уникенче яртыда бетәчәк. Аннан соң егерме минут тәнәфес була. Димәк, очрашу унике туларга ун минутта башланачак. Шулаймы?

**Алмаз**: Әйе. Сез очрашуга киләчәксезме? Минемчә, анда бик кызык булачак. Сыйныф җитәкчебез яшь язучылар арасында безнең мәктәпне тәмамлаучылар да бар диде.

**Наилә:** Шулаймыни! Әлбәттә киләчәкбез. Мин дә шигырҗләр язам, ләкин аларны туганнарыма гына укыганым бар. Башка яшьләрнең шигырьләрен тыңлау миңа бик кызык булачак дип уйлыйм.

**Алмаз**: Димәк, очрашуда очрашачакбыз.

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Наиләгә нинди фильмнар ошый?**

**Наилә:** Алмаз, сәлам! Син бүген кинотеатрга барасыңмы?

**Алмаз:** Әйе, барам. Анда яңа триллер күрсәтә башлыйлар бит. Рекламасын күрдем, кызык булырга охшаган.

**Наилә:** Сиңа триллерлар ошыймы?

**Алмаз:** Әйе, ошый. Андый фильмнарны карагач, минем энергиям арта. Әлбәттә, комедияләр карарга да яратам. Бигрәк тә иске фильмнар – Леонид Гайдай кинолары ошый.

**Наилә:** Ә мин сәяхәтләр һәм сәяхәтчеләр турында фильмнар карарга яратам. Алар аша яңа илләр һәм күп җирләр турында беләсең.

**Алмаз:** Син бүген кинотеатрга триллер карарга бармыйсыңмыни?

**Наилә:** Кинотеатрга барам, ләкин без энем белән “Аждаһаны ничек кулга ияләштерергә” фильмын караячакбыз. Энемнең бу фильмны карыйсы килә.

**Алмаз:** Әйе, бу кызык фильм. Фантастика. Мин карадым инде. Сезгә ошар дип уйлыйм.

**Наилә:** Рәхмәт, Алмаз. Кинотеатрда очрашырбыз.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Дәрес ни өчен булмаячак?**

**Наилә**: Алмаз, гафу ит, син бишенче дәрескә әзерләндеңме? Укытучы ничә күнегү эшләргә кушкан иде.

**Алмаз:** Дәрескә әзерләндем, ләкин сыйныф җитәкчесе бишенче дәрес булмаячак диде. Бу вакытта без мәктәп музеена барачакбыз.
**Наилә:** Анда нәрсә булачак?
**Алмаз:** Ветераннар белән очрашу булачак. Безнең сыйныф укучылары музейдагы яңа экспонатлар турында сөйләячәкләр. Соңрак ветераннар хөрмәтенә концерт та булачак.
**Наилә**: Алмаз, син бу очрашуда катнашачаксыңмы?
**Алмаз**: Әйе. Мин бабамның Бөек Ватан сугышында катнашуы турында сөйләячәкмен һәм аннан алып кайткан медальләре белән таныштырачакмын.
**Наилә**: Афәрин! Минем дә син сөйләгәннәрне тыңлыйсым килә.
**Алмаз**: Рәхим ит! Музейга керү ирекле.
**Наилә**: Рәхмәт, Алмаз!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый] **[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**Самат**: Исәнме, Җәмилә!
**Җәмилә**: Исәнме, Самат!
**Самат**: Җәмилә, соңгы вакытта син һәр көн каядыр ашыгасың? Яңа түгәрәкләргә язылдыңмы әллә?
**Җәмилә:** Юк, Самат! Мин технология һәм дизайн колледжында укыйм бит. Быел Казанда эшче һөнәрләр буенча халыкара бәйге булачагын ишеткәнсеңдер инде. Анда мин дә катнашачакмын. Шуңа күрә без хәзер конкурска әзерләнәбез. Һәр көн дәресләрдән соң төрле биремнәр башкарабыз, үзебезнең һөнәри осталыгыбызны арттыру өчен тырышабыз.
**Самат**: Бик шәп! Мин синең өчен бик шат, Җәмилә! Бәйгедә җиңүеңне телим. Син бу конкурста дизайнер буларак катнашачаксыңмы? Үзеңнең коллекцияңне күрсәтәчәксеңме?
**Җәмилә:** Рәхмәт, Самат! Бәйгедә һәр катнашучы үзен төрле яктан күрсәтергә тиеш була. Без үз һөнәребез турында сөйләргә, тегәргә, биергә, җырларга һәм башка осталыкларыбызны да күрсәтергә тиеш булабыз. Мин үзем уйлап тапкан милли костюмнарымны күрсәтәчәкмен.
**Самат:** Кызык! Хәзер сез биергә, җырларга өйрәнәсезме?
**Җәмилә:** Конкурста катнашучы һәр нәрсәне булдырырга тиеш бит. Безне остазларыбыз төрле ситуацияләрдә югалып калмаска өйрәтәләр. Хәзер мин вокал белән шөгыльләнәм, сәнгатьле сөйләм осталыгымны арттыру өчен тырышам..
**Самат:** Син бик матур җырлыйсың бит, Җәмилә! Мәктәптә укыганда, сыйныфтагы һәр чарада катнаша идең. Мин моны яхшы хәтерлим.

**Җәмилә:** Рәхмәт! Әйе, мин музыка мәктәбендә укыдым, шуңа күрә җырлый да, скрипкада да уйный беләм. Ләкин конкурска килүчеләр барысы да шундыйлар. Анда 60 ка якын илдән яшьтәшләрем киләчәк бит. Алар арасында сынатырга ярамый.
**Самат:** Минемчә, син булдырачаксың, Җәмилә! Син бик тырыш бит. Мин шундый кыз белән бер йортта яшәвемә горурланам!
**Җәмилә:** Рәхмәт, Самат! Мине генә мактап утырма әле, үзең дә төшеп калганнардан түгел! Бокс буенча уңышларың турында беләм бит мин. Тиздән син дә чемпион булырсың!
**Самат:** Рәхмәт! Чемпионлыкка ерак әле, Җәмилә! Ләкин киләсе атнада мин дә Россия җыелма командасының әзерлек турнирына китәм. Илкүләм бәйгегә әзерләнәбез.
**Җәмилә:** Сиңа да уңышлар һәм җиңүләр телим, Самат!
**Самат:** Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**У вас есть 6 минут, чтобы внести ответы в специальный бланк.**

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 17 | 2 |
| 2 | 1 | 18 | 3 |
| 3 | 2 | 19 | 2 |
| 4 | 3 | 20 | 1 |
| 5 | 3 | 21 | 1 |
| 6 | 2 | 22 | 2 |
| 7 | 1 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 1 |
| 9 | 1 | 25 | 2 |
| 10 | 2 | 26 | 1 |
| 11 | 1 | 27 | 3 |
| 12 | 1 | 28 | 1 |
| 13 | 1 | 29 | ДУСЛАРЫБЫЗ |
| 14 | 2 | 30 | ҖИҢҮЕМБЕЛӘН |
| 15 | 3 | 31 | КИТКӘНЛЕКТӘН |
| 16 | 1 | 32 | ДӘРЕСЛӘРБЕТТЕ |

## 5нче вариант
## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Әминә кемгә бүләк эзли?**
1) әнисенә
2) апасына
3) абыйсына

2 **Кызлар дәрестән соң кая баралар?**
1) шахмат секциясенә
2) бию түгәрәгенә
3) спорт залына

**3** **Дискотекага ничә кеше барган?**
1) дүрт
2) биш
3) җиде

**4** **Әминә нинди китаплар укырга ярата?**
1) мәхәббәт романнары
2) детективлар
3) танылган кешеләр турында әсәрләр

**5** **Алмаз кайсы театрга барачак?**
1) Г. Камал театрына
2) Яшь тамашачы театрына
3) “Әкият” театрына

**6** **Әминә кичен нишләргә тели?**
1) кунакка барырга
2) кунаклар чакырырга
3) туган көнгә барырга

**7** **Контроль эш ничәнче дәрестә булачак?**
1) беренче
2) икенче
3) өченче

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Алсу укуын үз мәктәбендә дәвам итәргә тели.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Алсуның сыйныфташлары тату түгел.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Сәлим унынчы сыйныфта укый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**11** Сәлим ил күләмендә үткәрелгән ярышларда катнаша.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Әти-әнисе Сәлимнең мәктәптә калуын телиләр.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Алсу Сәлимгә дөрес юл сайларга киңәш итә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

**14**

Музыка белән кызыксынучыларга! Консерваториядә балалар өчен музыка дәресләре үткәрелә. Алар анда классик музыка үрнәкләрен тыңлый алалар. Шулай ук музыка кораллары белән танышырга мөмкинлекләр дә булдырылган. Һәр якшәмбе көнне сезне әлеге дәресләргә көтеп калабыз. Алар сәгать унда башлана һәм сәгать уникегә кадәр дәвам итә. Музыка дәресләрен консерватория студентлары алып бара. Балаларда музыкага карата мәхәббәт тәрбиялик!
Телефоннар:
8 (843) 5-11-12-13
8 (843) 5-14-15-16

**Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**

1) Консерваториядә балалар өчен үткәрелә торган музыка бәйрәме турында.
2) Музыка мәктәбендә үтә торган дәресләр турында.
3) Балаларны музыка белән кызыксындыру өчен оештырыла торган дәресләр турында.

**15**

Хөрмәтле укучылар!
Апрель аенда мәктәптә күренекле татар язучысы Гаяз Исхакыйның юбилеена багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрелә. Сезне анда катнашырга һәм

**Бу хәбәр нәрсә турында?**

1) Булачак конференциянең көне һәм вакыты турында.
2) Мәктәп укучылары өчен оештырыла торган фәнни

| | |
|---|---|
| чыгыш ясарга чакырабыз. Конференциядә катнашу өчен, язучының тормышы, иҗаты һәм әсәрләре турындагы тезисларны 20 нче февральгә кадәр оештыру комитетына җибәрүегезне сорыйбыз. Үткәрү көне һәм вакыты турында өстәмә хәбәр булачак. | конференция турында.<br>3) Язучының юбилеена чакыру турында. |

| | | |
|---|---|---|
| **16** | Сәлам, Динә! Хәлләрең әйбәтме? Сине бик сагындым. Җәйге ялда тагын авылда очрашырбыз дип ышанам. Быел җәйге каникулда син авылга кайтырга җыенасыңмы? Без гаиләбез белән июнь ахырында әбиләргә кунакка кайтырга җыенабыз, чөнки әти-әнием шул вакытта ял ала. Синең белән очрашуны көтеп калам. Кайту көнен СМС аша хәбәр итәрмен.<br>Дустың Алинә | **Электрон хат аша Алинә дустына нәрсә турында язган?**<br>1) Җәйге ялны авылда дусты белән бергә үткәрү теләге турында.<br>2) Җәен авылдагы әбиләренә кайту һәм ярдәм итү турында.<br>3) Дустын әбиләренә кунакка чакыру турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Илдар быел Әниләр бәйрәмендә әнисенә башка беркем дә уйлап таба алмаган әйбер бүләк итәргә булды. Ул инде белә: Хәлим абыйсы, әнисенә дип, матур сәгать алды. Нәсимә апасы тәмле исле хушбуй алып кайтты. Илдар аның тәмледән-тәмле исләрен каян беләме? Апасы өйдә юк чакта, иснәп карады инде ул бу бүләк-хушбуйны.

Беркөнне тәрәзәдән тышка карап утырганда, Илдарның башына шундый уй килде: әгәр дә ул, кардан әнисенең сынын ясап, 8 Март көнне шуны алып кереп бүләк итсә? Әй сөенер иде әнисе! Илдар шулай итте дә. Әниләр бәйрәменә бер көн кала, ул кич буе кар кисәкләреннән бер кеше сыны ясап куйды. Бу сын әнисенә бик тә охшаган кебек тоелды.

Шул ук кичтә Илдар үзенең бүләген качырып кына алып кереп, бүлмәсенең бер почмагына бастырып куйды. Җәймә белән капларга да онытмады. Иртән барысы да гадәттәгедән иртәрәк уянды. Ел саен шулай: иртәнге ашка кадәр үк Илдар әтисе, абыйсы һәм апасының котлау сүзләрен, бүләк бирүләрен түземсезлек белән көтте.

Чират җиткәч, Илдар әнисе янына килде дә: «Хәзер мин үз бүләгемне күрсәтәм», — дип, бүлмәсенә йөгерде. Әмма, бүлмә ишегеннән атлап керүгә, нииндидер суга басуын тоеп алды Илдар. Идәнгә карады да аһ итте: аның «кар әнисе» җылы өйдә эреп беткән, ә кар суы бөтен бүлмәгә җәелгән!

Илдар нишләргә дә белмичә каушап калды. Әнисенә нинди бүләк бирә инде ул хәзер? ... Менә сиңа бәйрәм! ... Әнисе күргәнче, идәнне тизрәк сөртеп

алырга кирәк. Әле ярый бүлмәдә зур агач савытта гөл үсеп утыра. Илдар җыеп алган бөтен суны шул гөл төбенә агыза торды. Инде идәнне сөртеп бетерәм дигәндә генә, залдан әнисенең: «Илдар, балам, бүләгеңне карарга чыгыйкмы инде?» — дигән тавышы ишетелде.

Илдар соңгы мәртәбә идәнне сөртеп алды да, гөл төбенә соңгы тамчы суны агызып, чүпрәкне карават астына яшереп куйды. Шулвакыт аның янына әнисе, әтисе, абыйсы, апасы килеп керде. Килеп керүгә, юеш идән уртасында басып торган Илдарга карап телсез калдылар...

Әнисе улын шатландырып:

— И-и-и улым, менә нинди зур бүләк әзерләгәнсең икән син миңа! Идәнне югансың! Миңа бер эш тә калмаган. Рәхмәт, улым, мең рәхмәт сиңа!.. Кил әле, шуның өчен бер яратыйм үзеңне! Шулвакыт еларга җитешеп басып торган Илдарның күзләрендә ниндидер тылсымлы нур балкышы чагылып китте. Һәм ул, дөньядагы иң бәхетле бер малай булып, әнисенең кочагына атылды... (*Галимҗан Гыйльмановтан)*

**17** Илдар әнисенең туган көненә нинди бүләк әзерли?
1) Ул тәмле исле хушбуй сатып алды.
2) Ул беркемнекенә дә ошамаган бүләк ясарга тели.
3) Әнисен сөендерер өчен, ул аның рәсемен ясарга уйлый.

**18** Илдарларның гаиләсендә туган көн бәйрәме ничек башлана?
1) Иртәнге аштан соң, ул барлык туганнары белән бергә әнисен котлый.
2) Бу көнне Илдар барысыннан да алда әнисен котлый.
3) Башта әнисен олылар котлый.

**19** Илдар әнисенә бүләген ни өчен бирә алмый?
1) Ул әзерләгән бүләген таба алмый.
2) Аның бүләге суга әйләнгән.
3) Ул ясаган сын әнисенә ошамаган.

**20** Әнисе улын ничек тынычландырган?
1) Яхшы бүләк өчен аңа рәхмәтен җиткергән.
2) Аңа бер сүз дә әйтмәгән.
3) Ул малайга бүләк биргән.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

**Милли музей**

Татарстанның бай (21) .... музейларда чагыла. Республикабызның иң зур музее – Татарстанның Милли музее. Ул башкалабызның (22) ... Кремль урамында урнашкан.

Музей 1895 нчы елда (23) ... . Андагы экспонатларның күпчелеген танылган археолог А.Ф.Лихачёвның шәхси коллекциясе тәшкил итә. Музейның беренче уставында шундый сүзләр бар: "Музейның төп максаты – бу якның табигате, биредә яшәүче халыклар турында киң мәгълүмат (24) ...".

Музей тарихи истәлек булган бинада урнашкан. Элек анда Сәүдә йорты булган. Бина XIX гасыр (25) ... төзелгән.

Милли музейда дөньяның төрле (26) ... җыелган 700 меңнән артык экспонат саклана. Алар арасында төрле тарихи чорларга караган әйберләр күп. Алар музейга (27) ... борынгы заманнарга алып китә. Музейда бүгенге Татарстанны күрсәткән мәгълүматлар да бар.

Татарстан (28) ... багышланган экспонатлар да бик кызыклы. Милли музейда борынгы кульязмалар һәм китаплар, татар классик язучыларының ахивлары да саклана.

**21** 1) тарихи 2) тарихы 3) тарихын

**22** 1) үзәгенең 2) үзәгенә 3) үзәгендә

**23** 1) ачылды 2) ачылган 3) ачылыр

**24** 1) бирергә 2) бирү 3) бирәчәк

**25** 1) дәвамына 2) дәвамының 3) дәвамында

**26** 1) илләреннән2) илләрдән 3) илләргә

**27** 1) караучыларны 2) китүчеләрне 3) килүчеләрне

**28** 1) табигатен 2) табигатенә 3) табигатеннән

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кичә, авыру сәбәпле, мин укуга бара алмадым.

**Кичә мин мәктәпкә бара алмадым, чөнки ...**

| 0 | **АВЫРДЫМ** |
|---|---|

**29** Әниемнең туган көненә пешергән тортым бик тә тәмле булды.
**Әнинең туган көненә мин тәмле ...**

**30** Дустым гимназиядән ерак булмаган йортта яши.
**Дустым яши торган йорт безнең гимназиядән ...**

**31** Бүген әбиемә шалтыраттым, чөнки аның белән күптән күрешкәнебез юк инде, хәлләрен беләсем килде.
**Күптән күрешмәгәнгә күрә, әбиемә ...., аның хәлләрен белдем.**

**32** Абыем бассейнга йөри һәм бик яхшы йөзәргә өйрәнде, ярышларда да катнаша.
**Абыем ... кызыксына, шуңа күрә атнага өч тапкыр бассейнга йөри.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Мин музыка белән шөгыльләнергә яратам. Дәресләрдән соң музыка мәктәзбенә йөрим. Музыка миңа тормышымда бик булыша, чөнки мин матурлыкны аңларга өйрәнәм.*
*... Син буш вакытыңда нәрсә белән шөгыльләнәсең?... Син нәрсәләр белән кызыксынасың? ... Буш вакытны ничек үткәрергә кирәк?*

## Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.**

**Беренче сорау. Әминә кемгә бүләк эзли?**
**Алмаз**: Әминә, исәнме! Кунакка барырга җыенасыңмы әллә? Бүләкләр карыйсың...
**Әминә**: Сәлам, Алмаз! Әйе, бүләк эзлим, ләкин кунакка бармыйм. Март ае - безнең гаиләдә бәйрәмнәр ае. Әнием дә, апам да, абыем да мартта туганнар.
**Алмаз**: Бик яхшы бит! Димәк, ай буе бәйрәм итәсез.
**Әминә**: Әйе, ләкин аларга нинди бүләк алырга дип баш ватам. Абыема туган көненә футболка бүләк иттем. Апама инглизчә-русча сүзлек алдым. Аларга бик ошады.

**Алмаз**: Әниеңә чәчәкләр һәм хушбуй бүләк ит! Чәчкәләрне һәркем ярата.
**Әминә:** Аңа чәчәк бәйләме белән хушбуйны 8 нче Мартка бүләк иттем инде.
**Алмаз**: Алай икән... Бәлки матур яулык карарсың. Икенче катта матур яулыклар саталар.
**Әминә**: Рәхмәт, Алмаз! Хәзер шунда барып карыйм.
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Икенче сорау. Кызлар дәрестән соң кая баралар?**
**Әминә**: Исәнме, Алмаз! Син Алия белән мине дәресләрдән соң көтеп тора аласыңмы?
**Алмаз**: Сәлам, Әминә! Ярый, көтәрмен. Нишләргә телисез?
**Әминә:** Физкультура дәресендә тупны кәрзингә кертә алмадык бит. Киләсе дәрескә кадәр бу күнегүне өйрәнәсебез килә. Син баскетбол түгәрәгенә йөрисең бит. Безгә тупны кәрзингә кертү серен өйрәт әле.
**Алмаз:** Ярар. Ләкин минем вакытым аз. Сәгать икедә шахмат секциясенә барам.
**Әминә:** Без дә кичен бию түгәрәгенә барабыз. Спорт залы да ярты сәгать кенә буш булачак. Мин белештем инде. Ярдәм итәрсең бит. Без бик тырышачакбыз.
**Алмаз:** Ярар. Дәресләрдән соң очрашырбыз.
**Әминә:** Рәхмәт, Алмаз!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Өченче сорау. Дискотекага ничә кеше барган?**
**Алмаз:** Әминә, кичә дискотекага бардыңмы?
**Әминә**: Әйе. Алсу һәм Алия белән бардык. Соңрак Азат белән Сергей да килделәр. Син генә булмадың.
**Алмаз:** Кичә мин ярышта идем. Җиңеп кайттык. Командабыз 2 нче урынны алды.
**Әминә:** Котлыйм! Сәлим белән Андрей да шуңа күрә килмәделәрмени? Алар бу дискотеканы бик көткәннәр иде бит.
**Алмаз:** Әйе, без бер командада уйныйбыз. Дискотека тагын булыр әле.
**Әминә:** Әйе, киләсе атнада да булачак.
**[2 секунд пауза]**
**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Дүртенче сорау. Әминә нинди китаплар укырга ярата?**

**Алмаз:** Әминә, син тагын китапханәгә барасыңмы?

**Әминә:** Әйе. Тапшырасы китабым бар.

**Алмаз:** Нинди китап укыдың? Кызыкмы?

**Әминә:** Джоан Роулингның "Гарри Поттер һәм тылсымлы таш" китабын укып чыктым. Китап миңа ошады. Ләкин миңа маҗаралы әсәрләр бик кызык түгел.

**Алмаз:** Шулай инде, кызлар мәхәббәт турында укырга яраталар. Хәзер китапханәгә мәхәббәт романын алырга барасыңмы?

**Әминә:** Алмаз, барлык кызлар да бертөрле түгел инде. Кемгәдер мәхәббәт романнары ошый, кемнәрдер детектив укырга ярата, кемдер сугыш турында әсәрләр укый.

**Алмаз:** Сиңа кайсы күбрәк ошый инде? Хәзер нинди китап алачаксың?

**Әминә:** Мин атаклы кешеләр тормышы белән кызыксынам. Алар турында китаплар укыйм. Хәзер Петр Беренче турында китап укыйсым килә.

**Алмаз:** Ярар. Эчтәлеген миңа да сөйләсең.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз..**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Бишенче сорау. Алмаз кайсы театрга барачак?**

**Әминә:** Алмаз, исәнме! Син Зөлфәт Хәким әсәре буенча яңа спектакльне карадыңмы әле?

**Алмаз**: Исәнме, Әминә! Юк шул. Аны Яшьләр театры төрле биналарда куя икән. Кичә Г.Камал исемендәге татар театрына бардык, ләкин анда башка спектакль иде. Бүген бу спектакльне Кәрим Тинчурин театрында һәм "Әкият" театрында куячаклар, ләкин мин бүген бара алмыйм. Бүген дәресләребез күп.

**Әминә:** Спектакльне иртәгә дә куячаклар. Сәгать 11 дә Яшь тамашачы театры бинасында, ә кичен Г. Камал театрында.

**Алмаз**: Билетлар бармы икән?

**Әминә:** Әйе, сатуда бар. Сиңа ничә билет кирәк? Алыйммы?

**Алмаз**: Әлбәттә! Мөмкин булса, 2 билет ал. Кичен дәресләрдән соң барырбыз.

**Әминә:** Яхшы. Билетларыңны иртәгә бирермен.

**Алмаз**: Рәхмәт!

**[2 секунд пауза]**

**Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Алтынчы сорау. Әминә кичен нишләргә тели?**

**Әминә:** Алмаз, бүген кичен дусларны кунакка чакырыйк әле. Бергә күңел ачарбыз, чәй эчәрбез.

**Алмаз:** Мин каршы түгел. Дуслар белән очрашу бик яхшы, ләкин мин сиңа әйтергә онытттым бит. Бүген Айратның туган көне. Ул безне кафега чакырды. Бәйрәмгә барлык дуслар да киләчәк. Шунда очрашырбыз.

**Әминә:** Ә-ә-ә шулаймыни? Мин белмәдем бит. Алайса, бүләк алырга онытма.

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

**Җиденче сорау. Контроль эш ничәнче дәрестә булачак?**

**Әминә**: Алмаз, гафу ит, икенче дәрестә химия булачакмы?

**Алмаз:** Юк, алгебра.

**Әминә:** Химия алгебрадан соң булачакмы?

**Алмаз:** Син химияне яратмый идең бит. Ни өчен шулкадәр аның булуын телисең?

**Әминә**: Химиядән бүген контроль эш була. Мин әзерләнеп өлгермәдем. Өченче дәрестә булса, тәнәфестә кабатлап чыгарга телим.

**Алмаз**: Алайса тизрәк кабатла. Химия алгебрага кадәр була бит.

**Әминә**: Шулаймыни? Рәхмәт!

**Алмаз**: Уңышлар телим!

**[2 секунд пауза]**

**Прослушайте диалог второй раз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]

**[2 секунд пауза]**

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста, а какие – не соответствуют. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**[пауза 20 секунд]**

**Сәлим**: Сәлам, Алсу!

**Алсу**: Исәнме, Сәлим!

**Сәлим**: Алсу, син тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, мәктәптә каласыңмы?

**Алсу:** Әйе, 10 нчы сыйныфта калырга телим. Безнең сыйныфыбыз бик дус бит. Сыйныфташларымнан аерыласым килми. Ә син нишләргә телисең?

**Сәлим**: Мин бокс белән шөгыльләнәм. Тренерым спорт мәктәбенә күчәргә тәкъдим итә. Мин уйлыйм әле. Сыйныфташлардан аерыласым килми, ләкин бокс та миңа бик ошый.

**Алсу:** Син төрле ярышларда да җиңүче булдың бит инде. Шулаймы?

**Сәлим:** Әйе, Алсу. Быел Россия күләмендәге турнирда беренче урын алдым, шәһәр һәм районда үткәрелгән ярышларда берничә тапкыр җиңдем.

**Алсу:** Афәрин! Әти-әниең нинди киңәш бирә соң? Алар да спорт мәктәбенә күчәргә кушамы яки үз мәктәбебездә калыргамы?
**Сәлим:** Алар үземә сайларга кушалар. Мәктәптә калсам, тренировка һәм ярышлар вакытында дәресләрне күп калдырырга туры киләчәк. Ә югары сыйныфларда уку программасы авыр. Ләкин минем дусларым белән бергә укыйсым килә.
**Алсу:** Син дусларың белән кичләрен һәм ял көннәрендә дә очраша аласың. Хәзер аралашу өчен Интернет, телефон да бар. Иң мөһиме - дөрес юл сайлау.
**Сәлим:** Рәхмәт, Алсу! Мин тагын уйлармын әле. Сайлау җиңел түгел икән.
**Алсу:** Әйе шул. Сау бул, Сәлим!
**Сәлим:** Сау бул, Алсу!
**[2 секунд пауза]**
**Прослушайте диалог второй раз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**У вас есть 6 минут, чтобы внести ответы в специальный бланк.**

## ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 | 17 | 2 |
| 2 | 3 | 18 | 3 |
| 3 | 2 | 19 | 2 |
| 4 | 3 | 20 | 1 |
| 5 | 1 | 21 | 2 |
| 6 | 2 | 22 | 3 |
| 7 | 1 | 23 | 2 |
| 8 | 1 | 24 | 2 |
| 9 | 2 | 25 | 3 |
| 10 | 2 | 26 | 1 |
| 11 | 1 | 27 | 3 |
| 12 | 2 | 28 | 2 |
| 13 | 1 | 29 | ТОРТПЕШЕРДЕМ |
| 14 | 3 | 30 | ЕРАКТҮГЕЛ |
| 15 | 2 | 31 | ШАЛТЫРАТЫП |
| 16 | 1 | 32 | ЙӨЗҮБЕЛӘН |

## 6 нчы вариант

## Раздел 1

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Бүләккә нәрсә алырга булганнар?**
1) чәчәк бәйләме
2) картина
3) фотолар өчен альбом

**2** **Азат ничәнче дәрескә соңга калган?**
1) дүртенче
2) өченче
3) икенче

**3** **Җиләккә ничә кеше барган?**
1) алты
2) дүрт
3) ике

**4** **Күзлек кайда калган?**
1) аш бүлмәсендә
2) кунак бүлмәсендә
3) йокы бүлмәсендә

**5** **Якшәмбе көнне нинди яңа фильм була?**
1) «Хайваннар дөньясында»
2) «Шаяннар клубы»
3) «Солдат анасы»

**6** **Алиянең пакеты нинди?**
1) Зәңгәр чәчәкле алсу пакет.
2) Кызыл чәчәкле зәңгәр пакет.
3) Кызыл чәчәкле алсу төстәге пакет.

**7** **Автобус сәгать ничәгә килә?**
1) көндезге унбергә
2) кичке алтыга
3) кичке унга

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Әминә автовокзалга ашыга.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Әминә өеннән ике сәгать алдан чыккан.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Туганнарының Казанга беренче тапкыр лилүләре.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Самат ярышка ашыга.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12**

Самат бокс белән шөгыльләнә.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Самат Мәскәгә ялга барырга җыена.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Волейбол белән шөгыльләнергә теләүчеләр игътибарына! Волейбол белән кызыксынсагыз, безнең спорт түгәрәгенә килегез. Монда сез файдалы ял итә аласыз! Спорт залында атнага ике тапкыр тренер белән шөгыльләнергә, командада уйнарга яки һәр көнне икешәр сәгать үзлектән шөгыльләнергә мөмкин. Спорт түгәрәге көндезге 10нан кичке 5кә кадәр түләүсез эшли. Кичке сәгатьләрдә шөгыльләнү түләүле. Түгәрәккә язылу 10нчы ноябрьгә кадәр дәвам итә. | **Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**<br>1) Волейбол белән түләүсез шөгыльләнергә чакыру турында.<br>2) Волейбол түгәрәгендә шөгыльләнү мөмкинлекләре турында.<br>3) Волейбол белән шөгыльләнү сәламәтлек өчен файдалы булу турында. |
| **15** | Укучылар!<br>Киләсе мәктәптә атнада “Уңыш бәйрәме” үткәрәчәкбез. Бәйрәмгә хезмәт ветераннары да чакырылган. Алар хөрмәтенә концерт куелачак. | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Мәктәптә узасы бәйрәм турында.<br>2) “Уңыш бәрәме”нә ветераннарны чакыру турында.<br>3) Бәйрәм концертына чыгышлар әзерләү турында. |

| |
|---|
| Концертта катнашырга теләүчеләрне 406 нчы бүлмәгә мөрәҗәгать итүләрен сорыйбыз. |

**16**

| |
|---|
| Асия, сәлам! Дәрес вакытында сине күрә алмадым, шуңа хат язам. Безне җыр конкурсына җибәрәләр. Конкурс Алабугада узачак. Конкурска иртәгә китәчәкбез. Кызганычка каршы, мин синең туган көнеңдә була алмыйм. Гафу ит, дустым! Ләкин конкурстан кайткач, без очрашырбыз. Бәйрәмең күңелле үтсен! Алия |

**Электрон хат аша Алиянең дустына нәрсә турында әйтәсе килгән?**

1) Конкурста катнашуы турында.
2) Дустының туган көнендә була алмаячагы турында .
3) Дустын туган көне белән котлавы турында турында.

| |
|---|
| ***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.*** |

Иртән урамда йөрергә чыгып барганда, күрше фатирга звонок биреп торучы әбине очраттым. Звонок төймәсе шактый биектә, әбинең буе кыска: ул, аяк очларына басып, өскә үрелгән. Әби, кулын звонок төймәсеннән алмыйча, миңа карап куйды. Йөзе борчулы, күз карашында нииндидер өметсезлек, аптырау сизелә иде. Әбигә күршеләремнең бер атна элек ялга чит шәһәргә китүләрен әйттем. Ул, куркып, ни әйтергә белми торды. Аның тәмам өметсезлеккә төшүен күреп, кызганып куйдым. «Бик кирәк идемени соң алар?» – дидем. Әби авыр сулады. «Кирәк иде шул, балам, бик кирәк иде. Өченче килүем инде. Мунчага барганда, акчамны онытып калдырып, Хәбирәдән 50 сум акча алып торган идем. Шуны бирәсем бар иде», – ди. «И әби, шул 50 сум артыннан йөрмәсәгез инде, – дим, – зур акча түгел ич!» Карчык миңа карап алды. Сүзләремне ошатмады. «Бурычның зурысы-кечкенәсе юк аның, балам. Олы кешегә андый бурыч белән яшәү дөрес түгел. Үлеп китсәм, өстемдә кала ич!» – диде. «Алайса, калдырыгыз миңа 50 сумыгызны, алар кайткач, кертеп бирермен», – дим. Әбиемнең йөзе балкып китте. Ул миңа, ашыгып, акчасын сузды. «И, балам, игелекле кеше икәнсең, рәхмәт яусын, тагын ничек килермен дип борчылган идем. Рәхмәт, балам!»

Әбинең өстеннән тау төштемени! Ул, ашыга-ашыга, ишектән чыгып китте. Буры чын биргән әбинең эчке бер нур белән балкыган йөзе күз алдымда озак торды. (Роза Хафизовадан)

**17** Күршеләргә әби ни өчен килгән?
1) Мунчага чакырыр өчен.
2) Мунчага бергә бару өчен.
3) Хәбирә ападан акча алып тору өчен.
4) Бурычын кайтару өчен.

**18** Күршеләр ни өчен ишекләрен ачмыйлар?
1) Алар урамда йөрергә киткәннәр.
2) Ял итәргә башка шәһәргә киткәннәр.
3) Туганнарына мунчага киткәннәр.
4) Алган бурычларын бирергә киткәннәр.

**19** Әби ни өчен борчыла?
1) Күршеләрнең ишекне ачмауларна.
2) Күршеләрнең өйдә булмауларнына.
3) Күрше хатынына бурычын тапшыра алмавына.
4) Күршеләренә күрә алмавына.

**20** Кыз әбигә ничек ярдәм итә?
1) Күршеләре турында мәгълүмат әйтә.
2) Үз өенә чакыра.
3) Бурычның зур булмавын әйтә.
4) Акчаны үзе тапшырачагын белдерә.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Урта мәктәпнең соңгы сыйныфларында (21) ..., мин буйга үсеп киттем. Шаярулардан да туктала башладым, тырышып укый башладым. Әнием мәктәптә җыештыручы булып эшли иде. Кичләрен, аңа ияреп, мин (22) ... спорт залына керәм. Волейболга да, баскетболга да, гимнастикага да сәләтем бар. Башкалардан хәтта уздырып та җибәрәм. Әни спорт костюмы да алды.

Бервакыт спорт (23) ... ябык гәүдәле, куе сары чәчле, зәңгәр күзле бер кыз күренә башлады. Ул (24)... мәктәптән иде. Кыз да физкультурага оста, җитез. Турникта миннән дә уздыра. Бу кыз (25) ... ошый иде. Көн дә, аны күрү өчен, спорт залына йөри башладым.

Менә инде чыгарылыш имтиханнарына да ерак калмады. Мин рәтләп әзерләнә дә алмыйм. Көндез шул Мөслимә, күзгә күренмичә, чебен (26).... бәйләнә. Дәрестә дә күлүен ишетәм кебек. Беркөнне, өйгә кайтканда, Мөслимәне очраттым. Ак алъяпкычтан, кечкенә портфель тоткан.

– Малик, син кайда югалдың? Нигә спорт залына килмисең? – диде.

Ул көнне кичне түземсезләнеп җиткердем, (27) .... спорт залына кермәдем. Куе агач башына менеп, спорт залы тәрәзәсеннән карап тора башладым. Анда спорт костюмыннан булган Мөслимә миңа бик матур һәм җитез булып күренде. Ул сәгатенә карый-карый уйнады, кемнедер көтә иде, ахры (мине көтүен башыма да китермәдем). Бераздан, сәгатенә карап алгач, залдан чыгып кайтып китте.

Мин (28)... артыннан бардым. Ул өенә кадәр ялгыз кайтты, ишегалдына да йөгерә-йөгерә керде, ләкин мине күрмәде. Мин читтән генә аны күзәтеп тордым.

(«Ялкын» журналыннан)

**21** 1) укып 2) укыганда 3) укыганчы 4) укыса

**22** 1) дә 2) да 3) та 4) та

**23** 1) залга 2) залда 3) залында 4) залыннан

**24** 1) төрле 2) башка 3) кебек 4) һәр

**25** 1) миңа 2) мине 3) миннән 4) миндә

**26** 1) турында 2) белән 3) кебек 4) өчен

**27** 1) яки 2) чөнки 3) әгәр 4) ләкин

**28** 1) минем 2) аның 3) синең 4) аларның

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кемнәрнең алтынчы дәресләре бар, алар очрашуда катнашмыйлар.

**Алтынчы дәресләре ... ... очрашуда катнашмыйлар.**

| | |
|---|---|
| **0** | **булган укучылар** |

**29** Яз җитте, шуңа күрә көннәр озынайды.

**... көннәр озынайды.**

**30** Дусларым кунакка килделәр, шуңа күрә мин бик шат.

**Дусларым кунакка ..., мин бик шат.**

**31** Дәресләр тәмамланды, без шул вакытта гына күрешә алдык.

**Дәресләр ... ... без күрешә алдык.**

**32** Көннәр җылынса да, төннәр салкын әле.

**Көннәр ... ..., төннәр салкын әле .**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*Үткән атнада мин дусларымда кунакта булдым. Без анда кызыклы китаплар турында сөйләштек, музыка тыңладык, мәктәп хәлләре турында әңгәмә кордык. Дустымның әнисе безне тәмле бәлеш белән сыйлады.*
*... Син кемнәргә кунакка йөрисең? Кунакта сез нишлисез? Гадәттә, кунаклар килгәч, син аларны нәрсә белән сыйлыйсың?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Бүләккә нәрсә алганнар?**
**Мәдинә**: Әнвәр, иртәгә Алинең туган көне. Без аңа нәрсә бүләк итәрбез икән?
**Әнвәр**: Минемчә, кызлар чәчәкләр яраталар. Чәчәкләр бүләк итәрбез.
**Мәдинә**: Әйе, чәчәкләр бүләк итәргә мөмкин, ләкин алар тиз шиңәләр. Башкалар да чәчәкләр бүләк итәрләр әле... Минем истәлекле бүләк бирәсем килә. Мәктәпне тәмамлагач та, безне хәтерләтә торганны.
**Әнвәр**: Алайса, фотоальбом, зонт яки картина бүләк итәргә мөмкин. Чыннан да истәлекле бүләк булачак.
**Мәдинә**: Килешәм. Безнең сыйныфыбыз белән төшкән фотоларыбыз бик күп. Аларны бергә туплап кую карау өчен уңайлы булачак. Ярый. Мин риза. Бүләкне сайладык!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Ике. Азат ничәнче дәрескә соңга калган?**

**Азат**: Исәнме, Сания! Син геометрия дәресендә булдыңмы?
**Сания**: Сәлам, Азат! Әйе, булдым. Ә сине мин күрмәдем.
**Азат:** Мин дәрестә юк идем. Без географиядән олимпиадага барырга әзерләндек. Икенче дәрес вакытында мин укытучым янында идем. Кичә футбол карарга бардым, соң кайттым, беренче дәрескә йоклап калганмын.
**Сания:** Син бу дәрескә дә соңга калып килдеңме?
**Азат:** Шулай. Сания, Әдәбият дүртенче дәрестә буламы?
**Сания:** Әйе. Хәзер башлана. Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Өч. Җиләккә ничә кеше барган?**
**Сания:** Алмаз, якшәмбе көнне киного бардыңмы?
**Алмаз**: Юк. Гаиләбез белән җиләккә бардык.
**Сания:** Кемнәр белән җиләк җыйдың?
**Алмаз:** Иртүк дустым Азат белән бакча янындагы урманга бардык. Безнең янга апа да килде. Ә сәгать сигез тулганда, сеңлем дә килеп җитте. Без 1 чиләк җиләк җыйдык. Бик күңелле булды!
**Сания:** Җиләкне нишләттегез?
**Алмаз:** Әнием кайнатма ясады, ә башта туйганчы ашадык.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Күзлек кайда калган?**
**Сания** Алмаз, дәү әти күзлеген эзли. Син күрмәдеңме? Мин аны алгы бүлмәдәге өстәлгә куйган идем, ләкин анда юк.
**Алмаз:** Кичә дәү әти аны аш бүлмәсендә журнал укып утыра идем. Салих абыйлар кунакка килгәч, газеталар белән бергә шунда калдыргандыр.
**Сания:** Иртән Асия өйне җыештырган.Ул газеталарны йокы бүлмәсендәге язу өстәленә керткәндер. Дәү этигә әйтим әле, күзлеге дә шунда булырга тиеш.
**Алмаз:** Ә журналда кызыклы нәрсә бар соң? Һәркем аны сорый.
**Сания:** Анда яңа роман басылган.Бик кызык диләр. Минем дә укыйсым килә, ләкин әлегә вакытым юк.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Якшәмбе көнне нинди яңа фильм була?**

**Шалтыратучы**: Исәнмесез! Гафу итегез, якшәмбе көнне кинотеатрда нинди яңа фильм була? Әйтә алмассызмы?
**Мәдинә**: Исәнмесез! Иртән балалар өчен “Хайваннар дөньясында”дигән мультфильм була. Төш вакытында үткән атнада күрсәткән “Викинг” фильмын карый аласыз. Аны яратып карыйлар. Без бу фильмны икенче атна күрсәтәбез инде. Сәгать икедә “Солдат анасы” фильмын карый аласыз. Без аны беренче тапкыр күрсәтәбез. Кичен “Шаяннар клубы” дигән комедия карый аласыз.
**Шалтыратучы**: Ул студентлар яшьләр турындамы?
**Мәдинә**: Әйе.
**Шалтыратучы**: Мин аны карадым инде. Бик кызык фильм. Дуслар белән рәхәтләнеп карадык.
**Мәдинә**: Сәгать икедәге фильмга билетлар бармы?
**Шалтыратучы**: Бар, ләкин күп калмады инде.
**Мәдинә**: Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Алиянең пакеты нинди?**
**Әнвәр:** Гафу итегез, Сез нәрсә югалттыгыз? Бәлки ярдәм итә алырмын.
**Мәдинә:** Мин түгел, кызым Алия югалткан. Спорт киемнәре салган пакетын кайдадыр калдырган. Ул зәңгәр чәчәкле алсу пакет. Эчендә кызыл төстәге спорт киемнәре, зәңгәр төстәге аяк киеме капчыгы да бар иде. Ул аны чишенү бүлмәсендә онытып калдырмадымы икән? Табылса, бик рәхмәтле булыр идек.
**Әнвәр:** Хәзер эзләп карыйбыз.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Автобус сәгать ничәгә килә?**
**Әнвәр**: Гафу итегез, сорарга мөмкинме?
**Мәдинә:** Әйе, рәхим итегез. Тыңлыйм Сезне.
**Әнвәр:** Актаныш автобусы сәгать ничәгә Казанга килеп җитә? Әйтә алмассызмы?
**Мәдинә: Бу** 5 сәгатьлек юл. Актаныштан Казанга берничә рейс бар. Иртәнге алтыда, сигездә, көндезге унбердә, бердә. Сезне кайсы рейс кызыксындыра соң?
**Әнвәр:** Иң соңгы рейс.
**Мәдинә:** Соңгы рейс сәгать кичке 5тә була.
**Әнвәр:** Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**

[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**
[пауза 20 секунд]
**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.

**Самат**: Сәлам, Әминә!
**Әминә**: Исәнме, Самат!
**Самат**: Болай иртә кая ашыгасың, Әминә?
**Әминә:** Автобус тукталышына. Вокзалга барам.
Са**мат**: Син кая китәсең? Ялгамы?
Әминә: Юк, беркая да китмим. Бүген безгә Түбән Новгородтан туганнарыбыз кунакка кайта. Шуларны каршы алырга барам. Аларның Казанда булганнары юк әле. Юлны белмиләр, шуңа күрә поезд килгәнче, вокзалга барып җитәргә кирәк. Самат: Поезд ничәдә килә?
**Әминә:** Сәгать сигездә.
**Самат:** Син бик иртә чыккансың. Поезд килгәнче ике сәгать вакыт бар бит әле. Син вокзалга ярты сәгатьтә барып җитәсең.
**Әминә:** Мин соңга калырмын дип курыктым. Ә син, Самат, кая җыендың?
**Самат:** Мин тренировкага барам. Бокс белән шөгыльләнүемне беләсең бит инде. Бүген кич ярыш була. Шуңа күрә иртән бераз шөгыльләнеп алырга теләдем.
**Әминә:** Ярышта син дә катнашасыңмы?
**Самат:** Юк, анда кече яшьтәге укучылар катнаша. Ярыш безнең залда уза. Кич шөгыльләнеп булмаячак.
**Әминә:** Ә син ярышларда катнашасыңмы?
**Самат:** Әйе, киләсе атнада Мәскәүгә китәм. Анда буласы ярышларга әзерләнәм. Әминә, әнә синең автобусың килде.
**Әминә:** Рәхмәт, Самат! Сиңа уңышлар телим! Сау бул!
**Самат:** Сез дә туганнарыгыз белән яхшы ял итегез. Сау бул, Әминә!
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

**ҖАВАПЛАР**

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 17 | 4 |
| 2 | 2 | 18 | 2 |
| 3 | 2 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 4 |
| 5 | 3 | 21 | 2 |
| 6 | 1 | 22 | 1 |
| 7 | 3 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 2 |
| 9 | 1 | 25 | 1 |
| 10 | 1 | 26 | 3 |
| 11 | 2 | 27 | 4 |
| 12 | 1 | 28 | 2 |
| 13 | 2 | 29 | язҗиткәнгә |
| 14 | 2 | 30 | килгәнгә |
| 15 | 3 | 31 | тәмамлангачкына |
| 16 | 2 | 32 | җылынугакарамастан |

**7 нче вариант**

**Раздел 1**

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Ничәнче автобус кирәк?**
1) 2нче
2) 10нчы
3) 35нче

**2** **Зонт кайда калган?**
1) метрода
2) мәктәптә
3) автобус тукталышында

**3** **Нинди дәфтәр кирәк?**
1) юка тышлы, 48 битле
2) рәсемсез, калын тышлы
3) рәсемле, юка тышлы , 18 битле

**4** **Яңа газеталарны кайда укырга мөмкин?**
1) уку залында
2) өйдә
3) элмә тактада

**5** **Алия ничәнче дәрескә килгән?**
1) 2
2) 3
3) 4

**6** **Кунакка ничә кеше барган?**
1) 3
2) 4
3) 5

**7** **Автобус сәгать ничәгә килә?**
1) көндезге унбергә
2) кичке алтыга
3) кичке җидегә

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Әнисә мәктәп китапханәсенә килгән.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Әнисә уку залында китап укый.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Илдарга реферат язарга материаллар кирәк.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Илдар астрономиядән реферат әзерли.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Илдар журналлар укый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Әнисәгә китапханәче “Ак чәчәкләр” китабын биргән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Баскетбол белән шөгыльләнергә теләүчеләр игътибарына! Баскетбол белән кызыксынсагыз, безнең спорт секциясенә килегез. Монда сез файдалы ял итә аласыз! Спорт залында атнага өч тапкыр тренер белән шөгыльләнергә, командада уйнарга яки һәр көнне икешәр сәгать үзлектән шөгыльләнергә мөмкин. Спорт секциясе дүшәмбе һәм җомга көннәрдә сәгать биштән җидегә кадәр эшли. Шөгыльләнү түләүсез. Секциягә язылу 6 нчы сентябрьгә кадәр дәвам итә. | **Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**<br>1) Спорт белән кызыксынучылар өчен яңалыклар турында.<br>2) Баскетбол секциясендә шөгыльләнү мөмкинлекләре турында.<br>3) Баскетболның сәламәтлеккә файдасы турында. |
| **15** | Укучылар!<br>Киләсе мәктәптә атнада “Көзге бал” үткәрәчәкбез. Бәйрәмгә югары сыйныф укучылары чакырылган. Программада концерт та булачак. Концертта катнашырга теләүчеләрне | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Мәктәптә узасы бәйрәм турында.<br>2) “Көзге бал”га югары сыйныф укучылары чакырылу турында.<br>3) Концерт номерлары әзерләү турында. |

дүшәмбе көнне 6 нчы бүлмәгә мөрәҗәгать итүләрен сорыйбыз.

**16**

| | |
|---|---|
| Асия, сәлам! Бүген мәктәптә вакытта әйтергә онытканмын, шуңа хат язам. Иртәгә гаиләбез белән Мәскәүгә китәбез. Кызганычка каршы, мин синең туган көнеңдә була алмыйм. Алдан ук бәйрәмең белән тәбрик итәм. Мәскәүдән кайткач, без очрашырбыз. Бәйрәмең күңелле үтсен! Алия | **Электрон хат аша Алиянең дустына нәрсә турында әйтәсе килгән?**<br>1) Мәскәүдә булачагы турында.<br>2) Дустының туган көнендә була алмаячагы турында.<br>3) Туган көне белән котлавы турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Кечкенә Миләш үзен ялгыз дип тойды. “Минем яныма беркем дә килми”, - дип уйлады ул. Күңелсезләнеп, хәтта елап та җибәрде.

Сары күбәләк аның елавын ишетте дә:

- Ник елыйсың, Миләш? – дип сорады.

Миләш аңа:

- Мин ялгыз, минем яныма беркем дә килми...- диде. Үзе һаман елый иде.

– И елак, син бит әле кечкенә, синең чәчәгең дә юк, - диде Күбәләк. Ул чәчәктән-чәчәккә кенә кунып йөри иде. Миләшнең җавабын да көтмичә очып китте.

Күбәләкнең сүзенә Миләшнең хәтере калды. Ул үпкәләде. Миләш тагын да ныграк үкси башлады. Елаган тавышы бик еракка ук ишетелә иде.

Шулчак кайдандыр Сыерчык килеп чыкты.

-Ник елыйсың, Миләш? – дип сорады. Аның тавышы бик ягымлы иде.

- Мин ялгыз, минем яныма беркем дә килми, - диде Миләш.

– Син кечкенә бит әле, сине борчырга ярамый, - диде Сыерчык. Ул Миләшне юатырга теләде.

- Синең әле ботакларың да аз, кошларга кунарга урын да юк. Зур үскәч, сиңа күбәләкләр дә, кошлар да килер. Син безне кызыл җимешләрең белән сыйларсың. Елама, шат күңелле бул! Озакламый син дә зур үсәрсең!- диде Сыерчык.

Миләшнең күңеле күтәрелде. Ел елаудан туктады. Елмаеп җибәрде. Бу вакытта көн кояшлырак, һава җылырак булып тоелды. Тирә-якта агачлар, кошлар һәм күбәләкләр барлыгы да күренде. ( Гыйльмия Таһировадан)

**17** Миләш ни өчен елаган?
1) Күңелсез булганга.
2) Салкын булганга.
3) Кечкенә булганга.
4) Ялгыз булганга.

**18** Миләшнең күбәләккә нигә хәтере калган?
1) Җавап көтмичә очып киткәнгә.
2) Чәчәгең дә юк дигәнгә.
3) Дуслашмаганга.
4) Еларга комачаулаганга.

**19** Сыерчык нишләгән?
1) Миләш яныннан очып киткән.
2) Миләшне үртәгән.
3) Миләшкә кошлар килмәүнең сәбәбен аңлаткан.
4) Миләшне елаткан.

**20** Миләшнең күңеле кайчан күтәрелгән?
1) Кояш чыккач.
2) Сыерчык очып килгәч.
3) Күбәләкләрне күргәч.
4) Елаудан туктагач.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Кайбер елны елгаларда боз бик иртә 21) ... башлый. Апрель башларында 22) .... Ә кайбер язны апрель ахырына да боз кузгалмый.  Ул боз җибәрүче Чәберчек дигән кошның кайтуын көтеп ята икән. Бу кошның исеме русча трясогузка була. Боз  23)...  аның эше икән.

Иртәме, соңмы, яз кайчан килсә, шул вакытта, Чәберчек  җылы яктан кайта икән. Кайту 24) ..., ул боз өстенә куңа, ди.  Үзе бик кечкенә, учка сыеп бетәрлек кенә.  25) ... ул сыгылмалы тәпиләре белән бозда сикереп йөри. Шулай бозның калынмы, нечкәме икәнен үлчи икән.  Йөргәндә, аның сиртмә 26) ... озын койрыгы бозга тияр-тимәс кенә селкенеп тора.  Бозның калынлыгын белгәч, алга сикереп куна. Койрыгы белән бозга суга, 27) ... боз шартлап ярыла. Тагын суга – тагын ярыла.  Өченче сугуда боз бөтенләй кузгалып та китә, ди.

Шуңа күрә Чәберчек үзе дә мактана:
- 28)... кечкенә булсам да, койрыгым алтмыш пот!- ди икән.
Булырга мөмкин. Шундый зур елгаларның калын бозларын сугып яргач, авырлыгы зурдыр шул. ( Легендадан)

**21** 1) китеп 2) китә 3) киткәч 4) китсә

**22** 1) ук 2) соң 3) үк 4) кадәр

**23** 1) җибәрергә 2) җибәрә 3) җибәрү 4) җибәрәчәк

**24** 1)өчен 2) белән 3) кебек 4) саен

**25** 1) башта 2) башка 3) башында 4) башы

**26** 1) турында 2) белән 3) кебек 4) өчен

**27** 1) чөнки 2) яки 3) әгәр 4) ә

**28** 1) үзе 2) үзем 3) үзең 4) үзенең

**Раздел 4**

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кемнәрнең алтынчы дәресләре бар, алар очрашуда катнашмыйлар.
**Алтынчы дәресләре ... ... очрашуда катнашмыйлар.**

| | |
|---|---|
| **0** | **булган укучылар** |

**29** Укулар башланса да, тренировкаларны туктатмадык.
**Укулар ...** тренировкаларыбыз дәвам итте.

**30** Туганнарыбыз кунакка килделәр, шуңа күрә без бик шат.
**Туганнарыбыз кунакка ..., без бик шат.**

Каникуллар тәмамланды, без шул вакытта гына күрешә алдык.
**31** **Каникуллар ... ... без күрешә алдык.**

**32** Имтиханарга әзерләнәбез, шуңа күрә вакытыбыз аз.
**Имтиханнарга ..., вакытыбыз аз .**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Җәен мин Кара диңгездә ял итәргә телим. Безнең диңгез буенда гаиләбез белән ял иткәнебез бар инде. Быел да диңгездә су коеныргa, диңгез ярлары буенча сәяхәт итәргә, истәлекле урыннарны карарга телибез. Безгә сәяхәт һәм ял итү бик ошый!*

*... Ә синең җәйге ялга планнарың нинди? Син нишләргә яратасың? Гаиләгез белән сез ничек ял итәсез?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Ничәнче автобус кирәк?**
А: Гафу итегез, бу автобус “Университет” тукталышына кадәр барамы?
Ә: Юк, бармый.
А: Әйтегезче, ә ничәнче автобус бара? Белмисезме?
Ә: Утыз бишенче, утызынчы автобуслар.
А: Рәхмәт Сезгә.
Ә: Исән-сау булыгыз.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Ике. Зонт кайда калган?**
А: Сәлам, дустым!
Ә: Сәлам!
А: Син бүген зонт алмадыңмыни? Яңгыр ява бит.
Ә: Әйе, шул, зонтны мәктәптә онытканмын.
А: Әйдә, бергә барабыз. Син автобус тукталышына барасыңмы?
Ә: Зур рәхмәт! Метрога барам.
А: Яхшы, мин дә шул якка барам.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Өч. Нинди дәфтәр кирәк?**
А: Хәерле көн! Миңа ике шакмаклы дәфтәр бирегезче.
Ә: Ничә битле дәфтәр кирәк: унике битлеме яки унсигезме?
А: Калын тышлы 48 битле дәфтәрләр кирәк.
Ә: Рәхим итегез! Бездә рәсемле тышлылары да, рәсемсезләре дә бар. Кайсын бирим?

А: Рәсемсез тышлы ике дәфтәр бирегез.
Ә: Яхшы. Сезгә илле сум түләргә кирәк булачак.
А: Ярый. Ләкин миңа ике бетергеч белән ике линейка да кирәк әле.
Ә: Бетергеч һәм линейкалар менә монда күрсәтелгән. Сайлагыз.
А: Яхшы. Хәзер.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Яңа газеталарны кайда укырга мөмкин?**
А: Гафу итегез, миңа "Идел" журналының соңгы номеры кирәк иде. Сездә бармы?
Ә: Әйе, бар. Сезгә татар телендәге басма кирәкме?
А: Әйе. Сез аны өйгә бирәсезме?
Ә: Юк, газета һәм журналларны бары уку залында гына укырга мөмкин.
А: Кызганыч.
Ә: Әйе. Укучы билетыгызны бирегезче. Хәзер журналны алып киләм.
А: Рәхим итегез!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Алия ничәнче дәрескә килгән?Яңа газеталарны кайда укырга мөмкин?**
**А**: Исәнме, Самат! Син геометрия дәресендә булдыңмы?
**С**: Сәлам, Алия! Әйе, булдым. Ә сине мин күрмәдем.
**А:** Мин дәрестә юк идем. Сеңлем авырып китте. Әнием өйгә кайтканчы, аның янында булдым. Анан табип киде һәм даруханәдән дарулар алып кайтырга кушты.
**С:** Син бу дәрескә өлгердеңме соң?
**А:** Юк шул, Самат.Әдәбият дүртенче дәрестә буламы?
**С:** Әйе. Хәзер башлана. Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Кунакка ничә кеше барган?**
**С:** Алмаз, якшәмбе көнне киногa бардыңмы?
**А**: Юк. Без кунакка бардык.
**С:** Кемнәр белән бардың?
**А:** Иртүк дустым Азат килде дә, Айратларга киттек. Безне Сәлим кунакка чакырды. Без, Айдарны да алып, аларга киттек. Вакытны бик күңелле үткәрдек!

**С:** Нишләдегез?
**А:** Сөйләшеп утырдык, музыка тыңладык, өстәл уеннары уйнадык.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Автобус сәгать ничәгә киләэ?**
**Ә**: Гафу итегез, сорарга мөмкинме?
**М:** Әйе, рәхим итегез. Тыңлыйм Сезне.
**Ә:** Азнакай автобусы сәгать ничәгә Казанга килеп җитә? Әйтә алмассызмы?
**М:** Бу 5-6 сәгатьлек юл. Азнакайдан Казанга берничә рейс бар. Иртәнге алтыда, сигездә, көндезге унбердә, бердә. Сезне кайсы рейс кызыксындыра соң?
**Ә:** Иң соңгы рейс.
**М:** Соңгы рейс сәгать кичке 7тә була.
**Ә:** Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**
[пауза 20 секунд]
**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.

Әнисә: Сәлам, Илдар!
Илдар: Исәнме, Әнисә!
Әнисә: Син дә китапханәгә килдеңмени?
Илдар: Әйе, географиядән реферат язасым бар. “Вокруг света” журналындагы яңа мәкаләләр белән танышырга телим. Анда кызыклы мәгълүматлар турында язалар.
Әнисә: Бу журналны китапханәнең ничәнче залында укырга мөмкин соң?
Илдар: Өченче залда. География, геология, астрономия һәм физикага караган китаплар, журналлар барысы да өченче залга тупланган.
Әнисә: Син ни өчен шәһәр китапханәсенә килдең? “Вокруг света” журналы мәктәп китапханәсендә юкмы?
Илдар: Бар. Ләкин мәктәп китапханәсе шимбә көнне сәгать дүрткә кадәр генә эшли бит. Ә журналларны өйгә бирмиләр, уку залында гына укырга мөмкин.
Әнисә: Әйе, шул. Бөтенләй онытканмын.
Илдар: Әнисә, ә син китапханәгә ни өчен килдең? Син дә реферат язасыңмы әллә?

Әнисә: Юк, реферат язмыйм. Телевизордан Габдрахман Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” әсәре буенча төшерелгән фильмның рекламасын караган идем. Китапны укыйсым киде. Шул китапны алырга телим.
Илдар: Әйе, рекламаны мин дә күрдем. Тиздән бу фильмның премьерасы булачак. Әбием дә бу әсәр турында әйткән иде.
Әнисә: Әйе, миңа да әбием бу әсәрне укырга киңәш итте. Ләкин китапханәдә бу китап калмаган, барысы да кулда дип әйттеләр.
Илдар: Кызганыч! Әнисә, “ Ак чәчәкләр” китабы бездә бар. Теләсәң, мин сиңа биреп тора алам.
Әнисә: Бик телим, Илдар!
Илдар: Ярый, кич, китапханәдән кайткач, мин сезгә китапны кертеп чыгармын. Син өйдә булачаксыңмы?
Әнисә: Әйе, өйдә булам. Бик зур рәхмәт сиңа!
Илдар: Яхшы. Килер алдыннан, мин сиңа шалтыратырмын.
Әнисә: Мин көтәм.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

## ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 17 | 4 |
| 2 | 2 | 18 | 2 |
| 3 | 2 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 4 |
| 5 | 3 | 21 | 2 |
| 6 | 1 | 22 | 1 |
| 7 | 3 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 2 |
| 9 | 1 | 25 | 1 |
| 10 | 1 | 26 | 3 |
| 11 | 2 | 27 | 4 |
| 12 | 1 | 28 | 2 |
| 13 | 2 | 29 | язҗиткәнгә |
| 14 | 2 | 30 | килгәнгә |
| 15 | 3 | 31 | тәмамлангачкына |
| 16 | 2 | 32 | җылынугакарамастан |

**8 нче вариант**

**Раздел 1**

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Ничәнче автобус кирәк?**
1) 12
2) 10
3) 63

**2** **Директор ни өчен кирәк?**
**1)** гариза язу өчен
2) интервью алу өчен
3) мәкалә яздыру өчен

**3** **Урыннар кайда булган?**
1)партерда
2) балконда
3) фойеда

**4** **Поезд кайчан киләчәк?**
1) 5 минуттан
2) 10 минуттан
3) ярты сәгатьтән

**5** **Кая барырга әзерләнәләр?**
1) кибеткә
2) чит илгә
3) авылга

**6** **Ничә карандаш кирәк?**
1) 4
2) 3
3) 5

**7** **Журналның ничәнче саны басылган?**
1) 12
2) 8
3) 9

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Алия авылдан кайтып килә.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Алия чөгендер, кишер алган.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Алиягә бакчада эшләү бик ошый.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Илнур дәү әнисенә булышкан.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12**

Илнур каен гөмбәләре җыйган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Алия вакытын дуслары белән үткәргән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Бию белән шөгыльләнергә теләүчеләр игътибарына! Бию белән кызыксынсагыз, безнең түгәрәккә килегез. Монда сез күңелле һәм файдалы ял итә аласыз! Бию залында атнага өч тапкыр бию белән шөгыльләнергә, эстрада һәм халык биюләрен өйрәнергә була. Түгәрәк һәр дүшәмбе һәм җомга көннәрдә иртәнге 10нан кичке җидегә кадәр эшли. Шөгыльләнү түләүле. Бию түгәрәгенә язылу 10 нчы сентябрьгә кадәр дәвам итә. | **Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**<br>1) Бию кызыксынучылар өчен яңалыклар турында.<br>2) Бию түгәрәгенә язылу мөмкинлеге турында.<br>3) Бию түгәрәгенең түләүле булуы турында. |
| **15** | Укучылар!<br>Киләсе мәктәптә атнада макулатура җыю буенча сыйныфлар арасында бәйге оештырылачак. Макулатураны дүшәмбе һәм сишәмбе көннәрендә тапшырырга мөмкин. Иң күп кәгазь җыйган | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Укучыларның агачларны саклап калуга өлеш кертүе турында.<br>2) Җиңүчеләргә биреләсе бүләк турында.<br>3) Кәгазь җыю буенча бәйге игълан ителү турында. |

сыйныфны истәлекле бүләк көтә! Агачларны саклап калу һәм яшеллекне арттыруга һәркем үзеннән өлеш кертсен!

**16**

Алмаз, сәлам! Бүген мәктәптә вакытта әйтергә онытканмын, шуңа хат язам. Иртәгә сәгать кичке алтыда ишек алдында футбол ярышы була. Син безнең командада уйнарсың дип өметләнәбез. Килерсең бит? Син – иң яхшы капкачы. Ярышта җиңәргә телибез. Бүләкләр дә булачак.

Азат

**Электрон хат аша Азатның дустына нәрсә турында әйтәсе килгән?**

1) Футбол ярышы турында.
2) Дустын футбол уйнарга чакыруы турында.
3) Ярышта җиңәргә теләве турында.

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Апам шәһәрдә яши. Әни әйтә, анда өйләр шундый зур, кемнәр яшәгәнен дә белеп бетереп булмый, ди. Ничек инде ул үзең яшәгән өйдә кем торганын белмисең, ди? Моны Диләрәгә сөйләсәң, ул ышанмас. Чынлап та, менә безнең өйдә куяннарны, песине санамасаң, әти, әни, абый, мин, сеңлем Әлфия бар. Мин өйдәге кешеләрне генә түгел, авылдагы барлык кешеләрне беләм. Авылда җиде Наил бар. Мин аларның барысын да беләм.

Кемдер кереп килә, дип, тәрәзәгә карасам, урам кар белән тулган.

- Әни, әни, кар ява бит. Ник әйтмисең? – дип, эленеп торган киемнәрем янына килдем.

Беренче кар! Ур-ра! Әллә кайчан әзерләп куйган чанамны алдым да Диләрәләргә йөгердем.

– Диләрә, чык, кар ява! Диләрә, дим, чык инде, кар ява бит.

Диләрә чыкты.

- Нигә шулхәтле кычкырасың?

- Кар яуганны күрми каласың бит!

- Нәрсә дисең?

- Һи, мактанчык! – дидем мин, аның янына килеп. –Яңа чанасы бар икән. Ишетмәгән була. Быелтыр минем чанам да яңа иде, шуа-шуа искерде.

- Ә минеке өр-яңа.

- Булса ни! Ярый, алайса. Шул чанаңа карап тор!- дидем дә тауга йөгердем.

- Тукта! Мин дә барам! - дип, Диләрә дә минем арттан килде.

Без килгәндә, абыйлар, зур итеп, кар бабай ясаганнар. Борынына кызыл кишер, күзләренә кара күмер куйганнар.

- Әйдә, без дә үзебезнең кар бабайны ясыйбыз!

Кулларыбыз туңса да, зур кар бабай янына кечкенә кар бабайлар ясап куйдык. Алар шулхәтле кечкенә булдылар, без аларга “кар малайлар” дип исем куштык.

– Малайлар, әйдәгез, коега кар тутырабыз, – диде Мансур.

Безгә кызык. Карның коега төшкәнен карыйсыбыз килә. Абыйлар безне коега якын җибәрмиләр. Мансурларның коесы тирән, ләкин анда су юк. Өч малай тәгәрәткән карны коега салдылар. Ләкин ул төшмәде, кысылып калды.

Мансур аны этә башлады. Кар белән үзе дә коега төшеп китте. Без ярдәмгә олыларны чакырдык. Кое янына кешеләр җыелдылар. Мансурны әтисе озын бау белән тартып алды. (Н.Кәримовадан)

**17** Кыз ниләр белә?
1) Шәһәр йортларындагы кешеләрне.
2) Диләрәнең ышанмавын.
3) Йортларның зурлыгын.
4) Авылдагы һәр кешене.

**18** Кыз нәрсәгә шатланган?
1) Яңа чанага.
2) Кар яуганга.
3) Дус кызын урамга чакыруга.
4) Чана шууга.

**19** Зур малайлар нишләгәннәр?
1) Чана шуганнар.
2) Кечкенәләрдән коега кар ташытканнар.
3) Кар бабай ясаганнар.
4) Кар малайлар ясаганнар.

**20** Мансур нишләгән?
1) Коедан су алган.
2) Озын бау тартып чыгарган.
3) Кысылып калган.
4) Коега төшеп киткән.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Казанның зур тарихы бар. Казан шәһәре 1445 нче елда Казан ханлыгының үзәгенә 21) .... Ул вакытта Казан Көнбатышның һәм Көнчыгышның зур дәүләтләре, шәһәрләре белән элемтәдә торган. Шәһәрнең таш сарайлары, мәчет манаралары, шәһәр ныгытмалары, имән капкалары белән ерактан 22) ... күренеп торган.

Россия империясе составына 23) ..., Казан зур бер губернаның башкаласы була. Анда бик күп вакыйгалар була. Әллә ничә тапкыр янгын чыга, шәһәрнең яртысы янып бетә, 24) ... яңадан төзелә...

1804 нче елда Казан университеты ачыла. төзелгән Ул шәһәрнең 25) ... бик күтәрә. Анда математика, химия, тарихны өйрәнү фәннәре буенча бөек ачышлар ясала. Н. Лобачевский, Н. Зинин, А. Бутлеров, К. Фукс, Хәлфиннәр, А. Казем-Бек һәм Ш. Мәрҗаниләрнең фәнгә керткән зур өлешләре - Казан шәһәренең горурлыгы.

Шәһәр күп данлы исемнәр 26) ... бәйләнгән. Шәһәр янына Емельян Пугачев гаскәрләре килә. Аның турында А. С. Пушкин язган. Яшь граф Лев Толстой университетта 27) ..., бөек рус язучысы М. Горький үз әсәрен бу шәһәрдә язган. Г. Державин һәм Ф. Шаляпин, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов та төрле вакытларда бу 28) ... яшәгәннәр ...

«И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!» Бу сүзләрне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай әйткән (Р. Фәхретдиновтан).

**21** 1) әверелеп 2) әверелә 3) әверелсә 4) әвереләчәк

**22** 1) ук 2) соң 3) үк 4) кадәр

**23** 1)керү 2) кергән 3) кергәч 4) керәчәк

**24** 1)ә 2) ләкин 3) кебек 4) саен

**25** 1) данын 2) даны 3) данына 4) данының

**26** 1) турында 2) кебек 3) белән 4) өчен

**27** 1) яшәгән 2) эшләгән 3) торган 4) укыган

**28** 1) шәһәрендә ) шәһәрдә 3) шәһәр 4) шәһәргә

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кемнәрнең алтынчы дәресләре бар, алар очрашуда катнашмыйлар.
**Алтынчы дәресләре ... ... очрашуда катнашмыйлар.**

| | |
|---|---|
| **0** | **булган укучылар** |

**29** Укулар башланса да, очрашулар кимемәде.
**Укулар ... очрашуларыбуз кимемәде**.

**30** Чит илгә ял итәргә бардык, шуңа күрә без бик шат.
**Чит илгә ял итәргә..., без бик шат.**

**31** Дәресләр тәмамланды, без шул вакытта бию түгәрәгенә киттек.
**Дәресләр ... ... без бию түгәрәгенә киттек.**

**32** Имтиханарны уңышлы тапшырдык, шуңа күрә сөенечебез зур.
**Имтиханнарны уңышлы ..., сөенечебез зур.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

... Ял көннәрендә мин бию белән шөгыльләнәм. Ике ел инде “Айгөл” бию түгәрәгенә йөрим. Анда миңа бик ошый. Без төрле конкурсларда, концертларда да катнашабыз.

... Ә син нәрсә белән кызыксынасың?Буш вакытыңда нәрсә белән шөгыльләнәсең? Нинди чараларда катнашасың?

### Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Ничәнче автобус кирәк?**
А: Гафу итегез, әйтегезче, “Камал театры” тукталышына ничәнче троллейбус бара?
Ә: Минемчә 12нче троллейбус.

А: Ә ничәнче трамвай белән барып була?
Ә: Гафу итегез, анда трамвайлар йөрми. Автобуста барып була. 63нче, 30нчы автобуска утырыгыз.
А: Рәхмәт Сезгә.
Ә: Исән-сау булыгыз.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Ике.Директор ни өчен кирәк булган?**

А: Исәнмесез! Мин директорга килдем.
Ә: Исәнмесез! Сез алдан язылдыгызмы?
А: Әйе. Уникенче яртыга. Хәзер уникенче ярты. Керергә мөмкинме?
Ә: Гафу итегез, әз генә көтегез. Менә монда утырып торыгыз. Мин хәзер Галина ханымга әйтәм. Сез нинди мәсьәлә буенча килдегез?
А: Яхшы.Мин - журналист. Редакциядән сезнең оешма турында мәкалә әзерләү өчен җибәрделәр. Озак көтәргә кирәк булачакмы?
Ә: Минемчә, юк. Хәзер керерсез.
А: Яхшы, рәхмәт.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Өч. Урыннары кайда булган?**
А: Хәерле көн! Миңа бүгенге спектакльгә ике билет кирәк иде.
Ә: Исәнмесез! Бүгенгә билетлар аз калды. Хәзер тәкъдим итеп карыйм.
А: Партерга билетлар бармы?
Ә: Әйе, өч билет бар, ләкин урыннар янәшә түгел. 10нчы, 12нче, 14нче рәтләрдә берәр урын бар.
А: Гафу итегез, безгә янәшә ике урын кирәк иде. Андый урыннар юкмы?
Ә: Балконда икенче рәттә бар. Аласызмы?
А: Әйе, алам. Бүгенге спектакльне карыйсыбыз килә.
Ә: Яхшы. Балконда икенче рәттә унынчы, унберенче урыннар. Рәхим итегез.
А: Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Поезд килергә ничә минут калган?**
А: Гафу итегез, Казан- Мәскәү поезды ничәнче платформада туктый?

Ә: Икенчедә.
А: Ул кайчан киләчәк?
Ә: Биш минуттан.
А: Озак торачакмы?
Ә:  Ун минут.
А: Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш.  Алар кая барырга әзерләнәләр?**
А: Сәлам, дустым!
Ә: Сәлам!
А: Син бүген бик иртә торгансың, кая барырга җыендың?
Ә: Әйе, шул, бүген апам белән авылга китәбез. Дәү әнигә күчтәнәч алырга кибеткә килдем.
А: Бик яхшы! Сез ял көннәренә генә кайтасызмы яки каникулларгамы?
Ә: Бер атна торырга телибез. Дәү әнине, авылны бик сагындык.
А: Яхшы яллар сезгә! Сәлимә апага сәлам әйтегез!
Ә: Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Ничә карандаш кирәк кирәк?**
А: Хәерле көн! Миңа ике шакмаклы дәфтәр һәм карандашлар бирегезче.
Ә: Сезгә нинди дәфтәр һәм нинди карандашлар кирәк?
А: Калын тышлы 48 битле шакмак дәфтәр кирәк. Дустыма, сеңлемә һәм үземә бик яхшы  карандашлар кирәк.
Ә: Рәхим итегез! Бездә карандашлар күп. Сезгә төсле карандашлар кирәкме?
А: Юк, гадәти карандашлар.
Ә: Яхшы. Менә болары бик уңайлы һәм арзан.
А: Ярый, рәхмәт! Алайса, һәркемгә берәр карандаш алыйм, этиемә дә кирәк булыр.
Ә: Яхшы. Хәзер бирәм.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Журналның ничәнче саны басылган?**
А: Гафу итегез, миңа  “Идел” журналының соңгы саны кирәк иде. Сездә бармы?

Ә: Әйе, бездә 8нче саны бар. Сезгә татар телендәге басма кирәкме?
А: Әйе, мин татарча укыйм. Ләкин журналның 9нчы саны да сатуда бар дип ишеттем. Сездә юкмы?
Ә: Юк, әлегә 8нче сан гына бар. Аны уку залында укырга мөмкин.
А: Кызганыч. Мин ул санны укыдым инде.
Ә: Ярый, бераз соңрак килерсез. Тиздән яңа сан да килеп җитәр.
А: Рәхим итегез!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**
[пауза 20 секунд]
**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.

Алия: Сәлам, Илнур!
Илнур: Исәнме, Алия!
Алия: Илнур, син бакчадан кайтып киләсеңме?
Илнур: Әйе, Алия, бакчадан кайтам. Дәү әнигә булышырга бардым.
Алия: Анда нишләдегез?
Илнур: Көзен бакчада уңыш җыялар инде. Без дә кишер, чөгендер алдык. Алма җыйдык.
Алия: Бакчада рәхәтме?
Илнур: Әйе, бик рәхәт! Мин саф һавада эшләргә бик яратам. Бүген матур көн иде. Кояшлы, җылы һәм бераз җиләс.
Алия: Ә кәрҗинеңдә ниләр бар?
Илнур: Гөмбәләр. Бакчабыз янында кечкенә генә урман бар. Шуннан җыйдым.
Алия: Урманда гөмбә күпме?
Илнур: Гөмбәләр бар, ләкин җыярга вакытым аз булды. Дәү әниемә булышырга кирәк иде. Киләсе атнада гөмбә җыярга махсус барырмын әле. Алия, синең кәрҗиндә дә гөмбәләр бар бит!
Алия: Әйе, без дустым белән бүген гөмбә җыярга бардык.

Илнур: Кая бардыгыз?
Алия: Шәһәр янындагы посадкага.
Илнур: Нинди гөмбәләр җыйдыгыз?
Алия: Анда ак гөмбә, каен гөмбәсе һәм сары гөмбә генә үсә.
Илнур: Сез күп җыйгансыз. Озак йөрдегезме?
Алия: 4 сәгать йөрдек.
Илнур: Алия, әйдә, икенче атнада гөмбәгәикебез бергә барабыз. Алай күңелле дә булыр.

Алия: Ярар, мин риза!

**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

## ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 17 | 4 |
| 2 | 2 | 18 | 2 |
| 3 | 2 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 4 |
| 5 | 3 | 21 | 2 |
| 6 | 1 | 22 | 1 |
| 7 | 3 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 2 |
| 9 | 1 | 25 | 1 |
| 10 | 1 | 26 | 3 |
| 11 | 2 | 27 | 4 |
| 12 | 1 | 28 | 2 |
| 13 | 2 | 29 | башланугакарамастан |
| 14 | 2 | 30 | барганга/ баруыбызга |
| 15 | 3 | 31 | тәмамлангачкына |
| 16 | 2 | 32 | тапшырганга |

**9 нчы вариант**

**Раздел 1**

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Ничәнче автобус кирәк?**
1) 12
2) 10
3) 63

**2** **Очрашуга кем килгән?**
**1)** укытучы
2) журналист
3) хезмәткәр

**3** **Янәшә урыннар кайда калган?**
1) партерда
2) балконда
3) фойеда

**4** **Чаңгы батинкалары кайда сатыла?**
1) беренче катта
2) өченче катта
3) икенче катта

**5** **Поезд кайчан киләчәк?**
1) 15 минуттан
2) 20 минуттан
3) 30 минуттан

**6** **Билетлар ничәнче рәткә алынган?**
1) 18
2) 16
3) 14

**7** **Ялны кайда үткәргәннәр?**
1) урманда
2) елгада
3) бакчада

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Миләүшә түгәрәккә бара.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Миләүшә фигуралы шуу белән шөгыльләнә.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Миләүшә төрле ярышларда катнаша.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Сәлим компьютер уеннары уйнарга ярата.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Сәлим былтыр призлы урын алган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Сәлим спорт белән шөгылҗләнергә җыена.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Вокал белән шөгыльләнергә теләүчеләр игътибарына!Җыр сәнгате белән кызыксынсагыз, безнең түгәрәккә килегез. Монда сез күңелле һәм файдалы ял итә аласыз! Концерт залында атнага ике тапкыр вокал белән шөгыльләнергә, эстрада һәм халык җырларын өйрәнергә була. Түгәрәк һәр дүшәмбе һәм җомга көннәрдә иртәнге 10нан көндезге 2гә кадәр эшли. Хорда шөгыльләнү дә, аерым җырлау мөмкинлеге дә бар. Шөгыльләнү түләүле. Вокал түгәрәгенә язылу 10 нчы сентябрьгә кадәр дәвам итә. | **Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**<br>1) Вокал белән кызыксынучылар өчен яңалыклар турында.<br>2) Вокал түгәрәгенә язылу мөмкинлеге турында.<br>3) Түгәрәктә хорда җырлау мөмкинлеге турында. |
| **15** | Укучылар!<br>Киләсе мәктәптә атнада мәктәптә “Игелеклелек ярминкәсе” оештырылачак. Ярминкәгә кул | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Укучыларның мохтаҗларга ярдәм итү өчен өлеш кертүе турында.<br>2) Иң активларга биреләсе бүләк турында.<br>3) №Игелеклелек ярминкәсе” игълан ителү турында. |

эшләнмәләрен дүшәмбе һәм сишәмбе көннәрендә тапшырырга мөмкин. Иң күп кул эшләнмәсе җыйган сыйныфны истәлекле бүләк көтә! Мохтаҗларга ярдәм итүгә һәркем үзеннән өлеш кертсен!

**16**

Алмаз, сәлам! Сине командабыз составында хоккей уйнарга чакырам. Иртәгә сәгать кичке алтыда безнең ишек алдында урам командалары арасында хоккей ярышы була. Син безнең командада уйнарсың дип өметләнәбез. Килерсең бит? Син – иң яхшы капкачы. Ярышта җиңәргә телибез. Бүләкләр дә булачак.

Азат

**Электрон хат аша Азатның дустына нәрсә турында әйтәсе килгән?**

1) Хоккей ярышы турында.
2) Дустын хоккей уйнарга чакыруы турында.
3) Ярышта җиңәргә теләве турында.

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Бу өйдә ул инде күптәннән яши иде. Бирегә ничек килеп эләккәнен хәзер бөтенләй хәтерләми, чөнки ул чакта кечкенә иде шул әле. Ләкин бер нәрсәне ул ачык хәтерли: кара мыеклы кеше аның алдына сөт салынган чынаяк китереп куйды. “Ашыйсың килгәндер, эч син, эч!” – дип аның борынын сөткә төртте. Тамагы туйгач, көчек койрыгын болгады, һәм шул вакытта аның күңелендә бу кешегә карата ихтирам хисе уянды.

Биредә аны яраталар иде. Эт берәр шуклык кылса да, болай гына әрлиләр. Ул үзе дә моны сизә, койрыгын селкетеп, хуҗаның күзенә карый. Хуҗа да моны аңлый һәм елмаеп куя, шул вакытта этнең эченә җылы йөгерә.

Башта алар өчәү генә яшәделәр: ул, хуҗа, хуҗаның әнисе. Аннары дүртәү булдылар: өйгә килен төште. Ә беркөнне, бәби алып кайткач, бөтен игътибар шул сабыйга күчте. Тик хуҗаның гына эткә булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, ул аны элеккечә ярата иде.

Хуҗа эштән көн дә бер үк вакытта кайта. Эт аны балконда утырып көтеп ала. Хуҗасы күрше йорт артыннан килеп чыгу белән, эт шатлыгыннан өреп куя. Нәни дустын күреп, хуҗаның да йөзе яктырып китә.

Беркөнне өй янына кайтып җиткән хуҗаны ниндидер кеше туктатты. Ул, кычкырып, аңа нәрсәдер аңлатырга тырыша, кулларын болгый. Хуҗаның шул кеше белән торуы этне борчуга салды. Эт аңлады: бу кеше хуҗаны җибәрми. Бу минутта эт өчен шушы кешедән дә явыз кеше юк иде.

Аның түземлеге бетте, ул аска карады һәм ... җиргә очты. Эт, асфальтка бәрелеп, бер-ике тыпырчынды да тынып калды. Ирләр бернәрсә аңламадылар, башта эткә, аннары дүртенче кат балконына карадылар. Берничә секундтан йөзе качкан хуҗа исенә килде, эткә таба иелде. (Солтан Шәмсидән).

**17** Көчек бу йортка ничек эләгә?

1) Кара мыеклы кеше алып кайта.
2) Сөткә алданып кайта.
3) Үзе бу йортны сайлый.
4) Ул аны хәтерләми.

**18** Эткә мөнәсәбәт нинди була?

1) Аны әрлиләр.
2) Аны яраталар.
3) Эткә озак ияләнәләр.
4) Этне хуҗа гына ярата.

**19** Алар ничәү яшиләр?

1) Өчәү.
2) Дүртәү.
3) Бишәү.
4) Алтау.

**20** Фаҗига ни сәбәпле була?

1) Чит кешеләр хуҗаны тоткарлыйлар.
2) Эт балконда була.
3) Хуҗа эткә ярдәмгә килә алмый.
4) Эт хуҗасыны ярдәм итәргә тели.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Беркөнне Фәрит әнисенең кушуы буенча (21) ... барган иде. Каракай да аңа иярде. Шунда прилавка янында әйберләр караган чакта, бер хатын кинәт:

–Урладылар, акчамны урладылар!-дип кычкырып җибәрде.

Фәрит аны-моны уйлап тормады, әлеге хатынга: “Тизрәк кулъяулыгыгызны чыгарыгыз!” – диде. Хатын (22) ...: “Нигә?” – дип сорамады, сумкасыннан бизәкле кулъяулыгын алып, Фәриткә бирде. Фәрит (23)... тиз генә Каракай борынына китереп иснәтте дә:

-Тиз эзлә! – диде.

Каракай сискәнеп киткән кебек булды. Әйтерсең, ул кинәт йокысыннан (24)... китте. Арт аякларына басып, башын як-якка боргалый-боргалый иснәде дә кинәт чабып китте. Йөзләгән аяклар арасыннан елан (25)... кенә сузылып үтте. Фәрит аның артыннан чак-чак кына җитешә иде. Каракай ишектән чыгарга дип барган яшь кенә егетнең чалбар балагына килеп ябышты. Фәрит (26) ...:

-Ташла акчаны, ташла! – дип кычкырды.

Шул арада таза гына бер кеше карак алдына килеп басты. Егет портмонетны идәнгә ыргытты. Каракай аны, авызына кабып, Фәриткә китереп бирде.

Кибеттәге кешеләр авызларына су капкан кебек тынып тордылар. (27)... бу гаҗәп бер хәл иде, әлбәттә. Кечкенә генә йорт эте каракны эләктерде бит!

Каракны тотып алдылар.Акчаны хуҗасына кайтардылар. Ул хәтта бераз аптырап та калды. Әле хәзер (28)... кайгы иде – инде куаныч!

(Нәби Дәүли)

**21** 1) кибеттә 2) кибеткә 3) кибетне 4) кибетнең

**22** 1) да 2) дә 3) та 4) тә

**23** 1)ул 2) аннан 3) аны 4) анда

**24** 1)уяна 2) уянып 3) уянды 4) уянган

**25** 1) кебек 2) өчен 3) артыннан 4) турында

**26** 1) карак 2) каракны 3) каракка 4) каракта

**27** 1) алар 2) аларны 3) алардан 4) аларга

**28** 1) гына 2) генә 3) кына 4) кенә

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кемнәрнең алтынчы дәресләре бар, алар очрашуда катнашмыйлар.
**Алтынчы дәресләре ... ... очрашуда катнашмыйлар.**

| | |
|---|---|
| **0** | **булган укучылар** |

**29** Имтиханнар тәмамланса да, мәктәптә очрашулар кимемәде.
**Имтиханнарыбыз ... мәктәптә очрашуларыбыз кимемәде**.

**30** Чит илдә ял итеп кайттык, шуңа күрә без бик шат.
**Чит илдә ял итеп ..., без бик шат.**

**31** Дәресләр тәмамланды, без шул вакытта кинога киттек.
**Дәресләр ... ... без кинога киттек.**

**32** Бәйгедә уңышлы чыгыш ясадык, шуңа күрә сөенечебез зур.
**Бәйгедә уңышлы ..., сөенечебез зур.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Ял көннәрендә мин каратэ белән шөгыльләнәм. Ике ел инде “Круиз” секциясенә йөрим. Анда миңа бик ошый. Без төрле ярышларда, бәйгеләрдә дә катнашабыз.*

*... Ә син нәрсә белән кызыксынасың?Буш вакытыңда нәрсә белән шөгыльләнергә яратасың? Нинди чараларда катнашканың бар?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Ничәнче автобус кирәк?**
А: Гафу итегез, әйтегезче, “Камал театры” тукталышына ничәнче троллейбус бара?
Ә: Минемчә 12нче троллейбус.
А: Ә ничәнче трамвай белән барып була?
Ә: Гафу итегез, анда трамвайлар йөрми. Автобуста барып була.
А: Алайса, 15нче автобус барамы?
Ә: Юк, бередән 15нче автобус йөрми. 63нчегә утырыгыз.
А: Рәхмәт Сезгә.

Ә: Исән-сау булыгыз.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Ике. Очрашуга кем килгән?**

А: Исәнмесез! Мин директорга килдем.
Ә: Исәнмесез! Сез алдан язылдыгызмы?
А: Әйе. Уникенче яртыга. Хәзер уникенче ярты. Керергә мөмкинме?
Ә: Гафу итегез, әз генә көтегез. Менә монда утырып торыгыз. Мин хәзер Галина ханымга әйтәм. Сез нинди мәсьәлә буенча килдегез?
А: Яхшы.Мине редакциядән сезнең мәктәп турында мәкалә әзерләү өчен җибәрделәр. Озак көтәргә кирәк булачакмы?
Ә: Минемчә, юк. Хәзер керерсез.
А: Яхшы, рәхмәт.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Өч. Янәшә урыннар кайда калган?**
А: Хәерле көн! Миңа бүгенге спектакльгә ике билет кирәк иде.
Ә: Исәнмесез! Бүгенгә билетлар аз калды. Хәзер тәкъдим итеп карыйм.
А: Партерга билетлар бармы?
Ә: Әйе, өч билет бар, ләкин урыннар янәшә түгел. 10нчы, 12нче, 14нче рәтләрдә берәр урын бар.
А: Гафу итегез, безгә янәшә ике урын кирәк иде. Андый урыннар юкмы?
Ә: Балконда икенче рәттә бар. Аласызмы?
А: Әйе, алам. Бүгенге спектакльне карыйсыбыз килә.
Ә: Яхшы. Балконда икенче рәттә унынчы, унберенче урыннар. Рәхим итегез.
А: Рәхмәт!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Чаңгы батинкалары кайда сатыла?**
А: Гафу итегез, спорт киемнәре бүлеге кайда?Өченче каттамы яки беренчедәме?
Ә: Икенче катта.
А: Сез беләсезме, анда чаңгы ботинкалары саталармы?
Ә: Минемчә, булырга тиеш.

А: Рәхмәт Сезгә.
Ә: Исән-сау булыгыз.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Поезд кайчан киләчәк?**
А: Сәлам!
Ә: Сәлам!
А: Поезд килгәнче, кафега кереп, чәй эчик.
Ә: Кафе еракмы соң?
А: Юк, ерак түгел. 5минутлык юл.
Ә: Ярый. Ә поезд кайчан киләчәк?
А: Ярты сәгатьтән.
Ә: Әйдә, киттек.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Билетлар ничәнче рәткә алынган?**
А: Хәерле кич!
Ә: Исәнмесез!
А: Урыннарыгыз партердамы?
Ә: Әйе, уналтынчы рәттә.
А: Ә безнең урыннар ике рәткә арттарак.
Ә: Шул ук урыннармы соң?
А: Әйе.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты. Ялны кайда үткәргәннәр?**
А: Ял көне кайда булдыгыз?
Ә: Бакчада.
А: Бакчагыз кайда урнашкан?
Ә: Идел буенда.
А: Анда нишләдегез?
Ә: Җиләк җыйдык, яшелчәләргә су сиптек.
А: Урманга бардыгызмы соң?

Ә: Анда урман юк.
А: Елгада су коендыгызмы?
Ә: Әйе, күлдә коендык.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**
[пауза 20 секунд]
**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.
Сәлим: Сәлам, Миләүшә!
Миләүшә: Исәнме, Сәлим!
Сәлим: Син кая барасың?
Миләүшә: Спорт мәктәбенә.
Сәлим: Син спорт белән шөгыльләнәсеңмени?
Миләүшә: Әйе, фигуралы шуу белән шөгыльләнәм.
Сәлим: Ничә ел инде?
Миләүшә: 5 яшьтә шөгыльләнә башладым.
Сәлим: Атнага ничә тапкыр тренировкалар була?
Миләүшә: Өч тапкыр.
Сәлим: Ярышларда да катнашасыңмы?
Миләүшә: Әйе. Ел саен катнашам.
Сәлим: Уңышларың бармы соң?
Миләүшә: Әлбәттә. Быел республика беренчелегендә беренче урын алдым.
Сәлим: Котлыйм.
Миләүшә: Ә син нәрсә белән кызыксынасың, Сәлим?
Сәлим: Миңа информатика дәресләре бик ошый.
Миләүшә: Компьютер уеннарын яратасыңмы?
Сәлим: Юк, уйнарга яратмыйм, программалар төзергә яратам.
Миләүшә: Кызык.
Сәлим: Мин информатика түгәрәгенә дә йөрим. Анда безне күп нәрсәгә өйрәтәләр. Без олимпиадаларда да катнашабыз.
Миләүшә: Призлы урыннар алдыгызмы соң?
Сәлим: Әйе, былтыр республикада җиңдек. Аннары Мәскәүгә дә бардык.
Миләүшә: Сине уңышларың белән котлыйм.
Сәлим: Рәхмәт, Миләүшә. Сиңа да уңышлар телим.
Миләүшә: Яхшы. Сау бул.
Сәлим: Сау бул.

**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

## ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 17 | 4 |
| 2 | 2 | 18 | 2 |
| 3 | 2 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 4 |
| 5 | 3 | 21 | 2 |
| 6 | 1 | 22 | 1 |
| 7 | 3 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 2 |
| 9 | 1 | 25 | 1 |
| 10 | 1 | 26 | 3 |
| 11 | 2 | 27 | 4 |
| 12 | 1 | 28 | 2 |
| 13 | 2 | 29 | тәмамланугакарамастан |
| 14 | 2 | 30 | кайтканга/ кайтуыбызга |
| 15 | 3 | 31 | тәмамлангачкына |
| 16 | 2 | 32 | чыгышясаганга/ чыгышясаусәбәпле |

**10 нчы вариант**

**Раздел 1**

***Прослушайте 7 коротких диалогов. В заданиях 1 - 7 укажите правильный вариант ответа. Вы услышите аудиозапись дважды.***

**1** **Нинди ручка кирәк?**
1) 58 сумлык
2) арзанлы
3) 15 сумлык

**2** **Кызның нәрсә укыйсы килгән?**
**1)** “Казан утлары” журналын
2) Һ.Такташ әсәрен
3) повестьне

**3** **Әминә нишләгән?**
1) “Яңалыклар” караган
2) “Һава торышы”н тыңламаган
3) тиз-тиз йөргән

**4** **Егет эчтәлекне каян белә?**
1) әсәрне укыган
2) фильмны инде караган
3) дусты сөйләгән

**5** **Егет китапның ничә томын алган?**
1) 1
2) 3
3) 4

**6** **Кроссовкаларны ни өчен алмаганнар?**
1) кыйбат булганга
2) арзан булганга
3) сыйфатсыз булганга

**7** **Кыз кайсы футболканы сатып алган?**
1) рәсемле төсле футболканы
2) рәсемле ак футболканы
3) рәсемсез ак футболканы

***Прослушайте разговор двух друзей. Определите, какие из приведенных утверждений 8 - 13 соответствуют содержанию текста (1), а какие – не соответствуют (2). Вы услышите аудиозапись дважды.***

**8** Алсу бакчада ял иткән.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**9** Алсу спорт белән шөгыльләнә.
1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**10** Алсу күлдә су коенган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры илми

**11** Самат лагерьдә булган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**12** Самат футбол уйнаган.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

**13** Самат диңгезгә барырга теләгән.

1) текстка туры килә 2) текстка туры килми

## Раздел 2

***Прочитайте тексты в заданиях 14 – 16. После каждого текста определите правильный вариант ответа.***

| | | |
|---|---|---|
| **14** | Сәнгатьле сөйләм белән шөгыльләнергә теләүчеләр игътибарына! Шигырь язу һәм уку белән кызыксынсагыз, безнең түгәрәккә килегез. Монда сез күңелле һәм файдалы ял итә аласыз! Концерт залында атнага ике тапкыр сәнгатьле уку дәресләре була. Сез концертларда чыгыш ясарга, матур сөйләргә өйрәнерсез! Түгәрәк һәр дүшәмбе һәм җомга көннәрдә иртәнге 10нан көндезге 2гә кадәр эшли. Төркемдә дә, аерым да шөгыльләнү мөмкинлеге дә бар. Шөгыльләнү түләүле. Сәнгатьле уку түгәрәгенә язылу 10 нчы сентябрьгә кадәр дәвам итә. | **Белдерүдә сүз нәрсә турында бара?**<br>1) Сөйләм сәнгате белән кызыксынучылар өчен яңалыклар турында.<br>2) Сәнгатьле сөйләм түгәрәгенә язылу мөмкинлеге турында.<br>3) Түгәрәктә аерым шөгыльләнү мөмкинлеге турында. |
| **15** | Укучылар!<br>Киләсе мәктәптә атнада мәктәптә “Алтын куллар” бәйгсе оештырылачак. Бәйгегә кул | **Бу хәбәр нәрсә турында?**<br>1) Укучыларның кул эшләнмәләре белән танышу турында.<br>2) Иң активларга биреләсе бүләк турында.<br>3) “Алтын куллар” бәйгесе игълан ителү |

| | |
|---|---|
| эшләнмәләрен дүшәмбе һәм сишәмбе көннәрендә тапшырырга мөмкин. Иң күп һәм оригиналь кул эшләнмәсе җыйган сыйныфны истәлекле бүләк көтә! Һәркем үз осталыгн күрсәтсен! | турында. |

**16**

| | |
|---|---|
| Алмаз, сәлам! Сине командабыз составында баскетбол уйнарга чакырам. Иртәгә сәгать кичке алтыда безнең ишек алдында урам командалары арасында баскетбол ярышы була. Син безнең командада уйнарсың дип өметләнәбез. Килерсең бит? Син – иң яхшы уенчы. Ярышта җиңәргә телибез. Бүләкләр дә булачак. <br>Азат | **Электрон хат аша Азатның дустына нәрсә турында әйтәсе килгән?** <br>1) Баскетбол ярышы турында. <br>2) Дустын баскетбол уйнарга чакыруы турында. <br>3) Ярышта җиңәргә теләве турында. |

***Прочитайте текст. В заданиях 17 - 20 укажите правильный вариант ответа.***

Көннәр җылынып китте. Агачлар сиздермичә генә яфрак яра башладылар. Безнең бакча тирәсендәге урманга иң беренче булып кара каргалар кайтып төште. Алар үзләренең өзлексез тавышланулары белән бөтен тирә-якны шау-шуга күмделәр. Агач башларына оялар корып җибәрделәр.

Бер генә дә тик тормыйлар. Берсе чыбык-чабык ташый, икенчесе ул чыбыкларны бик оста итеп тезеп куя бара. Кайчакларда талашып та китәләр я, барысы да берьюлы гөрләшеп, һавага күтәреләләр дә үзара буталышып бетәләр.

Бер караганда, бу кара каргалар ничектер безнең кебек кыланалар. Без дә шулай бит, кара каргалар шикелле, әллә кайлардан җыелышып, бире килдек. Без дә, нәкъ шул каргалар шикелле, бу тынып торган бакчага шау-шу китердек. Каргалар оя корган кебек, без дә еллар буе кешесез, җимерелеп калган йортларны төзәтеп маташтык. Тукта әле, искә төште: безне Галимҗан бабай юкка гына каргалар дип әйтмәгән. Чыннан да, без шул тынгысыз каргалар шикеллерәк бит...

... Иртәнге вакыт иде. Бүген – ял көне, ашыгасы түгел. Гариф үз урыныннан әкрен генә торды да тәрәзә янына килеп басты һәм кинәт:

- Малайлар, торыгыз әле, тор!- дип кычкырды. – Бакчада әкәмәт!

Без, сикереп торып, тәрәзәгә капландык. Безнең бакчабыз ап-ак шау чәчәккә күмелгән иде. Иснәгән саен иснисе, мактанасы килә. Кем алдында мактанырга? Барыбыз да эшләдек бит бередә!

(Нәби Дәүлидән)

**17** Урманга беренче булып нәрсәләр кайта?
1) Сыерчыклар.
2) Сандугач.
3) Җылы якка киткән кошлар.
4) Кара каргалар.

**18** Каргалар нишлиләр?
1) Һәрвакыт талашалар.
2) Һәрвакыт эшлиләр.
3) Һәрвакыт каңгылдашалар.
4) Һәрвакыт тик торалар.

**19** Кешеләр нәрсә белән каргаларга охшаганнар?
1) Һәрвакыт тавышлanулары белән.
2) Күп булулары белән.
3) Төрле яктан җыелулары белән.
4) Иртә торулары белән.

**20** Егетләрне нәрсә шаккатырган?
1) Каргаларның шау-шуы.
2) Эшнең күплеге.
3) Ял көне булу.
4) Бакчаның ямьләнүе.

## Раздел 3

***Прочитайте текст. В заданиях 21 – 28 определите правильный вариант ответа.***

Фәрит өйгә кайтып керде. Ул иң элек (21) ... күргәзмәдә булган кызыклар турында сөйләргә теләгән иде, (22) .... әтисе өйдә булмады. Әнисе дә нигәдер бик борчулы, өстәл янында бик күңелсез утыра иде. Фәрит куркып калды:

-Әнием, (23) ... булды? – диде.

- Авылдан телеграмма килде. Әбиең бик нык авырган икән. Әтиең аэропортка билет (24) ... китте...

Фәрит дәшмәде. Тагын сораша башласа, әнисе тагын берәр авыр хәбәр

әйтер (25)... тоелды аңа.

Әлбәттә, Фәрит дәү әнисен бик ярата. Ел саен ул җәйге каникуллар вакытында авылга кунакка кайта торган иде. Ә быел ул үзенең Каракае белән авыл малайларының исләрен китермәкче иде.(26) .... йорт этләре бик күп. Фәрит, аларны да шулай өйрәтеп була дип, малайларның үзләренә дә әйтмәкче иде. Югыйсә, авылда йорт этләренә "эт" дип кенә карыйлар. Капка ачылганда өзгәләнеп өрсә, кемнең кем икәнен белмичә тешләргә теләсә, (27) ... яхшы эт шул була инде. Ә ул этләрне күпме кыйнап җәберлиләр анда! Янәсе, усал булсын. Әмма беркем (28)... акыллы булсын дип борчылмый.

Әйе, Фәритнең планнары зур иде. Тик бу җәйдә аңа авылга кайтырга туры килмәде, чөнки бер атнадан дәү әнине шәһәргә алып килделәр. Аның күзләре күрми иде. Фәрит әбисен бик кызганды.

- Борчылма, әбием, Казанда бик оста күз докторлары бар, дәваларлар, - дип, әбисен юатты.

(Нәби Дәүлидән)

**21** 1) этигә 2) этисенә 3) этине 4) этисен

**22** 1) әмма 2) һәм 3) ягъни 4) яки

**23** 1) кем 2) нинди 3) нәрсә 4) ничек

**24** 1) алып 2) алырга 3) ала 4) алды

**25** 1) кебек 2) өчен 3) артыннан 4) турында

**26** 1) авыл 2) авылны 3) авылда 4) авылдан

**27** 1) алар 2) аларны 3) алардан 4) аларга

**28** 1) да 2) дә 3) та 4) тә

## Раздел 4

***Прочитайте задания 29 - 32. Допишите второе предложение так, чтобы оно по значению совпадало с первым. Используйте не больше трех слов в каждом предложении. В бланк ответов перепишите только пропущенные слова, без интервала как в примере.***

**ҮРНӘК** **0** Кемнәрнең алтынчы дәресләре бар, алар очрашуда катнашмыйлар.

**Алтынчы дәресләре ... ... очрашуда катнашмыйлар.**

| | |
|---|---|
| **0** | **булган укучылар** |

**29** Салкыннар бетсә дә, кояшлы көннәр әле аз иде.

**Салкыннар ..., кояшлы көннәр аз булды.**

**30** Дусларым туган көнем белән котладылар, шуңа күрә мин бик шат.

**Дусларым туган көнем белән ..., мин бик шат.**

**31** Сыйныфташларым чакыргач, без кинога киттек.

**Сыйныфташларым ... без кинога киттек.**

**32** Ярышта кубок алдык, шуңа күрә сөенечебез зур.

**Ярышта кубок ... сөенечебез зур.**

**33** **Вы получили письмо от друга (подруги). Напишите ему (ей) письмо объемом не менее 60 слов, ответив на его (её) вопросы.**
**Для ответа на это задание используйте специальный бланк ответов.**

*... Кичә минем туган көнем булды. Дусларым миңа кунакка килделәр. Алар белән бик күңелле булды: уйнадык, җырладык, күңел ачтык. Котлаулар тыңлау да күңелемә хуш килде.*

*... Ә синең туган көнең кайчан? Гадәттә, туган көнеңә кемнәр килә? Алар белән ничек бәйрәм итәсез?*

**Тыңлап аңлау биремнәре өчен текстлар**

**Инструктор. Сез җиде кыска диалог тыңларсыз. 1-7 нче сорауларга туры килгән җавапны үрнәктәгечә билгеләгез.**
**Сез аудиоязманы ике тапкыр тыңларсыз.**

**Инструктор. Бер. Нинди ручка кирәк?**
А: Исәнмесез!
Ә: Исәнмесез!
А: Миңа ике рәсем дәфтәре һәм бер ручка бирегезче.
Ә: Кайсы ручка кирәк? Күрсәтегез әле.
А: Менә бу 59 сумлык ике рәсем дәфтәре һәм 15 сумлык ручка кирәк.
Ә: Яхшы, хәзер бирәм.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Ике. Нәрсә укыйсы килгән?**
А: Гафу итегез, Сездә Һади Такташның яңа басылган җыентыгы юкмы?
Ә: Бар. Ләкин хәзергә аны укыйлар, китап кулда.

А: Кызганыч, минем дә укыйсым килгән иде.
Ә: Сезне чиратка куйыйммы? Китапны тапшыргач, хәбәр итәрмен.
А: Ярар, шулай итегез.
Ә: Хәзергә башка китап укый торырга теләмисезме?
А: Миңа "Казан утлары" журналының соңгы санын бирегезче.
Ә: Яхшы, хәзер алып киләм.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Өч. Әминә нишләгән?**
А: Хәерле көн! Исәнме, Әминә!
Ә: Исәнме, Азат! О-о, бүген нинди салкын көн!...
А: Әйе, хәзер иртән һәрвакыт салкынча була. Бүген көндез дә 5 градус кына җылы була, диделәр.
Ә: Мин " Яңалыклар"дан һава торышы турында тыңламадым шул. Җиңелчә генә киенгән идем. Туңармын инде...
А: Ә син тиз-тиз бар. Тукталышка кадәр тиз барсаң туңмассың.
Ә: Юк, минемчә, өйгә кереп, калын куртканы киеп чыгарга кирәк. Авырыйсым килми.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Дүрт. Егет эчтәлекне каян белә?**
А: Энем, син бу фильмны карадыңмы әллә?
Ә: Юк, апа, караганым юк. Беренче тапкыр карыйм. Нигә алай дисез?
А: Син бит аның эчтәлеген алдан сөйләп барасың....
Ә: Мин фильм төшерелгән әсәрне укыган идем.
А: Шулаймыни! Энем, синеңчә, фильм кызыгракмы?
Ә: Фильмда бик күп махсус эффектлар бар, әмма әсәр эчтәлеге бераз үзгәртелгән. Миңа әсәр күбрәк ошады.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Биш. Егет ничә том алган?**
А: Хәерле көн!
Ә: Хәерле көн!
А: Миңа Лев Толстойның "Сугыш һәм тынычлык" китабы кирәк. Сездә бармы?
Ә: Әйе, әлбәттә. Китап рус телендә кирәкме яки татарчамы?

А: Татарча. Ничә сум тора?
Ә: Бер  томы - 280 сум.
А:  Яхшы, мин алам.
Ә: Барлык томнар да кирәкме?
А: Әйе.
Ә: Сездән 1мең 120 сум.
А: Яхшы.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Алты.  Кроссовкаларны ни өчен алмаганнар?**
А: Исәнмесез!
Ә: Исәнмесез!
А: Миңа  бу зәңгәр кроссовкаларны күрсәтегезче.
Ә:  Яхшы. Сезгә ничәнче үлчәм кирәк?
А: 38 нче үлчәм. Алар ничә сум?
Ә: Хәзер карыйм. Өч мең алты йөз сум.
А: О-О  кыйбат!
Ә: Әйе, ләкин бик сыйфатлы.
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Җиде. Нинди футболка кирәк?**
А: Исәнмесез! Сездә 44 нче үлчәмле  ак футболкалар бармы?
Ә: Исәнмесез! Әйе, бар.
А:  Миңа күрсәтегезче. Алар рәсемлеме?
Ә: Рәсемле футболкалар да, рәсемсезләре дә бар.
А: Рәсемсез футболка ничә сум?
Ә: 200  сум.
А: Миңа шуны бирегез.
Ә: Рәхим итегез!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.   Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**

**Инструктор. Сез ике дусның сөйләшүен тыңларсыз. 8-13 нче биремнәрдәге раслауларның текстка туры килүен яки туры килмәвен билгеләгез. Сез диалогны ике тапкыр тыңларсыз.**
[пауза 20 секунд]

**Инструктор.** Хәзер сез диалог тыңларсыз.
Самат: Сәлам, Алсу!
Алсу: Исәнме, Самат! Тагын укый башладык.
Самат: Әйе. Син җәен кайда булдың?
Алсу: Спорт лагеренда.
Самат: Лагерь кайда урнашкан?
Алсу: Урманда.
Самат: Син анда нишләдең?
Алсу: Саф һавада ял иттем, теннис, волейбол уйнадым, велосипедта йөрдем.
Самат: Су коендыңмы?
Алсу: Әйе.
Самат: Кайда?
Алсу: Күлдә. Урман янында бик чиста күл бар.
Самат: Лагерьда кызык булдымы?
Алсу: Әйе, бик кызык булды. Ә син кайда ял иттең?
Самат: Бакчада.
Алсу: Кояшта кызындыңмы?
Самат: Әйе, тагын футбол уйнадым, су коендым.
Алсу: Рәхәт булдымы?
Самат: Әлбәттә!
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор. Диалогны икенче тапкыр тыңлагыз.**
[язма икенче тапкыр яңгырый]
**[2 секунд пауза]**
**Инструктор.** Җавапларны махсус бланкка күчерү өчен, 6 минут вакытыгыз бар.

## ҖАВАПЛАР

| Биремнәр | Дөрес җавап | Биремнәр | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 17 | 4 |
| 2 | 2 | 18 | 2 |
| 3 | 2 | 19 | 3 |
| 4 | 1 | 20 | 4 |
| 5 | 3 | 21 | 2 |
| 6 | 1 | 22 | 1 |
| 7 | 3 | 23 | 3 |
| 8 | 2 | 24 | 2 |
| 9 | 1 | 25 | 1 |
| 10 | 1 | 26 | 3 |
| 11 | 2 | 27 | 4 |
| 12 | 1 | 28 | 2 |
| 13 | 2 | 29 | бетүгәкарамастан |
| 14 | 2 | 30 | котлаганга/ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | котлаусәбәпле |
| 15 | 3 | 31 | чакырганга |
| 16 | 2 | 32 | алганга/ алу сәбәпле |

## Шәхси хат язу биремен бәяләү критерийлары

| К | Бәяләү критерийлары | 3 балл | 2 балл | 1 балл | 0 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| К 1 | Коммуникатив бурычны үтәү | ***Эш тулысынча башкарылган:*** 3 сорауга да тулы җавап бирелгән. Мөрәҗәгать итү, саубуллашу һәм имзалау фразалары дөрес сайланган. Алынган хатка рәхмәт белдерелгән | ***Эш башкарылган:*** 3 сорауга да җавап бирелгән, әмма берсенә бирелгән җавап тулы түгел. Хат стилен бозган 1-2 төгәлсезлек бар ***һәм/яки*** алынган хатка рәхмәт белдерелмәгән | ***Эш өлешчә башкарыл-ган***: 2 сорауга гомуми җавап бирелгән, әмма 1 сорауга бирелгән җавап тулы түгел ***яки*** бер сорауга гомумән җавап юк. Хат стилен бозган 3 яки күбрәк төгәлсезлек бар, итагатьлелек формалары сакланмаган | ***Эш башкарылмаган:*** 2 сорауга җавап бирелмәгән ***яки*** текстның күләме тулмый |
| К 2 | Текстны оештыру | | Текст логик эзлеклелектә төзелгән һәм абзацларга бүленештә хаталар юк; тел чаралары дөрес кулланылган; хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килә | Текст, гомумән алганда, логик эзлеклелектә төзелгән, ләкин логик бәйләнешлә рдә ***һәм /яки*** абзацларга бүленештә ***яки*** хатның төзелешендә 1-2 төгәлсезлек бар | Текст төзелешендә логик эзлеклелек сакланмаган; язма текст төзелешендә 3 яки күбрәк хата бар, ***яки*** хатның төзелеше язма этикет нормаларына туры килми. |
| К | Текстның | Коммуникатив | Текстны | Текстны | Текстны аңлауга |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | лексик-грамматик төзелеше | бурычны үтәү өчен кирәк булган төрле лексик һәм грамматик чаралар файдаланылган (текстны аңлауга зыян китермәгән 1-2 төгәлсезлек рөхсәт ителә) | аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (3-4 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***яки*** тел хаталары юк, ләкин артык гади лексик һәм грамматик чаралар кулланылган | аңлауга зыян китермәгән тел чараларына караган хаталар бар (5-6 тупас булмаган хата рөхсәт ителә) ***һәм /яки*** текстны аңлауга зыян китерә торган 1-2 грамматик хата бар | зыян китерә торган хаталар 6 дан күбрәк |
| К 4 | Орфография һәм пунктуация | | Орфографик һәм пунктуацион хаталар юк, **яки** текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 1-2 хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерми торган 3-4 орфографик һәм пунктуацион хата бар | Текст эчтәлеген аңлауга зыян китерә торган орфографик һәм пунктуацион хаталар 4 тән күбрәк |

Шәхси хат язу биреме К1-К4 критерийлары буенча тикшерелә. Максималь **10 балл** алырга мөмкин.

Текстның эчтәлеге биремгә туры килмәсә (язма хат характерында булмаса, **тәкъдим ителгән сорауларга җавап урынына башка мәгълүмат язылса**, тәкъдим ителгән хат күчереп кенә язылса) бу бирем өчен 0 балл куела.

Хатның күләме **40** сүздән ким булса, К3 һәм К4 критерийлары буенча максималь балл куелмый.

Эшнең күләмен билгеләгәндә, беренче сүздән алып соңгысына кадәр (шулай ук адрес, язылу вакыты, имза да) исәпкә алына. **Хатта укучы үзенең чын исемен, адресын күрсәткән очракта эш тикшерелми.**

Эчтәлек


| | |
|---|---|
| ТАТАР ТЕЛЕ. 81 нче код биремнәре ............................................................... | 3 |
| Татар әдәбияты. 71нче код биремнәре ............................................................. | 27 |
| ТАТАР ТЕЛЕ. 82 нче код биремнәре ............................................................... | 90 |
| Татар әдәбияты. 72нче код биремнәре ............................................................... | 104 |
| ТАТАР ТЕЛЕ. 83 нче код биремнәре ............................................................... | 156 |